**Сәлахетдин Таҗиев**

# *Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә*

**Алабуга шәһәре**
**2000 ел**

Сәләхетдин Таҗиев



# Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә

Тарихи-публицистик очерклар

Алабуга шәһәре 2000 ел

Бу китапны нәшер итүдә матди ярдәм күрсәтүчеләр: НГДУ «Прикамнефть» башлыгы Нариман Кияметдин улы Җамалетдинов, шул ук идарәнең ППН башлыгы Вәлиәхмәт Мөхәмәтдин улы Сираҗетдинов, «Кама» колхозы рәисе Ибраһим Миндар улы Галимов, «Бехтерево» колхозы рәисе М.Х.Сәлимуллина, авылдашлар Минегәли Гыйләҗетдин улы Гәйнетдинов, Рәфиснур Хаҗи улы Шакиров. Аларга барлык авыл халкы, авылның киләчәк буыннары исеменнән зур

рәхмәт.

Бәяләүчеләр:
филология фәннәре докторы, АДПИ профессоры
Л.Ш.Арсланов
тарих фәннәре кандидаты, гомуми һәм Ватан тарихы кафедрасы мөдире, доцент А.М.Көлимуллин

**Таҗиев С.Ф. Туган авылыбыз Бөзәкә кайда да безнең йөрәктә. - Алабуга, 2000. - 120 бит.**

Бу хезмәт мәгөллифнең туган авылы - Менделеевск районы Бәзәкә авылы тарихын өйрәнүгә багышланган. Китапта фәнни, архив, музей һәм Бәзәкә мәктәбе укытучылары һәм укучылары җыйган материалларга, авыл картлары сөйләгән хикәятьләргә, юрамаларга нигезләнгән тарихи-публицистик очерклар тупланган.

Китап киләчәк яшь буын вәкилләрен тәрбияләүгә, аларда туган авылны, милләтне хөрмәт итү, ярату хисләре тәрбияләүгә зур өлеш кертер дигән өметтә калабыз.

ББК-63.3 (2Р-6Т) _______ ________

Тазиев Саляхутдин Фардиевич

**НЕ ЗАБЫТЬ НАМ БИЗЯКИ РОДНОЕ**
Историко-публицистические очерки

(на татарском языке)

*Әнием Газизәбану һәм әтием Фәрдетдин истәлегенә багышлыйм*

**Туган авылыбыз Бәзәкә**

С. Таҗиев сузлере, В. Әхмәтшин көе Киң
болыннар, әрәмәлек Туган ягымда.
Башын игән бөдрә таллар
Инеш ярында.
Кушымта:
Туган авылыбыз Бәзәкә,
Кайда да безнең йөрәктә.
Матурлана, үсә һаман Безнең
Бәзәкә!
Туган якның саф жилләре Хуш
ис тарата.
Пинәрәнең йомшак суын
Һәркем ярата.
Кушымта.
Бакчаларда гөрләп үсә Зур
алмагачлар.
Егетләребез бик эшчән Һәм
уңган кызлар.
Кушымта.

**Туган авылым - Бәзәкәм**

М. Гыймазетдинов сүзләре, В. Мироваев көе
Басуларда - башак җыры,
Тургай моңы кырыңда.
Зифа буйлы сылуларың
Уйный йөрәк кылында.
Кушымта:
Әй Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Языңны көтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җылыма салам.
Комбайннар, тракторлар,
Егетләр җырлый кырда.

Бер симфония язарсың Иркенләп
тыңлап тор да. Кушымта.
Иген игә егет-кызың,
«Кара алтын» таба илгә.
Шатланам, Бәзәкәм, мин бит
Синдә дөньяга килгән.
Кушымта.

**Сагындырды мине**
Фәйзелхак Хөснетдинов сүзләре

Давыл тынды. Алман күге зәңгәр.
Без торабыз Ватан сагында.
Сагыну хисе әмма тынгы бирми
Җанга көндез, кичен, таңын да.
Сагындырды мине туган авылым,
Төшкә керә бала чакларым.
Чулман буе, күлләр, тәнбоеклар,
Бөдрә таллар, туган якларым.
Сагындырды мине зәңгәр урман,
Авылымның алсу таңнары.
Сагындырды мине таныш моңнар,
Үз халкымның талгын моңнары.
Сагындырды мине хәтфә болын,
Колхозымның иген кырлары.
Сагындырды авылым егетләре,
Яулык болгап калган кызлары.
Сагындырды мине туганнарым,
Авылдашлар, ялгыз аналар.
Сагындырды мине изге мәктәп,
Җиз кыңгырау, нәни балалар.
Җиде елдан бирле сагынам сине,
Һәй, Бәзәкәм, кайтып күрергә! Бик
күпләрне гашыйк иткән Пинәрөңдә
йөзеп йөрергә!

**Туган җирем**
Фәния Шакирова сүзләре

Гөл чәчәкләр хуш исләрен
Тирә-юньгә сибәләр.
Күпме йөрәк сагынудан

Туган җир дип тибәләр.
Йолдызлар да якты балкый
Туган җирем кугендә.
Туган җирдән сәлам килсә
Шатлык иңә йөземә.   5
Кошлар да матур җиремдә
Матур көйләр көйлиләр.
Туган җирләрен сагынып
Күпләр кайтып киләләр.
Яшел урман, иркен кырлар
Назлый кеше күңелен.
Һәркем туган төбәгендә Үтсен
калган гомерен.

**Баллы чишмә**

Зөфәр Гыймадиев сүзләре, Владимир Мироваев көе

Очраштырды безне язмыш
Баллы чишмә буенда.
Су эчәргә килгән идек Җәйге
Сабан туенда.
Кушымта:
Әй дускаем, кил әле -
Баллы чишмә буена.
Таллар да сине сагына,
Син генә гел уемда.
Урамнардан җырлап үттем
Авылым йоклап ятканда.
Саубуллаштык синең белән
Сызылып таңнар атканда.
Кушымта.
Сагынып кайттым авылымны,
Төштем чишмә буена.
Таллар белән сөйләшәмен,
Ә син һаман уемда.
Кушымта:
Ага чишмә сулары Тал
тамырлары аша.
Сагынуларымны ж.иткерәм
Шушы җырларым аша,
Сиңа шул җырым аша.

**КАЙДА ДА ЙӨРӘКТӘ**

Туган авылым Бәзәкәгә кайткач, түбән очта йнеш өстеннән салынган яңа күпер буенда үскән баһадир һәм мәһабәт таллар буена төшәм дә, аларга карап хәйран калам. Бу талларны минем Сәлимулла бабаем утырткан булган. Бу талларга карыйм да тирән уйга калам: туган авылым дашушы таллар шикелле карт авыл, авылымда искиткеч батыр һәм матур кешеләр яшәгән һәм яши, шушы таллар тирәсеннән кемнәр генә үтмәгән дә, бу таллар нинди генә язмышларны, вакыйгаларны курмөгән! Ә бу таллар туган авылым турында, аның кешеләре турында әллә нинди серләр, хикәяләр, риваятьләр беләдер. Тик алар сөйли алмый шул. Ә туган җиренең тарихы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән кем генә кызыксынмый микән соң?

Элек сихри күлләре, хәтфәдәй болыннары, яшел тугайлары булган Бәзәкә Татарстанда карт авылларның берсе буларак та, даһи кешеләре белән дә күрше тирә-юньдә, гомумән, республикада, хәтта Рөсәйдә күпләргә таныш авыл.

Бәзәкә авылы бүгенге көндә Чулман елгасының уң ягында урнашкан. Элек авыл елгага 7 километр чарасы ераклыкта, ә Чулман белән Бәзәкә арасында киң болыннар, әрәмәлек, матур күлләр ята иде, тик алар барысы да Түбән Чулман сү саклагычы астында калдылар. Көнбатышта авылдан 2-3 километр читтә нефть чыгаручылар промыселлары, 4 километр читтә Сәйтәк авылы, 10 километр ераклыкта Менделеевск шәһәре урнашкан. Төньякта авылның басу кырлары, Тукмаклы ята. 5 километр тирәсе ераклыкта Псәй авылы, көнчыгышка таба 7 километр читтә Турай авылы урнашкан. Көнчыгышта колхоз кырлары, Умарталык, әрәмәлек күренеп торалар. Авылны икегә бүлеп таллар, бөрлегәннәр белән уратып алынган инеш ага.

Менделеевск ягыннан килеп кергәндә, сул якта зур зират каршы ала, уң якта Бәзәкә урта мәктәбе һәм аның каршында ук балалар бакчасы, мәктәп артында Мәдәният йорты урнашкан. Олы урамга кергәч, сул якта «Кама» колхозы идарәсе кала, аның кырында Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар истәлегенә мәшһүр һәйкәл куелган, уңга борылгач, түбән очка таба магазиннар һәм авылның яңа мәчете каршылый. Гомумән, бу урамда элемтә бүлеге, саклау кассасы, китапханә,

шифаханә, кабул итү пункты, авыл советы ише объектлар урнашкан.

Инешнең уң ягында урнашкан авыл өлешендә дүрт зур урам, «Тау башы» дип йөртелә торган өлешендә өч урам бар. Ике урамга асфальт7 салынган, урамнарны асфальтләштерү дәвам итә. Авылда 400ләп хуҗалык бар, барлыгы 750 кеше яши. Йортларның күбесе агачтан'җиткерелгән, тик соңгы вакытларда авылда кирпичтән төзелгән коттеджлар күбәя башлаган. Бәзәкәне төз урамнар, бизәкле капкалар, бизәкле тәрәзә йөзлекләре, ялтырап ята торган калай түбәләр бизи. Соңгы вакытта йортларга газ кертелгән. Һәр урамга су колонкалары куелган.

Авылда эш сөючән, тыныч һәм үзара дус яшәүче кешеләр яши. Алар арасында колхозчылар, нефтьчеләр, завод һәм төзелеш эшчеләре, авыл интеллигенциясе бар. Ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә, бигрәк тә Сабан туй көннәрендә туган йортларына

Яр Чаллыда, Алабугада, Түбән Камада, Менделеевскида күпләп яшәүче, шулай ук Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Чиләбе, Пермь, Екатеринбург һәм башка Калининградтан алып Владивостокка кадәр урнашкан шәһәрләрдә яшәүче бәзәкөлеләр туган авылларын сагынып кунакка кайталар. Авылдашыбыз Марсель Гыймазетдинов әйтмешли:

Туган ягын кем сагынмый, кем юксынмый,
Шул якларга өзелеп карап, кем үксеми.
Көн дә кайтам уйларымда туган якка,
Моңнарымны көйгә салам синең хакта.
Таралганбыз дөнья буйлап бәхет эзләп,
Җыйналышыйк, көтә безне туган төбәк.
Тик бәхетле була кеше туган якта - Аңладым
мин чит җирләрдә шушы хакта.

Бу авылда туып, үскән, укып чыккан, күп кешеләрне явыз чирдән коткарып калган Казан ГИДУВының кафедра мөдире, медицина фәннәре докторы, Санкт-Петербург фән һәм сәнгать академиясенең член-корреспонденты, профессор Рифкәт Минһаҗ улы Таҗиев, Иркутск шәһәрендә яшәүче физика-математика фәннәре докторы, профессор, академик Мансур Кәрим улы Нәбиуллин, филология фәннәре кандидаты, Мәскәү милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының өлкән гыйльми хезмәткәре булып эшләгән Мансура Габдулла кызы Әхмәтова, энесе - техник фәннәр кандидаты Мансур Габдулла улы Әхмәтов, аның улы - Мәскәүдәге классик балет театрының атаклы солисты Айдар Мансур улы Әхмәтов, тарих фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты доценты Альта Хаҗиәхмәт кызы Мәхмүтова, философия фәннәре кандидаты, АДПИ доценты Зирәк Мәхмүт кызы Сайфуллина, педагогия фәннәре кандидатлары, ЛЦПИ доцентлары Мөнирә Әхмәтзәки кызы Нәҗметдинова (Бәхтигәрәева) һәм Сәләхетдин Фәрдетдин улы Таҗиев, тарих фәннәре кандидаты, Алабуга дәүләт педагогия институты доценты Айдар Мансур улы Кәлимуллин, НГДУ «Прикамнефть» идарәсенең ППН начальнигы, Россия Федерациясенең атказанган нефть промышленносте хезмәткәре Вәлиәхмәт Мөхәммәтдин улы Сираҗетдинов, Татарстан Республикасының атказанган табибе, күрше тирә-юньдә белем дәрәҗәсе һәм тәҗрибәсе белән дан тоткан Алабуга территориаль медицина берләшмәсе баш врачының

дәвалау буенча урынбасары Сәетнур Сәләхетдин улы Нәҗметдинов, Яр Чаллы прокуратորасының баш прокурор урынбасары Гөлшат Фәрәхетдин кызы Хуҗиәхмәтова, Татарстан Республикасының атказанган укытучылары Рәшит Госман улы Бәшаров, Наҗия Хаҗиәхмәт кызы Мәхмүтова, Габделхәй Гыйльфан улы Гыйльфанов, СССРның мәгариф отличнигы Шәмсия Гәли кызы Гимазова (Ибәтуллина), РСФСРның мәгариф отличниклары Мәүлидә апа Галимуллина, Әминә апа Бәдретдинова, Фирая Хаҗи кызы Салихова, Зөйнак Әһли улы Әһлиев, Фоат Гатаулла улы Көләчев, Татарстанда бердәнбер гомер буе пионер вожатые булып эшләгән мәгариф отличнигы Әдия Сәлим кызы Ибраева, аның эшен дәвам итүче Рәмзия Гәрәй кызы Мөхетдинова (Гыймазетдинова), тәҗрибәле шәфкать туташы Рәфисә Баһаутдин кызы Шәрәфетдинова-Забражных, моңлы җырлары һәм шигырьләре белән күңелебезгә кереп калган шагыйребез Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов, Мәскәүдә хезмәт итүче полковник Рәвил Хәмәт улы Гыймадиев, Санкт-Петербургта хезмәт итүче подполковник Саетшәриф Хаҗиәхмәт улы Мәхмүтов, подполковник Сәетнур Гәли улы Габдрахманов, подполковник Рәфис Галимҗан улы Шакиров, Татарстан Республикасы эчке эшләр министрлыгы идарәсенең начальник урынбасары Вәгыйз Гәли улы Сираҗетдинов, Яр Чаллы эчке эшләр идарәсе АТХ начальнигы Рәшит Фәйзи улы Исмәгыйлов, Әгерҗе һәм Менделеевск районнарында алдынгы колхозлар рәисе булып эшләгән Мөхәмәтнур Нуриәхмәт улы Гыйльфанов, күп еллар хакимият һәм җәмәгать оешмаларында эшләгән Зиннур Нуриәхмәт улы Гыйльфанов һәм Фәрит Рәшит улы Бәшаров, Алабуга районының «Бехтерево» колхозы рәисе Мансура Хәмәт кызы Сәлимуллина, колхоз ветераннары Гәбделхак Гыйльфан улы Хөснетдинов, Нуриәхмәт Хажи улы Азин, Наҗия Әхмәтриза кызы Җамалетдинова, Менделеевск шәһәренең АТП директоры Минезөфәр һәм Яр Чаллы «Трестподряд» генераль директоры Мөнәвир Хәмәт уллары Гыймадиевлар, Менделеевск элемтә бүлеге баш инженеры Мансур Минегәли улы Әхмәтҗанов, клуб мөдире булып эшләгән Вәгыйдә Минегәли кызы Әхмәтжанова, сугыш һәм хезмәт ветераны Фәйзелхак Гыйльфан улы Хөснетдинов, балалар бакчасында гомерләре буе эшләгән Гайшә апа Хөснуллина һәм

Минеҗамал Зинәтуллина, Алабуга татар гимназиясе директоры урынбасары Рәмзия Нурмөхәмәт кызы Нигьмәтулова (Шәймөхәмәтова), 17 ел инде колхозны һәм авылны төзекләндерүгә күп көч куйган колхоз рәисе Ибраһим Миндар улы Галимов һ.б. Бәзәкәнең данын еракларга җиткерделәр һәм җиткерәләр.

Әйе, укымышлы һәм белемгә тартылучы да, кеше һем хезмәт сөюче дә, моң-җыр яратучы һөм сәнгатькә омтылучы да, җитез һәм тапкыр да, горур һәм намуслы да, киң һәм ачык күңелле дә, тиз аралашучан һәм чибәр дә ул Бәзәкә халкы.

## БӘЗӘКӘ ШӘҖӘРӘСЕ

Авылның ничәнче елда, ничәнче гасырда барлыкка килүе һәм кемнең аңа нигез салуы турында төгәл, документлар белән беркетелгән белешмәләр, кызганычка каршы, юк. Шунысы билгеле, Бәзәкә

авылы - күптән яшәп килә торган, Татарстан территориясендәге иң карт авылларның берсе. Моның турында Бәзәкә муллалары берничә гасыр алып барган авыл кешеләренең шәҗәрәсе сөйли. Дөрес, беренче дәфтәр 1934 елгы янгын вакытында янган. Исән калган кәгазьләр буенча авыл шәҗәрәсен мулла Шакиров Таҗетдин -яңадан торгызган. Шәҗәрәгә башта 37 нәсел башында торучылар язылган булган. Ләкин Бәзәкәгә читтән килгән кешеләр даими өстәлеп торганнар. Шулай итеп 1929 елга кадәр шәҗәрәдә 102 нәсел башлыгы теркәлгән. Шәҗәрә бары тик туган ир балалар буенча гына алып барылган. Шәҗәрәне кем һәм ничәнче елны яза башлаулары турында бер мәгълуматта сакланмаган. Шулай да шәҗәрәне башлап җибәргәндә 37 кеше арасында берсе Таһир исемле кеше булганы билгеле. Аның турында шәҗәрәдә «Таһир бабай 1545 елда вафат»,- дип язылган. Моннан чыгып Бәзәкәнең (хәзерге авылның) якынча яшен чамалый алабыз (2000- 1545 = 455). Моңа Таһир бабайның яшәгән елларын да кушсак авылга 500ләп яшь килеп чыга.

Бәзәкә шәҗәрәсен авыл барлыкка килгәч тә түгел, ә соңрак алып бара башлаганнар. Моны нәрсәдән чыгып әйтәбез: Таһир - белән рәттән Исхак бабай нәсел агачы язылган. 1930.елга кадәр Исхак бабай нәселендә 170 тән артык кеше исәпләнгән. Бүгенге көндә Бәзәкәдә Мөхәррәмнекеләр нәселеннән гаилә яши. Тик шәҗәрәдә Мөхәррәм язылмаган. Димәк ул шәҗәрәне башлап җибәргәнче үк яшәгән, халык арасында яшәүче юрамалар буенча ул авылга нигез салучыларның да берсе.

Бәзәкә шәҗәрәсе бүгенге көндә хезмәт һәм сугыш ветераны, укытучы Фәйзелхак Хөснетдиновта саклана. Үзләренең ерак бабаларының исемнәрен белергә теләүчеләр булса, аңа мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

**БӘЗӘКӘ ИСЕМЕ КИЛЕП ЧЫГЫШЫНА КАРАШЛАР**

Бәзәкә авылы исеменең килеп чыгышы турында халык арасында берничә караш яшәп килә: «Бәзәкәгә Белоус авылыннан им-том итеп йөрүче Бизәкәй дигән әби килеп яши башлаган. Авылда аны бик хөрмәт иткәннәр. Авылга шуның исемен биргәннәр, имеш». - Тик Белоус Кама елгасы өстеннән пароходлар йөри башлагач кына

барлыкка килгән авыл. Елга өстендә маяк лампалары яндырып торучы Белоусов анда яши башлагач кына бу’авыл барлыкка килгән. Бәзәкә инде аңа кадәр берничә гасыр элек яшәгән авыл. Моны Бәзәкәнең шәҗәрәсе әйтеп тора. Бу риваятьне икенче төрлерәк та сөйләүчеләр бар: «Иң беренче булып авыл урынына Бөдрикә исемле бер карчык килеп утырган. Бу карчык кешеләрне, хайваннарны дәвалаган. Хөрмәт йөзеннән халык авылга аның исемен биргән. Авыл исеме Бәдрикәдән әкренләп Бәзәкәгә әверелгән имеш».

Элегрәк «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә безнең авылның исеме турында кызыксынып сорау биргән идек. Озак көттерми шул газета исеменнән безнең сорауга профессор Г.Ф.Саттаров җавап бирде: «Сезнең авылның исеме Бәзә дигән кешенең исеменнән алынган булырга тиеш. Аны хөрмәт итү йөзеннән иркәләп Бәзәкәй дип йөрткәннәр булса кирәк, ә тора-бара кыскартып авылны Бәзәкә дип йөртә башлаганнар...»

Гарәп теленнән кайтарганда «Бәзә» - «байлык, хәзинә» дигән мәгънәне, «кәй» - иркәләп мөрәҗәгать итүне аңлата..Чынлап та, Чулман сулары басканчы, авылның тирә-юне чын хәзинәгә бай иде: әрәмәдә үскән җиләк-җимеш, чикләвек дисеңме,

балыклы күлләр, хуш исле печәнле болыннар дисеңме... Тал чыбыгыннан кәрҗин үреп, балан һәм гөлҗимеш җыеп, аларны сатып, болыннарда һәм әрәмәдә үскән җир җиләгеннән, карлыганнан, бөрлегәннән, кура җиләгеннән һәм чиядән варенье ясап, как коеп, байтак кына кеше табыш ясый иде.

Авылның исеме килеп чыгышына болай килгәндә аны «бизәкле» сүзеннән чыгып та аңлатыргд була: «Хәзерге авыл урынында элек урман булган. Монда күчеп утырган халык урманны кисеп узләренә йортлар җиткергән. Тирә-юнь бик матур, бизәкле булган. Шуңа курә авылны Бизәкле дип атаганнар». Бизәкледән Бәзәкә сүзе килеп чыккан булырга мөмкин.

Бер юрама Бәзәкә белән Сәйтәк авылларын «туганлаштыра»: «Сәет исемле кеше җитәкчелегендә билгесез яктан кешеләр килеп чыкканнар. Чәчүлек кыры итәрдәй җирләрне кургәч, Сәет бу кешеләрне ике төркемгә бүлгән. Бер төркемне хәзерге Сәйтәк урынына, икенчесен хәзерге Бәзәкә белән Псәй авыллары арасындагы ' «Көчәнде» кыры тирәсенә урнаштырган. Сәет үзе беренче төркем белән калган. Бу авылга Сәет исеме бирелгән. Икенче авыл кешеләре чәчүлек җирләрен «Сәетнеке» һәм «Безнеке» дип йөрткәннәр. Шул «Безнеке» дигән сүздән тора бара «Бәзәкә» исеме килеп чыгарга мөмкин». - Уйлап карасаң, ,бу юрамада бер тарихи- географик үзенчәлек бар: Псәй авылы белән Бәзәкә арасындагы бер басу хәзер дә Сәет тарлавы дип йөртелә. Димәк, кайчандыр Сәет исемле кеше яшәгән һәм аның кешеләре бу басуны урманнан әрчеп чәчүлек җире ясаганнар. «Сәет» гарәпчәдән «изге» дип кайтарыла. Хәзерге Сәйтәк авылы кырында изге чишмә ага, якын-тирә кешеләре дәва өчен шул чишмә суын алырга килеп йөриләр. Ул чишмә Сәет исемен йөртә. Күрше Сәйтәк авылының исеме «Сәет+әкәй» сүзләреннән килеп чыгуы ихтимал...

Тагын бер караш - укытучы-пенсионер Фәйзелхак Хөснетдинов искә ала: «Мин, Алабуга педагогия техникумының тарих факультетында укыганда, борынгы болгар халыкларының тормыш-көнкүреше белән таныштым. Борынгы болгарлар игенчелек, терлекчелек, аучылык һәм башка эшләр белән шөгыльләнгәннәр. Җәйгә чыккач, алар терлекләрен ерак болыннарга куып алып килгәннәр. Шунда җөйләүләр ясап, җәйләрен шунда

уздырганар, ә көз җиткәч, терлекләрен куып авылларына кайта торган булганнар. Техникумда укыганда безгә «Волжско- Камские болгары» исемле бер тарихи картаны күрсәттеләр. Ул картада Болгар шәһәрчеге тирәсендә Бәзәкә дигән ике авыл барлыгын күрдек, ләкин бу авыллар хәзерге Бәзәкәдән еракта урнашкан». - Тарихи фәнни тикшеренүләр күрсәткәнчә, чыннан да Болгар дәүләте җимерелгәч, исән калган халык Кама буена төньяк-көнчыгышка килеп утырган. Әйтеп кителгән Бәзәкә авылларыннан кешеләр безнең якларга күчкән булулары мөмкин. КамГЭС сулары Бәзәкә тирәсен басканчы, Чулман юнәлешендә өч километр ераклыкта «Иске Бәзәкә тамагы» дигән бер җир бар иде. Авыл халкы Бәзәкә элек шунда урнашкан булган дип уйлый. Бу хакта «Менделеевск яңалыклары» газетасында (1987 ел, 10 октябрь) Р.Мирзаянова да болай дип язган иде: «Кама буендагы авыл «Иске Бәзәкә» дип аталган...».

Кайбер туган якны өйрәнүче галимнәр фикеренчә, урта һәм ХУ1-ХУШ гасырларның топонимик материаллары Көнчыгыш Европа халыкларының этногенетик процессында угорларның катнашуы турында сөйлиләр. Безне бигрәк тә Көнчыгыш Кама буе топонимиясенең фин-угор пластының угор- самодий элементлары турындагы топонимик белешмәләр кызыксындыра. Менделевск, Алабуга һәм Әгерҗе районнары Көнчыгыш Кама буе регионына керәләр һәм, фәнни эзләнүләр күрсәткәнчә, бу районнарда Кама буе авыллары, елга-күлләре, әрәмәлекләре, урманнары исемнәрендә топонимиянең угор-самодий элементлары киң урын алалар. Алабуга педагогия институты профессоры, филология фәннәре докторы Л.Ш.Арсланов - Алабуга шәһәре тирәсендә урнашкан авылларның килеп чыгышын өйрәнгән галим. Аның фәнни эзләнуләре нәтиҗәсендә/ якын- тирә исемнәренең килеп чыгышын түбәндәгечә аңлатырга була: «Бәзәкә», «Пинәрә», «Кәдәнгеш», «Пәдәнгеш» ише исемнәр фин-угор теленнән килеп чыкканнар.«Бәз» - «су» дигәнне аңлата. Икенче галим А.К.Матвеев фикеренчә, шул ук мәгънәне анлатучы «Биз», «Бизәр», «Бизәркә» исемле елгалар да бар. «Пинәрә»(су басканчы шундый күл бар иде) сүзе угор теленнән кайтарганда «таллар белән уратып алынган су» мәгънәсен аңлата. «Ар юлы» дигән

урын да бу тирәдә элек удмуртлар (фин-угор этник группасыннан) яшәгәнен күрсәтә. Ар - удмурт халкына татарлар биргән исем. Картлар сөйләвенчә, чынлап та элек бу җирләрдә «арлар», марилар яшәгәннәр, Бәзәкәлеләр аларны төньякка куып җибәргәннәр. Бәлки элек Бәзәкә удмурт яисә мари авылы булгандыр, аңа төрки халык күчеп утырырга мөмкин...



Топонимик параллельләр Удмуртиянең Алнаш районында, Татарстанның , Әгерҗе һәм Сарман районнарында бар.

Шулай итеп хәзерге вакытка авыл исеменең фин- угор теленнән килеп чыгу мөмкийлеген фәнни яктан дөресрәк дип исәпләргә була. Тарихи эзләнүләр күрсәткәнчә, Болгар дәүләте булган җирләрдә дә элек фин-угор кабиләләре яшәгән. Ләкин шулай булуга да карамастан, Бәзәкә исеменең килеп чыгышын фәнни яктан чыгып аңлату кирәк. Шуңа күрә алдагы елларда Киров, Казан, Пермь, Уфа, Санкт-Петербург, Мәскәү архивларында һәм музейларында махсус эшләү һәм галимнәр белән аралашу зарури.

## АВЫЛНЫҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ҺӘМ ҮСЕШЕ ТАРИХЫ

Тәгаен, авылның, төбәкнең тарихын бәян итү өчен башта регионның гомуми тарихы белән танышу кирәктер. Тик Татарстанның төньяк-көнбатыш тарихы турында материаллар арасында безнең төбәк турында мәгълүматлар, низамнамәләр юк дәрәҗәсендә. Күп кенә тарихчыларыбыз өчен дә бу хәл һаман да табышмак булып кала бирә.

Инде булган материалларга күз салыйк.

Татар халкынын этник нигезләре Урта Идел һәм Урал буе территориясендә барлыкка килгән. Шуңа күрә татар халкының формалашуына ярдәм иткән борынгы тамырларны археологлар, этнографлар һәм антропологлар шушы территориядә эзлиләр дә.

Тел, мәдәният һәм беркадәр дәрәҗәдә антропологик кыяфәт буенча Идел буе татарлары барыннан да элек башкортларга, казакъларга, үзбәкләргә һәм башкаларга якын торалар. Шулай булгач, татар халкының этногенезында төрки халыкларга бәйле этник катлам хәлиткеч роль уйнаган диясе килә. Ләкин шул ук вакытта

галимнәр татар халкы мәдәниятендәге кайбер элементларның һәм антропологик яктан кайбер билгеләрнең фин- угор халыклары - марилар, удмуртлар һәм башкаларның мәдәни һәм антропологик үзенчәлекләре белән охшаш булуын күрсәтәләр. Шуңа күрә фин-угор кабиләләренең дә татар халкының этногенезында күпмедер дәрәҗәдә катнашканлыгын исәпкә алмыйча мөмкин түгел.

Әле күптән түгел генә кайбер галимнәр, Урта Идел һәм Урал буйларына төрки кабиләләр кайчан үтеп кергән дигән сораугa: безнең эраның УП-УШ гасырларында бу якларга болгарлар күченеп килгән һәм алар беренче төркиләр булганнар, дип җавап бирәләр иде. Табылган яңа материаллар төркиләрнең бу якка килеп чыгуларын Ш-1У гасырларга чигерергә мәҗбүр итә. Дөрес, элегрәк төрки кабиләләрнең Урта Идел, Урал буйларына Ш-У гасырлардан да иртәрәк үтеп керүләре, хәтта төрки халыкның беркаян да күчеп килмичә, гомер буе шушында яшәгән халык булуы турында фикерләр әйтелде. Ләкин бу фикерләр әлегә кадәр бернинди дәлил белән дә исбатланмый. Археологик материаллар күрсәткәнчә, Урта Идел һәм Урал буе территориясендә яшәүче җирле халыкның этник- мәдәни усешендә Ш-1У гасырларга чаклы җитди үзгәрешләр булмый һәм бу гасырларга кадәр фин- угор халыклары чагыштырмача тыныч этник тормыш белән яшәгәннәр.

Урта Идел һәм Урал буйлары фин-угор халыкларының борынгы җирләре булып тора. Идел һәм Чулман буйларына кеше таш гасырының иң әүвәле чорында, ягъни моннан йөз мең еллар элегрәк килеп чыга. Монда ул мезолит, неолит, бронза чорларын һәм тимер гасырын кичерә. Нәкъ менә шушы чорда - әүвәлге тимер гасырында хәзерге заман фин-угор халыкларының этник нигезләре формалаша. Менә шушы вакытларда Көнчыгыш Европаның урманлы җирләрендә яшәүче халыклар арасына монголоид типлар үтеп керүе мәгълүм. Европеид һәм монголоид компонентларның кушылуы нәтиҗәсендә, неолит чорында, ягъни безнең эрагача 4-3 мең елларда Урал тибы, яисә субпланоид тибы дип аталган үзенчәлекле катнаш антропологик тип барлыкка килә. Бу тип соңыннан күп кенә фин-угор халыклары (биграк тә мари һәм удмуртлар) өчен хас типка әйләнә. Марилар, удмуртлар һәм аларга якын булган кабиләләр аша бу тип

шулай ук татар халкының антропологик составына да үтеп керә. Әкренләп фин-угор халыкларының антропологик тибында монголоидлык арта төшә, һәм менә бу хәл соңга таба көнчыгыш кабиләләрнең Урал аша чыгып, Чулман, Идел буйларында утракланып калуына уңай җирлек була.

Тарихта билгеле булган төрки халыкны «гун» яисә «хунну» дип атаганнар. Безнең эрагача 111 гасыр азакларында гуннар, күчмә халыклар арасында беренче буларак, Үзәк Азиядә үзәкләштерелгән дәүләт төзиләр. 1-1У гасырларда гуннар Көньяк Урал һәм Түбән Идел аша Көнчыгыш Европага үтеп керәләр. Идел-Чулман буйларында, гуннарның үзләреннән дә бигрәк, гуннар хәрәкәте аркасында үз җирләреннән кузгалган башка кабиләләр күбрәк була. Бәзәкәдән берничә километрда урнашкан Турай авылы янында курганнарда табылган 1У-У гасырлардагы сугышчы күчмә халыклар баш киеме һәм коралы безнең якларда бу халыкларның килеп урнашуы турында сөйлиләр.

Идел-Чулман буена багышланган фәнни хезмәтләр белен танышканнан соң, бер гаҗәеп материалга тап булдым. Идел-Чулман мәдәниятенең неолитик истәлекләре картасында Идел буенда Чулман тамагы тирәсендә (хәзерге Казан һәм Ульяновск арасында) 12 Бәзәкә стоянкасы ( кешеләр торган урын) төшерелгән. Академик А.Х.Халиков фикеренчә, 1 Бәзәкә стоянкасы (Базяковский взвоз) неолитик мәдәниятенең башлангыч вакытына кертелә. Академикның «Древняя история Среднего Поволжья» (М.,1969) дигән китабының 46, 57, 290 битләрендә хәтта Бәзәкә стоянкасында табылган кораллар рәсеме дә бирелгән. «Безнең эрага кадәр 1 мең еллар һәм безнең эраның 1 мең еллар археологик картасында» Бәзәкә 500 еллар тирәсендә яшәгән авыл итеп бирелгән. Картада авыл Иделдән ерак, Зөя елгасы буенда урнашкан итеп күрсәтелгән. Шундый ук карта «Татарстан АССР тарихы» (Казан, 1959) китабында да бар (33 бит).

УШ гасыр урталарында Урта Идел һәм Түбән Чулман буйларына болгарлар күчеп утыра башлый.

Бу урыннарда яшәүче имән-кискә кабиләләре һәм урман араларындагы фин-угор кабиләләре болгарларны башта Идел ярлары буеннан ары китәргә ирек бирмиләр. Тик шулай да алар бер- берсе белән якыннан аралаша

башлыйлар.

Болгар дәүләт булып 1Х-Х гасырларда формалаша башлый һәм ХП гасырда Болгар дәүләтенең бердәм территориясе формалаша. Болгар халкы әкренләп Чулман буеның төньягын үзләштерә башлый һәм безнең якларга да килеп җитә.

Шунысы кызыклы, археологик эзләнүләр нәтиҗәсендә Болгар дәүләте территориясендә 250 гә якын болгар авылы һәм шәһәренең калдыклары табылды. Бу истәлекләрнең күбесе Зөя бассейнында урнашкан. 1955 елда чыккан «История Татарской АССР» (т.1) китабында «Булгарские археологические памятники Х-Х1У вв. в пределах современной Татарии» дигән картада һәм авыллар исемлегендә Бәзәкә авылы күрсәтелгән. Шул ук китапта бирелгән «Казан ханлыгы картасында» Бәзәкә исеме инде бирелмәгән (Бәзәкә авылы «Татарстан АССР тарихы» китабында урнаштырылган картада да бар). Шулай итеп алда әйтеп үтелгән Фәйзелхак абый Хөснетдинов карашы дөрес булырга, Бәзәкә болгар авылыннан кешеләр Болгар тар-мар ителгәч безнең якларга күчеп утырырга мөмкин. Иске Бәзәкә урыны бабаларыбызның беренче килеп урнашкан җиредер бәлки.

Халык арасында яшәп килүче риваятьләргә караганда, Бәзәкә авылына нигез 1390 елда салынган. Авылга нигез салучыларның исемнәре - Мораттай, Сәмәкәй һәм Мөхәррәм. Алар Болгар җирләреннән килгәннәр. Соңырак аларга тагын берничә болгар гаиләсе килеп кушылган. Тарих битләрен актарып карасак, чынлап та болгарлар саны безнең якта Федор Пестрый җитәкчелегендәге урыс дружиналары Болгар шәһәрен җимергәч 1431 елдан соң арта башлаган. Исән калган кешеләр төньяк-көнчыгышка, Каманың уң ягына күчкәннәр. Бу якларда удмуртлар һәм марилар яшәгән булган. Шуңа күрә алар күчеп килгән безнең бабаларыбыз белән сугышып торганнар. ХУ гасырның икенче яртысында Казан ханлыгы төзелгәч, бу җирләр юридик яктан татарларга бирелгән.

Болгарларның бу якка килеп утыруы турында хәзерге авылдан 1 км ераклыкта куелган болгар кабер ташы таныклый. Бәзәкә шәҗәрәсендә дә болгар исемнәре очрый: Лачын, Аманай һ.б. Тик чынлап та авыл 1390 елда барлыкка килгәнме, юкмы, ышанычлы мәгълүматлар булмагач, әйтүе кыен. «Татар энциклопедия сүзлеге» битләрендә исә Бәзәкә авылына ХУП-нче гасырның

беренче яртысында нигез салынган дип язылган (Татарский энциклопедический словарь. - Казань, 1998, с.76). Тик бу саннар дөреслеккә туры килми, сүзлеккә патша Екатерина П заманында официаль рәвештә авылларны теркәү даталары кертелгән, ә авыллар инде күптән яшәгән булган.

Әйтергә кирәк, авылның килеп чыгышы турында халык арасында шулай ук төрле юрамалар яши:

«Авыл башта Иске Бәзәкә урынында, Кама елгасы буенда урнашкан. Кама елгасы агу юнәлешен үзгәртүе яисә билгеле булмаган сәбәпләр аркасында әби-бабаларыбыз тау битләренә (хәзерге «Умарталык» дип аталучы урынга) килеп урнашканнар. Аннан соң авыл хәзерге урыннан бер 3 километр төньяккарак күчкән. Моны дәлилләү өчен аның иске зират ташлары әле хәзердә исәннәр. Ул вакытта авыл кара урман эчендә урнашкан булган. Соңрак авыл хәзерге урынга күчкән. Бу күченүнең ничәнче елларда булуын әйтүе кыен, ләкин шулай да муллаларның шәҗәрәсенә караганда ул 1550 еллар тирәсендә булган».

Авылның чынлап та берничә урын алыштыруы мөмкин. Моның турында авыл тирәсендәге атамалар уйланырга мәҗбүр итәләр. «Иске Бәзәкё» урыны, Умарталыкта чияләр усө торган тау буе, «Йорт урыны», «Тиҗек» басуы халык телендә авыл урыннары булып исәпләнәләр.

1932 елдаКәлимуллин Сәлимулла һәм Әхмәдиев Мөхәмәтҗан исемле ике карт Хөснетдинов Габделхакка васыять итеп калдырган хикәяләргә караганда, бу тирәдә тагын берничә авыл 'яшәгән: «Хәзерге Тукмаклы тирәсендә Татар Көчәнде һәм Мари Көчәнде, шулай ук Тиҗек авыллары урнашкан булган. Тиҗек Тукмаклыдагы авылдан аерылып чыккан хутор дип тә исәпләнә. Авыл зур булган, ләкин ул тиздән билгесез сәбәпләр нәтиҗәсендә таркалган». Әйтергә кирәк, колхозчылар бу тирәләрне сукалаганда еш кына кабер ташлары килеп чыккалаган.

1951-1952 елларда бу якларда археологик экспедиция эшләгән. Профессор Воробьев мондый нәтиҗәгә килгән: «Мин Бәзәкә тауларында үсүче кыргый чия агачлары курдем. Татарстан территориясендә кыргый чияләр биш җирдә генә очрыйлар һәм безнең климат өчен

алар хас түгел. Кыргый чия, алма, кура җиләге Булгар городищелары булган җирләрдә табылдылар» (Материалы по истории Татарии.- Казань, 1965, с. 117). Курәсең, бу агачларны булгарлар яңа җирләргә алып килеп утыртканнар ,һәм үстергәннәр. Бәлки Бәзәкә әрәмәлегендә үсүче чия, карлыган, күгән агачлары безнең борынгы болгар бабаларыбыз утырткан агачлардыр. Дөрес, ул тирә «Умарталык» дип атала, анда колхоз умарталыгы булган. Бу агачлар махсус утыртылырга да мөмкин.

Хәзерге урынга урнашкан Бәзәкә авылында 37 хуҗалык исәпләнгән. Авыл хәзерге сыман зур булмаган. Гыйззәтуллин Гыйлөҗетдин йортыннан алып «түбән очк&» кадәр бер урам булган. Йортлар инешкә каратып салынганнар.

Бәзәкәгә Казан ягыннан килгән кешеләр даими өстәлеп торганнар. Шуңа күрә Бәзәкә кешеләре ике төрле атама белән йөртелгәннәр: «башкортлар», «типтәрләр». «Башкортлар» дип элек-электән Бәзәкәдә яшәп, җир биләмәләре булган кешеләрне,  «типтәрләр» дип Казан ягыннан күчеп килгән кешеләрне атаганнар. Типтәрләргә җир бирелмәгән. Алар һөнәрчелек, батраклык белән шөгыльләнгәннәр. Чагыштыру өчен: күрше Псәй авылы да ике общинадан торган (йомышлы татарлар һәм башкорт-типтәрләр). Бу турыда «Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» (Казан, 1995, 180- нче бит) китабында язылган.

Бәзәкә халкының бүгенге сөйләм диалектын карасак, ул башкортлар сөйләменә тартым. Әдәби татар телендәге «ый», «и» кушымчаларын Бәзәкә халкы буген дә әле «ай», »әй», белән сөйләшә ( бармый -бармай, килми - килмәй, абый - абай һ.6.). Бәзәкә кешеләре сөйләмендә «иде» дигән сүз «и» белән алмаштырыла («барган иде» -«барган и», «килгән иде» - «килгән и» һ.6.), сүзләрдә »з» авазы «д» авазы белән әйтелә (Бәзәкә кызлары - Бәдәкә кыдлары).

Борынгы заманнарда бу җирләр урманнар белән капланган булган. Крестьяннар зур балталар белән урман кисеп, аны яндырып иген үстерер өчен кырлар хәзерләгәннәр. Көлне дәүләткә тапшырганнар. Ул элеккеге урманнардан хәзерге көндә Тукмаклыда һәм Умарталыкта үсүче чикләвек агачлары гына калган.

1552 елда явыз патша Иван Грозный Казан ханлыгын басып алгач, татар җирләренә күпләп урыслар күчеп утыра башлаганнар. Бәзәкә тирәсендә Икское Устье (Ык тамагы), Ижовка рус авыллары барлыкка килгән. Руслар Бәзәкә кешеләрен Ык Тамагына күчермәкче булганнар, чөнки Бәзәкә җирләре инде агачтан чистартылган, эшкәртелгән һәм уңдырышлы булган. Ләкин авыл халкы моңа каршылык күрсәткән.

Патша христиан динендә булмаган Урта Идел буе халыкларын чукындырырга боерык чыгарган. Иван Грозный ялчылары татарларны да көчләп чукындырган. Сәйтәк авылы кешеләре христиан диненә күчерелгәннәр. Бәзәкә халкы, бабайлар сөйләвенә караганда, татарларны чукындыру өчен җибәрелгән хәрби экспедиция килгәнен белеп, авылны ташлап кара урман эчендәге чокырларга

качып яшәгән. Тукмаклы янында хәзер дә «Кызлар чокыры» дигән урын бар. Хатын-кызлар монда киндер сукканнар. Анда кызларны качырып тотканнар. Ирләр атларга атланып авылга кайтып килә торган булганнар. Иван патша отрядлары авыл халкын тапмыйча, буш урамнарга, кешесез йортларга юлыгып, Кама буйлап югары менеп киткәннәр.

Төрле динле булу аркасында Бәзәкә һәм Сәйтәк халкы арасында дуслык беткән. Бәзәкәлеләр Озын Тау базарына барганда-кайтканда сәйтәклеләр еш кына юлга чыгып аларны талый торган булганнар.

1798 елда авыл халкы башкорт-мещеряк гаскәре составына кертелгән. 1780 елдан 1921 елга кадәр Бәзәкә авылы Вятка губерниясенең Алабуга уезды Салагыш волосте составында булган. «Башкорт» авыллары, шул исәптән Бәзәкә дә Уфа шәһәрендә һәм Салагыш авылында (хәзерге Әгерҗе районындагы авыл) урнашкан башкорт-мещеряк гаскәренең югары органнары тарафыннан идарә ителгәннәр. 1860 елда башкорт гаскәре бердәйләштерелгән, ә 1863 елда таратылган. Бәзәкә крестьяннары дәүләт карамагына күчерелгән.

Ул заманнарда яшәгән бабаларыбыз турында А. Анастасиевның «Вятские инородцы и ихъ школы» дигән китабында татар халкына бирелгән кызыклы характеристика бар: «Вятка татарлары күбесенчә губерниянең көньяк уездларында торалар ( Малмыж уездында 60353 җан яисә 20,44 процент, Алабуга уездында 35895 җан, 15,24 процент...). Вятка татарлары - чагыштырмача пөхтә, чиста һәм шактый матур халык: аларның йөзе кара кучкыллы, борыннары туры, күзләре кысынкырак, колаклары зур һөм тырпаеп тора. Тигез итеп кырылган башларына татарлар түбәтәй киеп йөриләр. Кием булып аларга озын ситсыдан тегелгән һәм киң җиңле күлмәк, бишмәт, киң штаннар, ә башка кыш көннәрен түбәтәй өстеннән бәрән йонынннан ясалган бүрек яисә киез эшләпә хезмәт итәләр. Муллалар чалма киеп йөриләр. Хатын-кызлар күлмәк өстеннән алъяпкыч, тәңкәләрдән торган күкрәкчә йөртәләр. Ә башларында - шәл, үвәл, ир-ат алдында шуның белән күзләрен генә калдырып йөзләрен каплыйлар. Татарларның өйләре ике тигез булмаган өлешкә бүленә: зур өлеше - ирләрнеке, кечерәге - хатын- кызларныкы. Өстәл, урындык, эскәмия ише әйберләр юк, татарлар

сәкеләрдә яисә кеше озынлыгы хәтле ләүкәләрдә ашыйлар, эчәләр һөм йоклыйлар. Бу сәкеләр бөтен алгы стена буйлап сузылган һәм тушек, ястык, мендәрләр белән тулган. Йоклар өчен мич кырында сәндерәләре дә бар.



Татарлар эшкә чыдам, сабыр һәм түзем, шулай булуга карамастан ярлы яшиләр. Төп сәбәбе - җир эшләрен бик яратып бетермиләр, җиңел эш эзләргә яраталар. Алар ислам динендә. Кешеләр арасында килеп чыга торган низахларны муллалар чишәләр. Мөселманнар үз диннәрен бирелеп тоталар, аңа фанатик табыналар. Характер ягыннан Вятка татарлары - җитез һәм аралашучан, зирәк зиһенле, тапкыр, өлгер халык»,- дип язган А.Анастасиев. (Вятские инородцы и ихъ школы, Москва, 1902, с. 82- 86 - тәрҗемә кыскартып алынды - автордан).

Бәзәкә халкы башка татар авылларындагы кебек үк авыр тормышта, фәкыйрьлектә яшәгән. Авылның җире бик аз, өйләр салам түбәле, читән белән уратып алынган, өйләрдә җиһазлар аз һәм начар булган. Халык игенчелек, терлекчелек, бакчачылык белән шөгыльләнгән. Бәзәкә кешеләре турыдан туры дәүләт карамагындагы крепостной крестьяннар булганлыктан, авылда алпавытлар булмаган. Дәүләт салган налогларны авыл халкы үзләре үстереп җыйган уңыш һәм акча белән түләгән, барщина үтәмәгән. Зурларның сөйләвенә караганда, ясак түләмәгән өчен кешеләрнең түшәкләрен, самовар, хәтта казаннарын кубарып алып чыга торган булганнар.

Бәзәкәдә шулай да халык саны арта барган. Типтәрләргә җир бирелмәгәч, күбесе яңа җирләргә күчеп киткән. Беренче тапкыр хәзерге Актаныш районына күчкәннәр. Анда «Иске Курмаш» дигән авыл бар. Ул авыл кешеләре үзләрен Бәзәкәдән күчкән дип исәплиләр. Икенче тапкыр Бәзәкәдән хәзерге Әгерҗе районына күчеп киткәннәр. Анда барлыкка килгән авыл хәзер дә «Яңа Бәзәкә» дип атала. Өченче мәртәбә күченү хәзерге Сарман районына булган. Анда «Бәзәкә» дигән авыл бар, икенче төрле «Шикәрле Каен» дип йөртелә. Бу авылга күченү үзенчәлекле: картлар сөйләвенчә, теге ике авылга типтәрләр үз теләкләре белән кучкәннәр, ә Шикәрлё Каенга авылдан усалрак булган типтәрләрне куып^ җибәргәннәр. Кайчан күчкәннәре билгесез. Ә шулай да

фикер йөртергә була: 1930 елда шул авылдан Бәзәкәгә бер 80 яшьлек карт килгән. Ул болай дип сөйләгән: «Минем бабайның атасы шушы сезнең авылдан егет чагында киткән булган. Аның сөйгән кызы Зөләйха Бәзәкәдә калган. Ике иптәше белән бабай Кама кичеп, Бәзәкәгә килеп Зөләйханы урлап киткән...»

Бәзәкә авылы аркылы Емельян Пугачев гаскәрләре узуы да халык телендә сакланган. Аны әбиләр: «Безнең бабайлар авылдан Пугач явы узуын сөйлиләр иде»,- дип иска алалар. Авыл халкы Пугачев хәрәкәтендә катнашмаган, тик шулай да башка авылларда алпавытларның утарларын талаганда, яндырганда Бәзәкәдән китеп аларга булышучылар булган.

Авыл зурайган, еллар уткән саен яңа өйләр, урамнар хасил булганнар. Х1Х гасыр азагына авыл территориясе бүгенгедән зурырак булган. Куп өйләр салам түбәле, коймалар җиткерелмәгән. Хуҗалыклар читән белән уратып алынган. Авылда байлар ләфкәләр ачканнар һәм сирәк очрый торган товарлар алып кайтып сәүдә иткәннәр. Бәзәкәлеләр Озын Тау ( Тихие Горы) һәм Алабуга базарларына барып шикәр, тоз, шырпы, кием-салым, бизәнү әйберләре алып кайтканнар, үзләре икмәк һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары сату белән шөгыль иткәннәр. Авылның ике очында биек манаралы ике мәчет салынган. Иртән азан әйткән тавышлар ишетелә башлаган. Бәзәкәдә беренче мәчет 1847 елда Казан сәүдәгәре Исхак Мустафин тарафыннан җиткерелгән. Бәзәкә халкы борынгыдан белемгә тартылган. 1865 елда авылда земство карамагындагы мәктәп ачылган. Авылда дини корбан, ураза, гашүрә, алан җыены бәйрәмнәре уткәрелгән. Уразага кергәч авыз ачар алдыннан кич кешеләр мәчет янына җыела торган булганнар. Картлар үзләре белән оныкларын да алып килгәннәр. Халык җыелып беткәч, мулла мәчет манарасына менеп азан әйткән, шуннан соң кешеләр «Мулла азан әйтте»,- дип таралышканнар...

Әкренләп ярлылар азайган, авылда күбесенчә бай һәм урта хәлле кешеләр яшәгәннәр. Гаиләләрнең берничә аты, сыеры, күп кенә сарыклары, каз- үрдәкләре булган. Ә кичләрен чыра яндырып яшәсәләр дә, авыл халкы үз өйләрендә уңайлык, ямьлелек, җыйнаклык ясарга тырышкан.

Киров дәүләт архивы материаллары күрсәткәнчә, 1842

елда Бәзәкәдә 855 башкорт һәм типтәр яшәгән.

1892 елга халык саны 1877-гә җиткән, авылда 312 хуҗалык исәпләнгән. Чагыштыру өчен: икмәк сату һәм аны ташу үзәге булган Ык Тамагы авылында 1887 елда 848, 1892 елда 975 кеше, күрше Мари Тәкәш авылында 1887 елда 47 кеше, 1911 елда 77 кеше, Сәйтәктө 1864 елда 400, 1887 елда 731 кеше яшәгән. Турай һәм Псәй авылларында XX гасыр башына меңгә якын кеше булган. Шуна күрә гасыр башында Бәзәкәне күрше-тирә авылларда «мең душлы» авыл дип йөрткәннәр. Бер «душ» дип 2 ир аталган. Хатын-кызлар исәпкә кертелмәгәнен дә исәпкә алсак, авылда берничә мең кеше яшәгән.

X1X гасыр азагы - XX гасыр башы авыл кешеләре өчен авыр вакыт булган. Бу күрше-тирәдә капиталистик хуҗалык итү формалары туу белән бәйле. Авылда да капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлаган. Моның турында түбәндәге саннар сөйли: XX гасыр башында Бәзәкәдә атсыз хуҗалыклар - 40 процент, бер ат белән - 30 процент, 2 ат белән -20 процент, 3 һәм аннан артык - 10 процент булганнар. Хезмәт кораллары примитив хәлдә, шуңа күрә җир эшкәртү түбән булган. 1867, 1877, 1883, 1891 елларда ашлык уңмаган. 1892 елда авылда 50 кеше холера белән чирләгән, шуларның 22-се вафат булган. Бигрәк тә ярлыларның хәле авырайган. Гаиләләрен туйдыру өчен, ир-атлар иртәдән алып кичкә кадәр байларга ындыр сугып көненә 15 тиен акча эшләгәннәр, күрше авылларга барып эшка ялланганнар. Кайберләре балаларына ашатыр әйбер тапмагач, яз чәчкән уҗымнарын да сатарга мәҗбүр булганнар. Ә җир ул чагында һәркемнең узенеке, үзе чәчеп үзе ашлык үстергән. Авылда байлар хөкем сөргән. Мөсир Шәйгәлламов, Төхвәтовлар (исемнәре билгесез) чәй-шикәр белән сату иткәннәр, ә Гыйлаҗ исемле кеше кулында галош-ситцылар булган. Авылда калач пешереп сатканнар. Бәзәкәдә берничә кибет булган. Шуларның иң зурысы «Кәшби лавкасы» дип йөртелгән. Ул хәзерге кабул итү пункты кырындагы тыкырыкта урнашкан булган.

Байларның ярлыларга карата булган мөнәсәбәте турында Фәйзелхак Хөснетдиновның «Байлык корбаны» дигән хикәясе бик ачык итеп сөйли. Ул хикәяне авторның рөхсәте белән тулысынча бирәбез:

—Кәшби абзый, мәрхәмәтеңнән ташлый күрмә, балаларым ач утыра, яңа уңыш җиткәч ике өлеш итеп түләрмен.

Алдында билдән бөгелеп торган сәләмә киемле крестьянга Кәшби бай эре гена карап ала, шактый ялындыра, аннан соң гына зур амбарының четерекле йозагын ачып, бер подаука он кутәреп чыга.

Һәр көнне шулай кабатлана. Бөлгенлеккә төшкән ярлы крестьяннар бурычка он сорап кына түгел, актыккы җирләрен, болыннарын сатарга да, батрак булып ялланырга да киләләр. Кәшби карт аларның ачы тирләре исәбенә баеганнан-байый бара. Ике катлы йорт салып җибәрә, кибет ача, ишек аллары, зур каралтылары терлек-туар, кош-корт белән тула.

Өч улы арасында бик иркә булып усуче бердәнбер кызы Ситдыйканың зифа буйлы, сөрмәләнеп торган зәңгәр кузле, алсу йөзле бер чибәр булып җитеп килүен күреп Кәшби байның куанычы эченә сыймый. Бай кияү табып, әллә никадәр калым алырга, май эчендә йөзәргә мөмкин бит кызың ! чибәр булса.

Тик Ситдыйканың саф күңеле байлыкка түгел, мәхәббәткә сусый. Әгәр кулыннан килсә, үзләренең батрагы яшь, сылу егет Муллахмәт белән бергә булу өчен әтисенең бөтен мөлкәтен бирер иде ул. Муллахмәт тә Ситдыйканы өзелеп сөя. Тик Кәшби карт үз батрагына кызын бирәме соң инде. Ул моны яхшы аңлый һәм бәхет эзләргә Донбасс якларына чыгып китә. Шахтада эшләрмен, акча җыярмын, ул вакытта Ситдыйка минеке булыр, дип уйлый егет.

Шахтада кесә калынаймаячагын тиз төшенгән егет Бәзәкәгә кайтып, Ситдыйканы урлап китәргә карар бирә. Кыю фикер кызга да бик ошый. Егет белән кыз

төнлә, ындыр артында очрашып, мәңгегә бергә булу турында матур планнар коралар.

Без капчыкта ятмый. Кызының Муллахмәт белән дуслыгы Кәшби байга да беленә.

—Зимагур өчен устерген кызым юк,—дип кычкыра бай йодырыкларын төйнәп. Шул көннән башлап Ситдыйканы читлектәге кош кебек бикләп тота башлыйлар.

Мәхәббәт алдында иң зур йозаклар да көчсез. Кыю егет бер төнне сөйгәне йоклый торган булмәнең тәрәзәсен алып, Ситдыйканы урлап китә. Тик байның шымчылары аларның эзенә тиз төшәләр, авылдан бераз китү белән тотып кыйный-кыйный Кәшби байга китереп тапшыралар. Ачуыннан шартларга җиткән Кәшби карт кызыннан тизрәк котылу ягын карый, аны Псәй авылының Әхмәтгәрәй бай малаена ярәшә.

... Кышкы караңгы төн. Зур шәлгә төренгән бер кыз ак кар өстеннән сузылган тар гына чана юлы буйлап йөгерә. Ашыга, кабалана, әледән-әле артына карап ала.

Кимсетелүләргә, хурлауларга түзә алмыйча, яратмаган иреннән качып кайтып килүче Ситдыйка була ул. Менә кыз тиздән Муллахмәте белән күрешер,онытмаган ул аны,юк, онытса, тальян гармонь моңнарын түктереп, алар турыннан шул кадәр сагыш белан җырлап утәр иде мени. Кызурак кайтырга кирәк, тагын бер сәгатьтән ул сөйгәнен курер, бергәләп Донбасскакитәрләр, күргән газаплар онытылыр...

Тик мескен кызның планнары барып чыкмый. Аны тотып алалар. Ире, көнчелектән кан баскан күзләрен акайтып, Ситдыйканы ялгыз өйгә сөйрәп кертә. Сулгып-сулгып җылау, өзгәләнеп кычкыру тавышлары күршеләренә кадәр ишетелә. Тәмам котырынган Мөхәмәтҗан итеге белән хатынының кукрәген таптый бәшлый. Кинәт тавыш тына.Ситдыйканың хәрәкәтсез калган күзләрен озын керфекләре каплый, куллары өзелгән гөл сабагыдай идәнгә бөгелеп төшә. Авыз-борыныннан киткән кан нәфис ак муены буйлап кызыл тасма ясап сызыла.

Мөхәмәтҗан пычрак җинаятен яшерү очен үз корбанының әле суынырга да өлгермәгән гәүдәсен абзарга алып чыгып, муенына элмәк сала. Үз-үзен үтергән, янәсе.

Төн буе буран котыра, ямьсез тавышлар чыгарып җил сызгыра, тирә-юньне көрт басып китә.

Ирта үк торып сыерлар карарга чыккан хатын Ситдыйканың цемент кебек каткан гәүдәсен таба.

Ситдыйканың язмышы бөтен авылны тетрәтә. Бичара кыз турында бәетләр чыгаралар. Менә аннан өзекләр:

Ситдыйканың күлмәкләре
Уймак, уймак уелган.
Ситдыйканың гәүдәсенә
Дүрт каравыл куелган.
Кыз теләмәгән егеткә
Ирексезләп бирделәр.
Кара янган беләкләрен
Үрәдникләр күрделәр.
Ай, уф дигән тавышка
Былбыл кача камышка.
Һич бер кеше дә кермәгән
«Үләм!» дигән тавышка.
Бакыр комган эче тар,
Эченда җылы су бар.
Үтерүче Мөхәмәтҗан
Ходайдан җәза табар.

Халык үтерүчегә нәфрәт белән карап, ходайдан аңә җәза сорап ялвара. Ләкин Мөхәмәтҗан байны закон да, «ходай» да җәзага тартмый. Акча аны коткарып кала...» (Октябрь байрагы, 1960, 8 июнь).

Бәзәкәдә зур җир биләүче байлар булмаган. Шулай да X1X гасыр азагында кайбер бай кешеләр килеп чыкканнар.

Бәзәкәдән 20 километр тирәсе ераклыкта урнашкан Кокшан авылында 1850 елда хромпик заводы беренче продукциясен биргән. Хромпик эшләп чыгарудан башка бу заводта беррәттән күкерт кислотасы, тимер һәм бакыр купоросы, пыяла савытлар, химик һәм хуҗалык өчен яраклы савыт- сабалар, пыяла җитештерелгән. Завод елына көмеш белән хисаплаганда 70 мең сум табышка ирешкән. Тагын да зур табыш артыннан куу заводны оештыручы Капитон Ушковтан химик продукцияне арттырып чыгаруны таләп иткән. Ул вакытта бердәнбер пристань Кокшаннан 25-28 чакрым ералыкта урнашкан Ык Тамагында булу сәбәпле, предприятиене киңәйтеп булмаган. Шуңа күрр Ушков Тойма елгасы буенда яна завод төзергә карар кабул иткән һәм Иске Бондюг, Камаш, Озын Тау авыллары арасындагы җирне сатып алып X1X гасырның 60 еллары уртасында завод төзи башлаган. 1868 елда яңа завод беренче хәзер продукция бирә башлаган. Монда Кокшаннан производствоның байтак өлеше күчерелгән. Аның өстенә тоз кислотасы, сульфат, хлор, хлор известе җиткерелә башлаган. Завод төзелү нәтиҗәсендә Бәзәкә крестьяннары анда барып эшкә

ялланганнар. Алар авыл хуҗалыгы эшләрен бетергәч Ушков заводы өчен килгән тоз, күмер, колчедан ташларын баржадан аркаларына төяп ярга ташыганнар. Ә кыш көне шул ук әйберләрне ат белән Озын Тауның икенче ягында урнашкан заводка илткәннәр. Йөк ташучыларның эше авыр булган. Бер эшче хәттә купорос маена төшеп эрегән. Эш хакы көненә 60 тиеннән 1 сумга кадәр түләнгән. Эш авыр булу сәбәпле күпләре картлык көнен күрә дә алмаганнар. Әйтергә кирәк, заводта балалар һәм хатын-кызлар көченнән да киң файдаланганнар. Таш юл салу өчен кирәкле таш ватып бала-чага көненә 15-20 тиен акча эшли торган булган.

Бу заводта эшләнгән кислоталарны шешәләргә тутырганнар. Шешәләр ватылмасын өчен аларны кәрҗиннәргә салганнар. Менә шул кәрҗиннәрне Бәзәкә халкы үргән. Аларны җыеп заводка китеру эшен Ушков Бәзәкәнең Гыйльмибәшәр исемле кешегә йөкләгән. Бу кәрҗиннәр 20 литрлы бутылкалар өчен үрелгәннәр. Авыл халкы заводның эшләгән тозларын тутыру өчен мичкәләр эшләгән һәм аларны агач коршау белән коршаулаган. Менә бу коршауларны да, тәртә, себерке, өстәл, урындык ише әйберләрне Бәзәкә кешеләре Гыйльмибәшәр аркылы заводка тапшырып торганнар. Ушков алар өчен акчалата түләгән. Соңыннан бу Гыйльмибәшәр бик зур байга әйләнеп киткән. Ул үлгәч бу эштә Гаффаров Муллахмөт тә нык баеган.

1905-1907 елгы рус революциясенең авылга тәэсире зур булмаган. 1914 елда империалистик сугыш башлангач, авыл халкын амбар алдына җыеп, ирләрне сугышка барырга өндәгәннәр. Халык сугышка барырга теләмәгән. Шулай да авылдан сугышка китүчеләр булган. Мәсәлән, Мөхәмәтҗанов Бәхтигәрәй сугышта катнашып 1917 елгы революцияне дә сугышта каршы алган. Авылдашыбыз Фәйрушин Әхмәдиша сугышта булып яраланып кайткан. Шиабиев Мулланур да шулай ук илнең төрле почмакларында барган сугышларда катнашкан. Кәлимуллин Кирами революцияне шулай ук сугыш кырында каршылаган. Байтак авылдашлар сугыш кырында ятып калган...

Бөек Октябрь революциясе авылга тиз килеп җиткән. 1917-нче елның 18-нче ноябрендә авылда совет власте урнашкан. Революцияне ярлылар бик теләп кабул иткәннәр. «Байлар бетә, безгә рәхәт тормыш була, Ленин

дигән кеше ярлылар очен тырыша икән»,- дип сөйләп йөргәннәр. Бәшаров Зиннур, Сэйфуллин Мәхмүт, Сәйфуллин Вафа, Хөснетдинов Мулләхмәт - ничектер белем алган авылдашларыбыз - революциянең мәгънәсен дөрес аңлап, халык арасында аңлату эшләре алып барганнар, җыелышлар җыеп җир һәм урман турында, аларның халыкныкы икәнен аңлатканнар. Крестьяннарның тормышка карашын үзгәртүдә авылда төп рольне Бәшаров Зиннур уйнаган. Ул яңа строй, халык бәхете өчен ялкынлы көрәшче, оста оештыручы һәм пропагандист булган. Бәзәкәдә

революциягә багышланган демонстрация булган, анда балалар кызыл флаглар күтәреп йөргәннәр. Авыл советы ачылган. Авылда русча яза белүче булмагач, Степан исемле кешене китереп писарь итеп куйганнар. Авыл советы урнашкан бина «казенный фатир» дип йөртелгән. Авылның беренче авыл советы рәисе Бәшаров Госман булган.

Җир турында сорау озак һәм авыр чишелгән. Һәркөн үткәрелгән җыелышларда бәхәсләр' ызгыш- талаш өймәкләшеп сугышуга өйләнә торган булган. Тик шулай да җир, урман турында сораулар крестьяннар файдасына чишелгән. Байларның һәм кулакларның беркадәр җирен һәм авыл хуҗалыгы инвентарен тартып алып ярлыларга бүлеп биргәннәр.

Гражданнар сугышы Бәзәкәне читләп утмәгән, авыл берничә мәртәбә кулдан кулга күчкән. Бу турыда картлар һәм әле дә җирдән килеп чыгучы сугыш трофейлары сөйли.

1919 елның язында яшь Совет хөкүмәтен үз юлында җимерә-җимерә көнчыгыштан Мәскәүгә юл тотучы Колчак гаскәрләре Нокрәт елгасы буендагы сугышларда Азин дивизиясе тарафыннан җиңелеп яңадан көнчыгышка чигенә башлаганнар. Аларның бер төркеме Бәзәкәгә кайтып җиткән. Үзләрен куып килүче Азин дивизиясен туктату максаты белән Бәзәкә, Ык Тамагы белән Турай арасында оборона төзегәннәр. Бер үк вакытта Колчакның Чулман буйлап Иделгә юл тотучы флотилиясен кызылларның Маркин җитәкчелегендә хәрәкәт итүче Идел флотилиясе куып Озын Тау пристанена килеп җиткән. Алар шуннан торып Колчак гаскәрләре төзегән оборонаны артиллерия утына тотканнар. Бәзәкә инешенең сул як яры буйлап казылган окоплар өстендә снарядлар шартлаган. Тиздән бу оборонаны калдырып көнчыгышка качканнар.

Аклар авылга гомумән 3 тапкыр килгәннәр. Арган атларын ташлап, кешеләрнең җигә торган атларын алып чыгып киткәннәр. Күп кенә кешеләрнең сыерларын алып чыгып әрәмәлек буенда суеп ашаганнар. Йомырка, икмәк, бәрәңге талап алганнар. Картлар сөйләвенчә, аларның өсләрендә җебеп беткән, асылынып төшкән ак туннар, аякларында олы киез итекләр булган. Шул итекләрдә язгы пычракта йөргәннәр. Итекләрен чабатага алыштырганнар.

1918 елның мартында Бондюгта 500 кешедән торган Кама буе партизан отряды төзелгән. Тиздән ул В.М.Азин

җитәкчелегендәге армия составына кергән. Шул армиянең бер группасында авылдан 250-ләп кеше катнашкан. Таҗиев Минһаҗ 1920 елда ак полякларга каршы сугышып Ижевск шәһәреннән алып Варшавага кадәр барган һәм каты яраланып өенә кайткан. Шиабиев Мулланур белән Әхмәров Шәрәфи 1919 елда Вятские Поляныдан алып Себергә кадәр Колчак армиясенә каршы сугышларда, Хәсәнов Ситдыйк немец оккупантларына, Деникинга, Колчакка һәм Врангельгә каршы булган каты сугышларда катнашканнар. Гайнуллин Камали Колчакка каршы сугышларда катнашып ике тапкыр авыр яраланган. Гафиятуллин Шаех Азин дивизиясе составында Колчакка каршы пулеметчы булып Вятские Поляныдан алып Курганга кадәр араны үткән. Сугыштан кайткач алар авылдашлары белән, барлык ил халкы белән социализм төзергә керешкәннәр.

Социализм төзү җиңел булмаган. Ярлы крестьян, инде җире булса да, һаман байлардан бәйле яшәгән. Хәрби коммунизм сәясәте кризисы нәтиҗәсендә ил буенча крестьяннарның совет властенә каршы чыгышлары булган. 1920 елда «Кара бөркет» («Сәнәкле баш күтәру») исемен алган стихияле татар-башкорт халыкларының восстаниесе булган. Шул елда Бәзәкә, Псәй, Турай авылларында да совет дәүләтенә каршы чыгышлар булып алганнар. Мәгълуматлар булмау сәбәпле, ни өчен бу чыгышлар булган, кемнәр аны оештырган, бу сорауларга җавап бирүе кыен.

1928-1929 елларда армиядән махсус хәзерләнеп кайткан Төхвәтуллин Габдулла крестьян комитеты төзегән һәм аның рәисе булган. Тик 1930 елда совет властена каршы эшләрдә ялган гаепләнеп аттырылган. Авылда коллективлаштыру 1929 елда башланган. Бәзәкәгә колхоз оештыру өчен эшче, «егерме бишь меңче» Кандаков Әхмәтжам килгән. Коллектив хуҗалык төзелү турында протокол 1931 елның 10 мартында төзелгән. Аны язучы ул чакта унҗиде яшьтәге Габделхак Хөснетдинов булган. Сталин исемендәге колхозга 150 кеше язылган. Алар арасында Камалиев Сирай, Мәүлиева Минниса, Гатауллин Габдрахман, Көлимуллин Фәләхетдин, Хөрмәтуллина Минниса, Газизова Таджибә, Хәсәнов Исмәгыйль, Гыйззәтуллин Нәбиулла, Фәйрушиннар гаиләсе булганнар. Колхоз рәисе итеп беренче елны Гыйззәтуллин Нәбиулла сайланган. Язгы чәчү алдыннан атлар, хезмәт кораллары,

чәчүлек орлыклары берләштерелгән. Бергәләп авыл хуҗалыгын алып баруның өстенлеге беренче елны ук сизелгән. Урып-җыюдан соң крестьяннар колхозның көченә ышанганнар. Көзгә колхозчылар саны 300-гә җиткән (ә авылда 1930 елда яшәүчеләр саны 2179 кеше булган). Башта сөрү, чәчү эшләре атлар белән башкарылган, беренче бишьеллык елларында колхозга трактор кайтарылган.

Тик дошманнар сүзенә ышанып күп крестьяннар колхоздан чыкканнар. Колхозда нибары 15 хуҗалык калган. Кандаковның авторитеты төшкән. Кулаклар тарафыннан котыртылган хатын-кызлар: «Син имансыз аркасында авыл дырый-бырый килеп бетте»,- дипӘхмәтжанны, кыйнарга теләп, авыл буйлап куып йөргәннәр.

1931 елда «Сталин» колхозында тормышның газаплы көннәрен үз җилкәсендә кичергән, империалистик сугыш авырлыгын үз күзләре белән күргән, 1921 елгы ачлыктан көч хәл белән исән калган Госман Башаров терлекчелек фермасы оештырган. Билгеле, башта эш кыен барган, ферма оештыру теләге белән йөргәч, кулак калдыклары аңардан көлгәннәр. «Үзең башладың, үзең дәвам ит»,- дигәннәр аңа колхоз идарәсендә дә. Госман күңел төшенкелегенә бирелмәгән, авылдан авылга йөреп ферма җиткерү очен материаллар җыйган, һәр кеше белән аерым сөйләшеп, терлекчеләр һәм сыер савучылар тапкан, хәтта җитәрлек кадакны мәктәп балалары аша туплаган. Тырышлык бушка китмәгән, сыерлар өчен абзар төзелгән. Беренче күрсәткечләр түбәндәгеләр: 1932 елда ферма 38721 литр сөт биргән, 1933 елга бу күрсәткеч -42754 литрга җиткән. Ферма хезмәткәрләре сөтнең майлылыгын күтәрү өстендә тырышып эшләгәннәр.

Колхозда чәчү, сөрү, урып-җыю, печән чабу кебек эшләр атка тагылган машиналар ярдәмендә башкарылган. Тиздән авылга кайтарылган ЧТ-Д тәгәрмәчле тракторлар, ТЗ тракторы авыл хуҗалыгы эшләрен күпкә җиңеләйткәннәр.

Бу елларда колхозның ашлык саклау амбарлары да җитәрлек булмаган. Ашлык хәтта колхозчыларның келәтләрендә сакланган. Бандитлар хәрәкәте көчле булган, шуңа күрә колхоз идарәсе әгъзаларына һәр төн кулга корал тотып колхоз милкен, басудагы игеннәрне

сакларга туры килгән. Ул елларда бухгалтер булып эшли башлаган Габделхак Хөснетдинов: «1936 елга кадәр гел конторада
кундым», - дип искә ала. Шулай да 1933 елның 13 октябрендә конторага ут төрткәннәр. 1936 елда колхоз малын агулау факты булган. 18 баш мал үлгән.

Колхоз рәисләре ел саен алмашынып торганнар: 1930-1931 елларда Гыйззәтуллин Нәбиулла, 1931- 1932 елларда Кандаков, 1933 елда Хәйретдинов Хуҗа, 1934 елда Гыймазетдинов Сәләх, 1935-1936

елларда Ганиев Габденур колхоз рәисләре булганнар.

1932 елда авылда комсомол оешмасы төзелгән. Шул елдан алып 1944 елга кадәр аның секретаре булып Габделхак Хөснетдинов эшләгән. Комсомол оешмасы колхоз төзелешендә зур көч булып торган.

Сталин репрессиясе Бәзәкә авылын да читләтеп үтмәгән, кайбер авылдашларыбызның (Типтәрләр нәселеннән) артык «коммунистик» караштa булып, бәзәкәлеләрне «сатуы» аркасында, берничә кеше лагерьларга җибәрелгән, 5 кеше атып үтерелгән. Башта байларны НКВД кулына биргәннәр, аннан соң инде кайбер җитәкчеләргә «яшәргә комачаулаучы» коммунистлар, совет хезмәткәрләре эзәрлекләнгән. Алар арасында Гөбәйдуллин Нәбиулла Гобәйдулла улы да булган. 19 ел совет аппаратында эшләгән Нәбиулла, советларга каршы агитация алып баруда гаепләнеп, 1937 елның 13 ноябрендә кулга алынган һәм 10 елга ирегеннән мәхрүм ителгән. Алга таба аның язмышы турында бер төрле хәбәр дә булмаган. Кызы Миңзифа хәзер дә әтисе турында мәгълүматларны бөртекләп җыя. Шунысы билгеле: Гөбәйдуллин Н.Г. 1989 елда реабилитацияләнгән.

Бөек Ватан сугышы елларында колхозчылар аеруча тырышып эшләгәннәр. «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» лозунг безнең авылдашлар лозунгысына да әйләнгән. Хатын-кызлар фронтка киткән ирләрен, абыйларын, энеләрен, улларын алыштырып колхоз кырларында эшләгәннәр. Атларны сугышка алу сәбәпле, чәчү һәм урып-җыю эшләре кул белән башкарылган. Трактор руле артына хатын-кызлар утырганнар. Алар арасында Сәлимуллина Фатыйма, Зиннәтуллина Мөгәллимә, Ганиева Мәугидә булганнар. Авылдашлар фронтка ярдәм итү өчен кулларыннан килгән барлык эшне эшләгәннәр. Алар сугышчыларга җылы киемнәр һәм азык-төлек әйберләре җыеп җибәргәннәр. Укучылар да сугышчылар өчен җылы әйберләр җыюда катнашканнар, аларга бүләкләр һәм хатлар җибәреп торганнар. Яшь тимурчылар авыру кешеләргә һәм картларга төрле ярдәм күрсәткәннәр. Сугыш елларында авылда эвакуацияләнгән балалар да яшәгәне билгеле.

Сугыш елларында авылда ике колхоз булган. Түбән оч - «Сталин» колхозы, ә югары оч - «Ворошилов» колхозы дип аталганнар. Тау башы «Сталин» колхозына кергән. «Сталин» колхозының рәисе булып фронтовиклар

Гыйльфанов Нуриәхмәт, ә «Ворошилов» колхозында Таҗиев Фәрдетдин эшләгәннәр. Алар сугыш кырларыннан яраланып кайткан булганнар.

Башка эшләрдәй ирләр авылда булмагач, игенне хатын-кызлар урак белән сотыйлап урганнар. Ашау ягы тыгын булганлыктан, кашыклап он, санап кына бәрәңге биргәннәр. Маллар өчен азык хезмәт көне буенча бирелгән. Шифаханәдә юыныр өчен граммлап кара сабын таратканнар. Кешеләр бозауларын ипигә, терлек азыгына алмаштырырга мәҗбүр булганнар. Кырларда эш аеруча кызу булган. Шуңа күрә төнлә сәнәкләр белән балалар көлтә ташыганнар, картлар кибән өйгәннәр. Көндез барысы да ындыр сукканнар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, авылга көн саен унар повестка килгән. Повестка алу белән атларга төялеп ирләр фронтка китеп торганнар. Бөек Ватан сугышына авылдан 635 кеше киткән. Халык бәхете өчен 241 авылдашыбыз сугыш кырында ятып калганнар, колхоз буенча сугышта вафат булганнар саны - 456. Хәбәрсез югалганнар саны шулай ук күп булган. 1930 елда Бәзәкәдә 2179 кеше яшәгән булса, сугыш азагына кеше саны бер мең тирәсе генә калган.

Бөек Ватан сугышы еллары баласы Фәния Шакированың»Сынап сындырган язмыш» шигыре нәкъ шул көннәр турында сөйли:

Көтмәгәндә илгә афәт килде Илне кара төтен каплады.
Җиңү өчен өметләрен баглап Ирләр ил сакларга атлады.
Балаларын, ирләрен озатып Бәгырьләре калды өзелеп.

Бала-чага, колхоздагы эшләр Хатын-кызга калды өелеп.
Җиңү диеп, көнне төнгә ялгап Эшли алар, эшли - тырыша.
Бөтен булган ипекәйне җыйнап Җибәрәләр алар фронтка.
Кайтып тора кара кәгазьләре Эш өстенә кайгы өелә.
Өчпочмаклы сәлам хаты көтеп Күпме газиз җаннар тилмерә. Берәрсенә сәлам хаты килсә Шатлык иңә алар иңенә.
Кат-кат җыелып аны укый алар Ничә кабат микән көненә.
Атлар арып, ашатырга беткән Сукаларда атлар егыла.
Мондый ачы, авыр газаплардан Бугазларга төер тыгыла.
Исән калганнарын фронтка алдылар, Атлардан да халык аерылды.
Кибән төбе ашлыкларын ашап,
Күпме газиз жаннар кырылды. Көтүмкәләп, бәләкәй арба сөйрәп, Алабугадан орлык ташыды. Чабаталар тузып, табаннар кабарды, Тешен кысып халык чыдады.
Көне кызу, авыз чайкый-чайкый Көне буе урак урдылар.
Үз диннәрен алар хөрмәт итте,
Эссе дими ураза тоттылар.
Носилкалар белән көлтә ташып, Тиргә батып кибән куйдылар. Тешкәйләрен кысып, түзә-түзә Күпме саулыкларын җуйдылар. Басу капкасында - каравыллар, Кесәләрне алар капшадылар. Безнең әниләрнең күтәреп кайткан Печәненә кадәр алдылар. Авырлыклар белән кимсетүләр, Сугышы да китте озакка.
Таш булып таш та чыдамас иде Әниләр кичергән газапка.
Кан тамгандыр алар йөрәгеннән, Һаман онытылмый яралар.
Өйгә кайткач тагын йөрәк өзеп Ипи сорап елый

балалар.
Кояш чыгу белән әни эшкә китә, Кайта иде фәкать кич кенә. Өйдәге эш, ике нәни бала Җиде яшьлек кызчык өстендә. Олы чиләкләрен сөйри-сөйри,

Өй чистарта, суын китерә.
Әни кичен эштән кайтуына Ярып бәрәңгеләр пешерә.
Аш пешерү өчен басулардан Берәмтекләп борчак чүпләдек. Төрле үлән яфракларын ашап Ярый инде җәен үткәрдек.
Ярап куйды безгә шул чагында Кычыткан, балтырган, кукысы.
Әле дә тора кебек тамагымда Алабута ипи ачысы.
Сукыр лампа, керосины беткән, Табага салып чыра ягабыз. Кабыклы бәрәңге өләшенә, Шулай гына булгач чамабыз.

Ул чагында сабын бөтенләй юк,
Селте белән керне уалар.
Су буена төшеп, тукмый-тукмый
Киндер күлмәкләрен юалар.

Бу ачлыкка тагын афәт булып
Бизгәк чире килеп сырылды.
Мәрхәмәтсез шушы явыз чирдән
Күпме кеше җаны кырылды.

Ой эченә кергәч тигезләде,
Чирләделәр өйдә барчасы.
Ашап булмый - әле дә күз алдымда
Тәлинкәдә юа боткасы.

Авырлыкка авырлыклар өстәп,
Налог-заемнарын салганнар.
Акча сорап әниләрне беркөн Авыл
советына япканнар.

Төне буе елап чыккан алар,
Йөзләр шешкән, күзләр кызарган.
Иртән генә балалар янына Әнкәй
бәгърем кайтып егылган.

Язмыш безне сындырып сынады,
Күрдек бу сугышның газабын.
Алда тагынниләр көтеп тора?
Белмибез шул гомер азагын.

Өсләрегез бөтен, ис китәрлек,
Туенасыз тәмләп тамакны.
Әй, Ходаем, балаларга бирмә Без
кичергән авыр газапны...

Сугыштан соңгы еллар авыл һәм колхоз өчен авыр булган. Берсе артыннан берсе колхоз рәисләре алышынып торган. 1952 елда Сталин һәм Ворошилов исемендәге колхозлар Сталин исемендәге колхозга, 1959 елда «Беренче Май» (Татар Тәкәш авылы), «Игенче» (Сәйтәк авылы), «Кызыл Октябрь» (Мари Тәкәш авылы), «Труженик» (Ык Тамагы авылы) һәм Сталин исемендәге колхозлар Сталин исемендәге колхозга берләштерелгәннәр.

1958 елның февралендә Сталин колхозы рәисе итеп колхозчылар бердәм тавыш белән укытучы Баян Вәли улы Әхмәровны сайлап куйганнар. Ул үзен оста оештыручы, тәжрибәле тәрбияче итеп күрсәткән. Колхоз идарәсе әгъзалары белән бергәләп ул колхоз төзелешенең мөһим урыннарын табып аларга төп көчне юнәлткән, механизаторлар, терлекчеләр, җитәкчеләр кадрларын үстерүгә аеруча зур игътибар биргән.

Бөек Октябрнең 60 еллыгы алдыннан (1977 ел) «Яңа Кама» газетасы түбәндәге материалны бастырган: «Бөек Октябрнең 40 еллыгына Сталин колхозы кырларында 3 трактор, 3 комбайн, 3 автомашина эшләгән, фермаларда 325 баш эре мөгезле терлек, 574 баш сарык, 315 баш дуңгыз булса, хәзер 20 елдан соң колхозның 4800 гектар чәчү җирлеге, 1800 гектар болыны, 20 гусеницалы тракторы, 20 тәгәрмәчле тракторы, 17 «Колос» һәм «Сибиряк» комбайннары, 13 автомашинасы бар. Фермаларда - 1850 баш эре мөгезле терлек, 700 баш дуңгыз, 1100 баш сарык, 3500 баш кролик. Колхоз 1976 елда 171400 сумлык продукция җиткерде, 451000 сум капитал кертелде, акча кереме 1014000 сум булды» («Яңа Кама», 1977, 7 ноябрь).

Юлбашчы культы тәнкыйтьләнгәннән соң Сталин исемендәге колхозга «Кама» исеме бирелде. 1983 елга кадәр колхоз рәисе булып Б.В.Әхмәров эшләде. 1983 елның 6 июненнән башлап колхоз белән инде менә унҗиде ел Ибраһим Миндар улы Галимов җитәкчелек итә.

1992 елда колхозны тагын берничәгә бүлделәр. «Кама» колхозы составында Бәзәкә һәм Ык Тамагы бригадалары гына калдылар.

Хәзерге вакытта «Кама» колхозы - районда иң эре хуҗалыкларның берсе. Аның карамагында 19 трактор, 5 комбайн, 8 автомашина бар. 2000 елның 1 маена терлек саны: 1314 эре мөгезле терлек, шулардай 360 савым сыер, 27 ат. Колхозның җир мәйданы - 1910 га. Колхозда 141 колхозчы эшли.

Рөис И.М.Галимов җитәкчелек итә башлагач, колхозда зур гына үзгәрешләр булды. Яңа фермалар, ашлык складлары, колхозчылар туклану урыны - яңа ашханә төзелде, цемент белән уратып алынган яңа силос саклау чокырлары барлыкка килде. Бәзәкә белән Ык Тамагы авылын асфарьт юл тоташтырды. Колхозның һәм авылның электр линияләре яңартылды. Урамнарга асфальт җәелде, 12 су колонкасы куелды. Бапалар бакчасы, яңа китапханә, колхоз идарәсе, промышленность һәм продукт магазиннары, почта бүлеге, сберкасса өчен яңа биналар җиткерелде. Ватан сугышында һәлак булганнарга Җиңүнең 50 еллыгына һәйкәл куелды. 1988 елда Татарстан авыллары арасында беренчеләрдән булып Бәзәкәдә яңа мәчет ачылды. Авылның төп өлеше белән тау башын тоташтыра торган 100 метрлы тимердән күпер салынды. Авыл урамнарына йөк машиналарын кермәү ниятеннән авыл кырыннан асфальт юл җиткерелде. Авыл өйләренә газ кертелә башлады. Нефть алу нәтиҗәсендә бозык су килә башлау аркасында, колхоз идарәсе авыл советы белән берлектә яңа су системасы төзү эшләре башлады. Җәй айларында балаларның ял итү һәм сәламәтләндерү лагеры эшли. *

Бәзәкә авылы көннән көн яңара, үсә бара. Соңгы елларда авылда тагын бер урам барлыкка килде. Анда күбесенчә яшь гаиләләр йорт җиткерделәр. Агач өйләр белән рәттән кирпич йортлар, коттеджлар да барлыкка килде. Ә авылда барлыгы 400 тирәсе хуҗалык; 751 кеше яши.

Авылның яңа йөзе, бүгенге хәле өчен Бәзәкә кешеләре колхоз рәисе Галимов Ибраһим Миндар улына, колхоз ветераннары 1931 елдан алып 1984 елга кадәр бухгалтер булып эшләгән Хөснетдинов Габделхак Гыйльфан улына, Гайнетдинова Нурзия
Мулланур кызына, Шөрәфиев Шакир Садри улына, Сэлимуллина Миңнеҗамал Шәйхиәхмәт кызына, Фатхуллин Нуриәхмәт Хуҗиәхмәт улына, Садриев Рафәгетдин Нәҗметдин улына, Шакиров Мулланур

Мөхәмәтҗан улына, Зәйнетдинова Фатыйма Фәттахетдин кызына, Салихов Мулламөхәмәт Салих улына, Шакиров Кәрим Шакир улына, Җамалетдиновлар Наҗия Әхмәтриза кызына һәм Дәүләт Хөснетдин улына, Нигъмәтуллиннар Хәмдениса Минтаҗетдин кызы һәм Хәмәт Вәлиулла улына, Шәймөхәмәтов Әхәт Касыйм улына,Сабитов Муллаян Шәйхеләхмәт улына, Азин Нуриәхмәт Хаҗи улына, Хәбибуллина Фәрдәвия Мәгънәви кызына, Гыйльфанова Әлфия Гәли кызына, Нигъмәтуллина Фәйрүзә апага, Әхмәтҗановлар Рәхим абый һәм тракторчы Фәйрузә апага, Шәрәфетдиновлар Шәйхенур абыйга һәм тракторчы Наталья апага һ.б. бурычлылар. Колхозның тормышы бүгенге алдынгыларга да бәйле: Мусина Рәвилә Рәвил кызы, Гайнуллина Сөгъдә, Закирова Гөленәвия Миннеәхмәт кызы, Закирова Рәфинә Зиннур кызы, Таҗиев Фәнис Гайфетдин улы һәм башкалар.

Бәзәкә тарихында туган ягыбызда нефть табылу да зур роль уйнады. Авылда колхоз крестьяннары белән рәттән нефть табучы эшчеләр барлыкка килде. Авылның шәһәрләр белән элемтәсе усте. Бондюг һәм Алабуга белән Бәзәкә арасында асфальт җәелде, автобуслар йөри башлады, авылга шәһәр стандартлары килде.

Безнең якларда палеозой катламнары булуы турында беренче мәгълүматлар 19 гасыр урталарында ук барлыкка килгәннәр. Казан университеты галимнәре бу якларда геологик эзләнүләр алып барганнар. Революциядән соң геологик эзләнүләр 1934 елда яңартылган. Озын Тау белән Татар Тәкәше авылы арасында нефть булуы турында беленгән. 1938 елда Сәйтәк, Бәзәкә,
Ык Тамагы авыллары тирәсендә геологлар эшләгәннәр һәм Сәйтәк кырында пермь катламнарын тапканнар. 1951-1952 елларда безнең якларда беренче бораулау эшләре алып барылган. 1955 ел азагында Сәйтәк авылы кырында 1553 метр тирәнлегеннән беренче нефть күтәрелгән. 15 номерлы скважина - туган якның

нефтьчеләр тарихында истәлекле урын. Бу скважина әле хәзер дә «исән», һаман да эшли. 1958 елда / Бәзәкә тирәсендә дә нефть вышкалары калкып чыккан. Авылга торырга нефтьчеләр килгәннәр. Бәзәкәлеләр аларны бик теләп «квартирага» керткәннәр. Алабугада махсус йортлар җиткерелгәч, («Восточная»), алар Алабугага күчеп киткәннәр.

1959 елдан башлап Бәзәкә кырында (Маймурзада) Бондюг - Әлмәт нефть уткәргече салганнар. 1961 елда трубалар буйлап Кама буе нефте ага башлаган. Бәзәкәдән 2 километр ераклыкта нефть җыю үзәге (Сборный) төзелгән. Күп кенә авылдашларыбыз шунда эшкә урнашкан.

НГДУ «Прикамнефть» идарәсендә Почет китабы бар. Анда беренче нефтьчеләр кертелгән. Алар арасында авылдашыбыз Габделнасыров Сәләхетдин дә бар. Ул 1958 елдан 2-промыселда нефть табу буенча оператор булып эшләгән. Тәҗрибәле оператор булганга аны 42-скважинага күчергәннәр. Бу скважинада һәрвакыт яңа автоматик техника сынала торган булган. Сәләхетдин абый орден- медальләр белән бүләкләнгән.

Гомере буе, 1959 елдан бирле нефть табу буенча оператор булып Муллаян Хаҗи улы Хаҗиев та эшләгән. Читтән торып 11 сыйныф бетергән, сварщик һәм стропальщик һөнәрләрен үзләштергән. Муллаян Хаҗи улы - нефть промышленносте отличнигы, М.Я.Кропачев исемендәге совет профсоюзлары премиясе лауреаты.

1959 елдан тагын бер Бәзәкә егете нефтьче булып эшли башлаган. Мулламөхәмәт Минниәхмәт улы

Әхмәтҗанов башта төрле эшләрдә йөргән. Ул үзенең эшкә бирелгәнлеге, яңалыкка омтылуы белән башкалар арасында аерылып торган. Шуңа күрә аны җитәкчеләре Әлмәткә мастерлар мәктәбенә укырга җибәргәннәр. Укып кайткач, ул бригада җитәкчесе булып эшли башлаган. Ул башкалардан тагын бер ягы - иҗат итү, иҗатка омтылуы белән аерылып торган. Ул керткән тәкъдимнәр - скважинаны туктатмыйча нефть үткәөгрчен ремонтлау, нефть җыю системасын герметизацияләү һәм башкалар - зур экономик эффект биргәннәр. Аның хезмәте хөкүмәт бүләге - Октябрь Революциясе Ордены белән билгеләнгән. Мулламөхәмәт Әхмәтҗановка «Татарстан АССРның атказанган нефтьчесе» мактаулы исеме дә бирелгән.

Әлбәттә, промышленностьның авылга якынаюы Бәзәкә кешеләренең профессиясен, тормыш хәлен үзгәртеп кенә калмады, авылның матурлыгына, аның климатына начар тәэсир дә ясады. Бигрәк тә, Кама елгасын буалап КамГЭС төзелгәч, Бәзәкәнең матур һәм гүзәл җирләре, байлыклары су астында калды. Әле Чулман суы тагын да күтәрелергә тиеш дип көтелә... Бу турыда Фәния апа Шакирова ачынып «Сагыну» шигырендә болай дип яза:

Җәйләр җитсә сагынып, ямансулап
Үткәннәрне искә аламын.
Су астында калды күпме байлык -
Шуны сагынып дөрләп янамын.
Ташларына басып моңлы кошлар
Каршылады алсу таңнарны.
Тирә-юньдә шау чәчәкләр исе
Сафландыра иде җаннарны.
Җәйләүләрдә җәен утлап йөрде
Сыерлары, көтү атлары.
Ямьле иде Бәзәкә болыннары,
Авылымның тирә яклары.
Болынга төштек кунакка баргандай,
Кибән куйды уңган агайлар.
Матур озын Кәдәнгеш күлендә Балык читтерделәр

малайлар.

Бердәм булып кызлар җыелышып Җыйдык печән, өйдек чүмәлә.

Җанга шифа, тәнгә сихәт бирде, Коендырды күле Пинәрә.

Бар иде бит Сырт өсте күле дә, Якты,
Караңгы күл, Дусае.
Җырлар җырлап кичен күңел ачТык Кәч-куәт өстәде җәй ае.

Шушы ямьле матур болыннарның Их саф иде шундый һавасы. Мәхәббәтен ача алмаганга Һавасының тиде дәвасы.

Күбәләкләр чәчәкләргә кунып Гашыйк кыздай шашып очтылар. Сагынышып кайткан су кошлары Күлнең дулкыннарын кочтылар. Табигатьнең гүзәл кочагында Яшь колыннар чабып уйнады. Карлыган, җиләкләп чөйләр эчтек, Хозурланып йөрәк туймады.

Олы күл һәм Кече күл буенда Гөлҗимешен җыйдык, баланын. Шундый матур ямьле болыннарга Хыялымда гына хәзер барамын. Авылымның иркен болынында Сыер сауган чаюгар исемдә.
Шунда йөргән яшьлек вакытларым, Сагынуданмы, керә төшемә. Авылымның табигатен сагынып Ераклардан кайтты кунаклар. Җәйләр җитсә йөрәгем җилкенә Ядкарь булып калды шул чаклар. Учак ягып, балыклар пешереп, Бәрәңгеләр күмеп ашадык.
Әллә бәлки ялгышлык беләндер Бар байлыкны суга ташладык...

Әйе, илебездә хәзер бара торган авыр күчү процесслары авылымны да читләтеп үтмәде. Шуңа да карамастан, бәзәкәлеләр үз авылларының киләчәгенә зур оптимизм белән олугъ өметләр баглыйлар, аларга гына хас булган сыйфатларын югалтмыйча авыл тарихын дәвам итәләр...

## БӘЗӘКӘНЕҢ ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАРЫ

**Әүлия кабере.** Бу кабер авылның «тау башы» дип йөртелә торган өлешендә Шәйхетдин абыйлар хуҗалыгы артында урнашкан. Әүлия турында берничә юрама яши. Шуларның берсе ' буенча, авылның бер фәкыйрь генә гаиләсендә ике игезәк кыз үлгән һәм аларны мена шушы урынга күмеп куйганнар. Гонаһсыз балалар, бигрәк тә аларның игезәк булуы монда зур роль уйнаган. Авыл әбиләре әле хәзер дә чистарынып, изге уйлар белән догалар укып кабер янына килеп черем итеп алалар. Шул черем итеп алган арада бу игезәкләр күзгә чалынып киткәлиләр. Аларның кулында бер чүмеч су, бер кашык бал, икмак телеме һ.б. күрәләр. Ә бу синең күпме гомерең калганын белдерә икән..

**Бәзәкә авылы урыны (Бизякинское селище).** Авылдан көнчыгыш якта Чулман елгасына очлаеп кергән коры җирдә, су баса торган болыннан 15 м биеклектә урнашкан. Бу мәйданда археологлар тарафыннан борынгы ананьино чорына карый торган керамиканың 18 төрле бизәкле фрагменты табылган.

**Бәзәкә борынгы каберлеге (Бизякинский могильник).** «Селище» янында урнашкан. Безнең гасырның Ш-1У гасырларына карый торган мәет калдыклары табылган: скелет, баш сөяге, балчыктан ясалган савыт. Каберлек 1994 елның 2 июнендә ачылган.

**Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл.** Һәйкәл башта авыл клубы ишек алдында куелган булган. Аннан соң ул мәктәп территориясендә урнаштырылган. Менә инде ничә ел яңартылган матур һәйкәл авыл уртасында колхоз идарәсе янын бизәп тора. Һәйкәлгә сугыш кырларында ятып калган авылдашларыбыз исем- фамилияләре язылган.

**Газраил тавы.** Бу инешкә төшә торган тауларның берсе. Таудан ерак түгел бер өйдә агайлы-энеле Мөхәмәтдин һәм Мөхәмәтша яшәгәннәр. Боларның ике атлары булган: берсе яхшы, икенчесе начаррак. Мөхәмәтдин башка чыгасы булгач, яхшы атны сораган. Ләкин Мөхәмәтша атны бирмәгән. Гауга кубкан. Бер

кичен Мөхәмәтша клубка чыгып киткән, Мөхәмәтдин аның кайтуын сагалап торган да, арттан килеп башына кендек белән бәргән һәм канга баткан Мөхәмәтшаны тау буйлап сөйрәп инешкә алып төшеп бәкегә батырган. Эзләрен күмә-күмә өенә кайтып киткән. Иртән суга төшкән хатын-кызлар бөкедән чыгып торган аякларны күреп авыл кешеләрен җыйганнар. Алар бәкедән Мөхәмәтшаны тартып чыгарганнар һәм, ничек кенә Мөхәмәтдин эзен яшерергә тырышмасын, аны эзләп тапканнар. Ул өч елга ирегеннән мәхрүм ителгән. Шул көннәрдән бирле бу урын «Газраил тавы» дип йөртелә башлаган.

**Гимазетдинов Марсель үскән йортта мемориаль такта.** Ул Олы урамның нәкъ уртасында урнашкан йортта урнаштырылган. Бу йортта җитәкче, шагыйрь-патриот, Бәзәкәгә мәдхия җырлаган Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов туган. Аның 50 яшьлек юбилее көнендә бу мемориаль такта куелган. Аның истәлеген мәңгеләштерү өлкәсендә укытучы Мөхетдинова Рәмзия Гәрәй кызы һәм колхоз идарәсе, авыл советы күп көч куйган.

**Иске колхоз идарәсе бинасы.** Бу бина Сталин исемендәге колхоз заманында җиткерелгән. Б.В. Әхмәров рәис булган заманда бина киңәйтелгән. Бу бина колхоз төзелешенең авыр, ләкин искиткеч

романтик еллары турында, партия оешмасы һәм колхоз җитәкчеләре турында, төннәрен килеп йоклаган каравылчы Миниҗамал апа турында хәтирәләр саклый. Яңа бина җиткерелү сәбәпле бу йортта колхозчылар өчен квартиралар ясау планлаштырыла.

**Кызлар чокыры.** Рус патшалары татар халкын чукындыру өчен коралланган «карательный» отрядлар җибәргәннәр. Безнең бу тирәдә Сәйтәк, Бигәшише авыл татарларын чукындырганнар. Бәзәкә кешеләре авылдан 3 км ераклыктагы чокырларда качып ятканнар. Хатын-кызларны яшереп, ир-атлар еш кына авылга кайтып килгәли торган булганнар. Хатын-кызлар шушы чокырда киндер сукканнар, мал-туар асраганнар: Бик озак торганнан соң гына кире авылга кайтканнар.

**Мәдәният йорты.** Мәктәп артында урнашкан мәдәният йорты - күрше-тирә авыллар арасында 60 елларда беренче булып җиткерелгән мәдәни үзәк. Зур сәхнәсе, тамашачылар залы, биюләр залы, гримнар булмөләре, вестибюле бар. Икенче этажында директор бүлмәсе һөм кинобудка урнашкан.

**Мәктәп.** Шулай ук 60 елларда авыл төзүчеләре җиткергән архитектура истәлеге. 70 еллар башында мәктәпкә өстәмә бина өстәлә. 90 елларда күрше авыллардан килеп укучы балалар өчен яңа интернат җиткерелә. Мәктәптә предметлар буенча кабинетлар системасында уку-укыту бүлмәләре, хезмәт мастерское, зур спортзал, китапханә, ашханә, балалар оешмасы бүлмәсе, Марсель Гыймазетдинов музее, укытучылар бүлмәсе һ.б. бар. Залларны һәм сыйныф бүлмәләрен мәктәп, авыл һәм колхоз тарихына багышланган матур стендлар бизи.

**Мәчет.** Соңгы елларда җиткерелгән мөселманнарның изге урыны. Мәчет «Кама» колхозы идарәсе һәм авылдашлар хисабына төзелде. Элекке сыман авылда хәзер азан тавышлары ишетелә.

Мәчеттә мулла тарафыннан дини укулар алып барыла.

**Тау башы мәктәбе урыны.** Бу мәктәп тау башында 1926 елны салынган. Тау башында салынуның сәбәбе - янгыннардан саклану һәм дин әһелләренең ризасызлыгына каршы килмәү. Агачтан корылган булу

сәбәпле мәктәп бинасы сүтелгән. Хәзерге вакытта мәктәп янында ускән агачлар гына монда кайчандыр бала-чага тавышлары белән тулы булган мәктәп ишек алдын һәм бакчаларын искә төшереп торалар...

**Тукмаклы.** Авыл картлары сөйләвенчә, Сарсаз һәм Псәй авылларына бара торган юл бер тирән чокыр аркылы узган. Бу авыллар арасы урман белән капланган булган. Ике авыл арасында кешеләр йөреп торган. Ә бу урманда качкыннар качып ятканнар. Юлдан уткән һәркемне тукмаклап, әйберләрен алып кала торган булганнар. Шуңа курә бу урынны «Тукмаклы» дип атап калдырганнар.

**Шәйхетдин каберлеге.** Бу Кама елгасы янында Бәзәкөнең көнбатыш ягындагы зират. Элек аракы эчкән, спиртлы эчемлекләр кулланган кешеләрне олы зиратка күммәгәннәр. Һәм менә бу каберлек килеп чыккан. Анда Шәйхетдин, Исмәгыйл, Гыйләҗ, Фәттах исемле кешеләр кумелгән.

**«Яман тал» чокыры.** Бу хәл 1919 елның көзендә булган. Бер тыныч көнне кичкырын көтмәгәндә бөтен якын-тирәне дер селкеткән көчле шартлау ишетелгән. Бу шартлаудан сәләмә тәрәзәләр коелып төшкән. Шул вакыт авылның Псәй ягына чыга торган очында күккә ямьсез кара төтен күтәрелгәнен күргәннәр. Халык шунда йөгергән. Барсалар, ни күзләре белән күрсеннәр: Хәмидулла дигән кешенең бөтен каралтысы җимерелгән, ишек алдында бер аягы бот төбеннән өзелгән Хәмидулланың малае 18 яшьлек Зиннур ята икән. Ул үлгәнче бу фаҗиганың ничек булганын сөйләп бирергә өлгергән.

Гражданнар сугышы чорында Бәзәкә тирәсенә төшкән кайбер снарядлар шартламыйча җиргә күмелеп калган булган. Хәмидулла аучы мылтыгын корырга дары таба алмагач, әлеге шартламый калган снарядларны казып алып, өенә алып кайткан, аларны сүтеп, эчләрендәге дарыны бушатып алып, уз мылтыгын корып, ауга йөргән. Фаҗига буласы көнне соңгы снарядның капсуле кирегә борылмый аптыраткан. Хәмидулла капсульдәге чокырга өтерге белән сугуы булган, снаряд шартлаган. Секунд

эчендә Хәмидулла да[illegible]ул азапланган лапас түбәсе дә күккә очкан. Шунычы гаҗәп, ишек алдында уйнап йөргән 4 яшьлек малай бертөрле дә зыян күрмичә исән калган.

## АВЫЛДА МӘГАРИФ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫ

_ Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр Бәзәкәдә фәнни белем бирүче мәктәп булмаган. Архив материаллары (Киров өлкәсе дәүләт архивы) күрсәткәнчә, авылда ике мәдрәсә булган. Аларның берсе 1860 елда, икенчесе 1870 елда ачылганнар. Аларда муллалар Фәтхетдин Сәйфуллин һәм Закир Мортазин (фамилиясе архив материалында Митрузин дип бирелгән.- автордан) укытканнар (Материалы по статистике Вятской губернии. Вятка, 1890, т. У1, ч.2, п. 2). Авылда Минехуҗа мулла һәм соңга таба Гыйльфан мулла булганнары билгеле. Балалар мәдрәсәдә дин сабагы алганнар. Шуңа күрә революциягә кадәр авылда белемле кешеләр югары катлау гаиләләрендә генә очраган. Авыл крестьяннары тулысынча надан булганнар.

Мәдрәсәләрнең ничек эшләве турында кызыклы материалларны Анастасиевның Алабуга педагогия институтында сакланып калган «Вятские инородцы и ихъ школы» дигән китабыннан табарга мөмкин. Ә без шул китаптан кайбер материалларны биреп кенә чикләнербез: «Мәдрәсәләр күбесенчә мәчет кырындагы йортларда урнашканнар. Мәдрәсәне яктырту, җылыту ише эшләрне кайбер байлар үз өсләренә алганнар, а кайбер мәдрәсәләрне шәкертләр чират буенча утынны өйдән алып килеп җылытканнар. Мәдрәсә кечкенә бинада яисә берәр кешенең өй почмагында урнашкан булу сәбәпле анда тынчу һәм юеш булган. Анастасиев язганча, шәкертләр тәһәрәт алу сәбәпле мәдрәсәләрдә авыр үзенчәлекле ис тарала торган булган. Өстәлләр булмаган, шуңа күрә малайлар суык идәнгә тезләнеп укый торган булганнар. Шуңа курә күбесе суык тигезеп еш кына чирләгәннәр.

Мәдрәсәгә укырга кергән малайлар башта гарәп телендә укырга өйрәнгәннәр, аннан соң гомуми белем

курслары укытылган: диалектика һәм метафизика, астрология һәм космография, изге мөселман китаплары турында белешмәләр, география нигезләре, гади арифметика һ.б.» Дөресен әйтергә кирәк, картлар сөйләве буенча бу курслар барысы да Бәзәкә мәдрәсәләрендә укытылмаган.

Авылда клуб ише ял итү урыннары булмаган, шуңа күрә халык күңел ачу өчен Сабан туе, «Түгәрәк тал» җыены, «Корбан суы» исемле массакүләм кунак чакыру җыены үткәргән. Кама ташыган вакытларда кызлар-егетләр су буенда кичләрен уен оештырган. Озын кыш көннәрендә яшьләрнең бердәнбер күңел ачу урыннары булып тула һәм каз өмәләре, «Аулак өйләр» исәпләнгән. Революциягә хәтле авылда концерт, спектакльнең нәрсә икәнен белүче да булмаган. Тик бик сирәк очракларда авылга аю биетүчеләр килеп чыккалаган. Авыл халкы арасында дини хөрәфәтләргә ышану көчле булу сәбәпле, теге яки бу кешенең убыр, җен, абзар иясе, пичура күрүе турында хәбәрләр авылда еш таралып торган. «Кара йөзләр», «Миркәй белән Айсылу» әсәрләрендә язылган аяныч вакыйгалар караңгылыкта яшәгән Бәзәкә халкы тарихында да очраганнар.

Авыл халкы киндер яки җитен сүсеннән кул белән тукып өйдә җитештерелгән киемнәр кигән. Кышкы салкында да, җәйге эсседә дә, язгы һәм көзге пычракта да аякта чабата булган. Кыш көне кешеләр кечкенә өйләрдә яшь терлекләр белән бергә яшәгәннәр. Пыялалы керосин лампалары тик таза хәлле кешеләр өйләрендә генә янган.

Халыкка медицина хезмәте бөтенләй күрсәтелмәгән. Чәчәк эпидемиясеннән һәр елны күп бала үлгән яисә шадра булып калган. Халык арасында йогышлы авырулар еш тарала торган булган.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң Наркомпрос мөрәҗәгате нигезендә 1917 елның кышында Бәзәкә авылында беренче мәртәбә фән нигезләре өйрәтелә торган башлангыч мәктәп - совет мәктәбе ачылган. Ул мәктәпне ачып җибәрүче кеше авылдашыбыз Бәшаров Зиннур булган. Мәктәп Әхтәмҗан исемле кеше йортының

бер ягына урнашкан. Мәктәптә ана теле, рус теле, арифметика, география, рәсем һем башка фәннәр укытылган. Уку ике сменада алып барылган. Тик беренче елларда мәктәп 50-60 баланы гына укуга тарта алган. 1917-1918 елларда мәктәптә Бәшаров Зиннур, Искәндәров Нәҗип һәм Сибгать (фамилиясен хәтерләүче юк.- автордан) укытканнар.

1919-1920 елларда мәктәп туксанынчы елларга кадәр колхоз идарәсе урнашкан урында Рәфәгетдин мөәзин өенең бер ягына урнашкан. Бу елларда укытучылар булып Шакиров Фәйзи, Балтин Насыйри эшләгән. 1920 елның көзендә Балтин Насыйри юкка чыккан. Ул гражданнар сугышыннан яраланып кайткан партия әгъзасы булган. Күрәсең, аны совет властенә каршы кешеләр юк иткәннәр. Ул үз чыгышы белән хәзерге Әгерҗе районы Балтач авылыннан булган.

1922 елдан авылда өч урында укыта башлаганнар. Мәктәп инде үзенә йөздән артык баланы тарта алган. Бу елларда укытучы булып Әхмәдиев Авзалый (Әгерҗе районы Шаршады авылыннан), Йөзекөева Разия, Мәҗитов Нурый, Калимуллин Сәгъди ( өчесе да Камай авылыннан) эшләгәннәр. 1923-1925 елларда мәктәпкә яңа укытучылар - Бакиров Әхәт, Әхтәмова Сәрвәр килгәннәр.

Әлбәттә, ул еллардагы мәктәпләр * бүгенге мәктәпләрдән бик аерылып торганнар. Фәйзелхак абый Хөснетдинов искә төшерә: «Безне Бакиров Әхәт абый укытты. Уку әсбаплары бөтенләй юк иде. Мәктәпкә бер кесәбезгә акбур, икенчесенә чүпрәк тыгабыз, а култык астына ярты метр чамасында беркадәр шомартып эшләнгән такта кыстырып бара идек. Дәрестә арифметика да, ана теле дә, рәсем дә шушы тактада алып барылды. Әхәт абый кара тактада яза, ө без шуннан күчереп узебезнең тактага яздык. Китаплар булмады. Тик укырга шартлар булмаса да, мәктәпкә зур канәгатьлек белән йөри идек».

Бәзәкәдә беренче кино 1923-нче елда күрсәтелгән. Авылга кино килү зур вакыйга булган. Тегендә дә, монда да кешеләр «Томанный картина була икән»,- дип

сөйләгәннәр. Кайберәүләр «Аны карау бик зур гөнаһ, ул бик куркыныч була икән», - дип курыкканнар.

1925 елны авылга мәктәп салдыру өчен дәүләт тарафыннан акча бирелгән. Мәктәпне кайда салдыру мәсьәләсен хәл итү өчен җыелыш булган. Бу җыелышта кулаклар, муллалар мәктәпне авылдан читтә салынуын таләп иткәннәр. Алар: «шайтан оясының авылдан ерагырак булуы хәерле», - дип кычкырганнар. Мәктәпне инешнең сул ярындагы тау башында җиткерергә дип карар кабул ителгән. Мәктәп җиткерү өчен материал Чулман аръягындагы урманнан киселеп, язгы ташу вакытында сал белән авыл кырына алып кайтарылган. 1926 елның җәендә мөктөп төзү эшләре башланган һәм 7 ноябрьдә Октябрь бәйрәме хөрмәтенә мәктәп ачылган. Мәктәптә бу көнне тантаналы зур җыелыш булган. Җыелыштан соң балалар көче белән концерт куелган.

Мәктәп салдыру эшенә Әгъләмов Солтан җитәкчелек иткән. Мәктәптә аның белән бергә Әгъләмова Наилә, Мостафин Касыйм ( Тойгуҗа авылыннан) укытучы булып эшләгәннәр. Авылда мәгърифәтне, мәдәниятне үстерүдә авылдашыбыз Көләчев Гатаулла да күп көч куйган.

Авылда мәгърифәт һәм мәдәният үсеше каршылыксыз гына бармаган, әлбәттә. Кулаклар, муллалар күрсәткән каршылыклар белән көрәштә ускән һәм ныгыган Бәзәкә мәктәбе. Мәктәп салынгач, аңа пианино кайтартканнар. Мәктәптә балалар өчен хор түгәрәкләре оештырылган. Каршы элементлар мәктәптә җырланган җырлардан, укытучылардан көлү максаты белән түбәндәге такмакны чыгарганнар:

Аксак-туксак, җиксәк, китсәк,
Бар бит безнең туры атлар.
Тау башында мәктәп салып
Җырлар ята дураклар.

Күрсәтелгән каршылыкларны җиңә барып, авылда совет мәктәбе һәм мәдәният үсешләрен дәвам иткәннәр, торган саен үзләренә күбрәк кешеләрне тарта барганнар.

1927 елда Габдрахмановлар өенең ишек алдында пионер оешмасы төзелгән. Аны төзүче Казан педагогия институты студенты Имранов Зиннур булган. Пионер

оешмасына 17 бала кергән. Беренчеләрдән булып пионер сафына Бәдертдинова Әминә, Көләчева Мәрьям, Зиннәтуллина Гаян басканнар. Зиннур аларга көч-хәл белән кызыл галстуклар табып биргән. галстуклар кызыл материядән кисеп алынган кисәкләр булган. Мәрьям Гатаулла кызы Көләчева бу елларны болай дип искә ала: «Без мәктәпкә җитәрөк галстукны бергәләп тага идек тә, кайтканда байларның һәм әти-әниләрнең ачулануыннан куркып, барлык пионерлар да бер урында салып куя идек.» Яшь ленинчылар пионерлар турында җырлар җырлаганнар, концертлар куйганнар,авылга башка файдалы эшлар башкарганнар. Вакыт үткән саен башка балалар да пионерга керү теләге белән йөри башлаганнар. Тик шулай да 1933 елга пионерлар саны 23 кешедән артмаган.

1928-1929 елларда авылда кулаклардан тартып алынган йортларнын берничәсендә тагын сыйныфлар ачылган. Авылдагы уку яшендәге барлык балалар мәктәпкә тартылган. Авылда берничә урында өлкәннәр арасында наданлыкны бетерү мәктәпләреэшләгән. Авылга күп санда газета-журналлар кайтарыла башлаган. 1928 елда авылда Уку йорты ачылган. Анда мөдир булып Әхмәтшин Мөхәмәтдин (Камай авылыннан), аннан соң Фазуллин Фәләхи эшләгәннәр. 1929 елда Уку йортына беренче радиоалгыч алып кайтканнар. Бу авыл халкы очен зур яңалык булган. Зурлар аны «Раҗивай» дип йөрткәннәр. Аның сөйләүчесе радио эченә кереп утырган дип, радиоалгычны ачтырып караучылар да булган.

Авылда беренче . булыпүз хуҗалыгына радиоалгычны Мөхмүтов Хаҗиәхмәт алган.

Шул ук елларда бер кулагк йортында клуб ачылган. Ә соңыннан Уку йорты белән клуб бер йортка урнаштырылганнар. Клубта яшьләр күңел ачу кичәләре оештыра башлаганнар. Башта кичәләргә йөрүчеләр аз булган, тик көннән көн клубка йөрүчеләр саны арта башлаган. Беренче татар спектакле авылда 1930 елның Октябрь бәйрәмендә куелган.

Бөзәкөнең алдынгы яшьләре Мөхмүтов Хаҗиәхмәт, Исмагилов Ислам, Гарифуллин Фатыйх, Шибаев Әхмәтнәби, Әхмәтова Рәхимә, Ибәтуллина Камал, Нөбиуллина Бөдөр, Шакирова
Фәтхия һәм башкалар катнашында Г.Камалның «Беренче театр» әсәре сәхнәгә куелган. Бу хәл авыл динчеләре, надан халык арасында ачу тудырган. Спектакльдә катнашучыларга төрлечә янаганнар, аларны начар сүзләр белән каргаганнар. Ләкин яшьләр янау, каргаулардан курыкмыйча мәдәнияткә омтылуларын дәвам иткәннәр. Шул көннән башлап клубта сәхнәләштерелгән күренешләр, концертлар куела башлаган. Ул заманда Бәзәкөнең атаклы җырчысы булып Шибаев Әхмәтнәби, иң оста гармунчы итеп Исмәгыйлов Шакый исәпләнгән.

1933 елда Бәзәкәдә беренче балалар яслесе, 1934 елда балалар бакчасы ачылган. Ул түбән очта яшәүче Миңнехан бабайнын өе урынында булган. Балалар бакчасының җитәкчесе Мөхёмәтҗанова Зифа, тәрбиячесе Хаҗиева Фәйрүзә, пешекчесе Исламова Гөлҗиһан булган. 1941 елда балалар бакчасы югары очтагы мәчет бинасына күчерелгән.

1934 елда беренче тапкыр Казан филармония артистлары басуда эшләүче колхозчылар өчен ындыр табагында концерт куйганнар. Бу елларда инде кинофильмнар еш күрсәтелгән. Ләкин алар тавышсыз булган. Фәйзелхак абый Хөснетдинов искә ала: «Кинога керер өчен киномеханикка бурегеңне бирәсең дә чиратлап бер пәрдә беткәнче кул белән хәрәкәткә китерелә торган моторны әйләндерәсең, калган пәрдәләрне утырып карыйсың. Кино беткәч механик бүрекләрне өләшә иде». Шул юл белән бушлай кино карый торган булганнар...

1935 елда шәһәрләрдә тавышлы кино курсәтелә башлаган. Күршедәге Бондюг поселогында бер атна буенча кинофестиваль оештырылган. Бәзәкә яшьләре атларга төялеп, Бондюгка кино карарга барганнар. Анда «Чапаев» кинофильмы күрсәтелгән. Бу вакытта халык телендә гел шул «Чапаев» картинасы хакында сүз барган.

1937 елда Бәзәкәдә хәзерге мәдәният йорты кырындагы урында агачтан махсус клуб бинасы җиткерелгән. Бу заманда клуб инде авылның мәдәният учагына әверелгән. Анда еш кына җыелышлар, спектакльләр, концертлар, киносеанслар, яшьләр өчен куңел ачу кичәләре үткәрелгән. Бигрәк тә клуб мөдире булып Әхмәтҗанов Г әлиәхмәт эшләгәндә клуб советы членнары актив эшләгәннәр.

1930-нчы елда Бәзәкәдә кичке 5-нче - сыйныф ачылган.

Авыл яшьләренең мәгарифкә, мәдәнияткә омтылуында зур роль уйнаган комсомол оешмасы Бәзәкәдә 1931 елда төзелгән. Беренче булып комсомолга Ганиев Габденур кергән. Беренчеләр рәтендә шулай ук Хөснетдинов Габделхак (беренче комсомол оешмасы секретаре булып сайланган), Закиров Минәхмәт, Камалиев Нәби, Мәүләвиева Фатыйма, Хөснетдинов Галиәхмәт. Алар җыелып китаплар укыганнар. Берәү укыган, а калганнары тыңлап торган. Комсомол оешмасы яшьләр арасында коммунистик пропаганда һәм агитация эшләре алып барган, төрле кичәләр, концертлар оештырган. Тора-бара яшьләр үзлегеннән укырга өйрәнгәннәр, авылда наданлыкны бетерүдә, авылда коллективлаштыру эшләрендә, сәясәттә актив катнашканнар. 1932 елда Минәхмәтов Нәби, Закиров Минәхмәт комсомол путевкасы белән авыр промышленностька эшкә, Мәүлевиева Фатыйма укырга киткәннәр.[4]

1930-1933 елларда мәктәптә директор булып Фаезов Мәгъсүм эшләгән. Аның заманында мәктәп хуҗалыгы бик нык үскән. Мәктәпнең узенең ярдәмче хуҗалыгы, ягъни чәчүлек җире, яшелчә бакчасы, сыерлары, куяннары, мастерское булдырылган. Аларда җәй айларында эшләр өчен укучылар бригадасы оештырылган.

Бу елларда укытучылар саны 12-гә җиткән. Шушы елларда мәктәпкә яшь кенә.бер кыз - Бәзәкә килене Вәлиәхмәтова Оркыя килгән.

1933-1934 елларда көндезге 5-сыйныф ачылган. Шул көннән алып Бәзәкә мәктәбе жидееллыкка әйләнгән. Бу елларда мәктәп директоры булып Тукиев (исемен хәтерләүче юк.-автордан), Зәйнуллин Фәрди, укытучылар Вәлиәхмәтова Оркыя, Садыйфов Гата, Садыйфова Гөлсем, Шакирова Хәйрия, Акманаев Габдрахман, Камалиева Фәйрүзә, Ганиева Зәйтүнә, Камалов Хәмит һәм Камалова Фатыйма (күренекле татар язучысы Барлас Камаловның әтисе белән әнисе), композитор Марс Макаровның әтисе Макаров (исемен хәтерләүче юк. - автордан) һәм башкалар эшләгәннәр. Бу елларда мәктәп берничә урында урнашкан булган. Мәктәп яшендәге балалар барысы да укуга тартылып беткән. Укучылар саны 500-600-гә җиткән. Бәзәкәгә килеп 4-7 сыйныфларда Сәйтәк, Татар Тәкәше, Мари Тәкәш балалары да укыган.

1937-1938 уку елында Бәзәкә мәктәбендә 8- сыйныф ачылган. Шул көннән башлап ул урта мәктәп булып исәпләнә башлаган. Урта мәктәп директоры булып Мәрданов Габдрахман билгеләнгән. 1935-1939 елларда югарыда атап үтелгән укытучылардан башка мәктәптә Аюпов Гәли, Гайнуллина Гөлсем, Әхмәтова Фатыйма, Белов Сергей, Зиннурова Сания, Садыйков Фәтхи һәм башкалар эшләгән.

1936 елда мәктәптә комсомол оешмасы оештырылган. Чөнки бу вакытта мәктәптә комсомол укытучы яшьләр эшли башлаган, алар укучыларны комсомол сафларына тартканнар. Пионер оешмасын мәктәптә оештырып җибәрүче укытучы Әгъләмова Наилә булган. Тик оешма өзлексез эшли алмаган. Бары тик 1931 елда Вәлиәхмәтова Оркыя пионер оешмасын яңадан оештыргач кына яшь ленинчылар саны арткан һәм мәктәптә күңелле пионер эшләре оештырыла башлаган. Пионерлар саны арткач мәктәпкә махсус өлкән вожатый булып Әхмәтшин Харис (Тойма авылыннан) килгән. Аннан соң пионер оешмасы белән Мөхәммәтдинов Шәех (Псәй авылыннан), Бәдретдинова Әминә җитәкчелек иткәннәр.

Бу вакытларда укытучылар барысы да махсус урта белем белән яки 7 сыйныфны тәмамлаганнан соң

берничә айлык укытучылар курслары гына тәмамлаган булган. Урта мәктәптә укыту өчен югары белемле укытучылар кирәк була башлаган. 1939-1940 елларда мәктәптә югары белемле, аерым' фәннәр буенча көчле укытучылар Мөхәмәдиев Нәкый һәм Гыйльфанов Габделхәй математика, Федорова Дарья химия, биология укыта башлаганнар.

1940 елда Бәзәкә урта мәктәбе беренче чыгарылыш ясаган. Бу тантаналы кичәдә өлгергәнлек аттестаты алучылар арасында мәктәбебездә соңырак куп еллар укытучы булып эшләгән Аюпова Гаян, Көләчева Мәрьям, Бәдретдинова Әминә булганнар.

1941 елны башланып киткән Бөек Ватан сугышы нәтиҗәсендә Бәзәкә мәктәбе яңадан 7-еллыкка әверелгән. Күп кенә укытучылар сугышка китүгә карамастан авыр елларда мәктәп коллективы Аюпов Гәли, Гайнуллина Гөлсем, Вәлиәхмәтова Оркыя җитәкчелегендә балаларга белем һәм тәрбия бирү эшен дәвам иткән. Бу елларда мәктәп директорлары булып Усманов Хәлил, аннан соң Әхмәтов Гайнан эшләгәннәр.

Сугыштан соңгы елларда укучылар, укытучылар бергәләп мәктәп хуҗалыгын торгызу өчен байтак кына эш башкарганнар. МӘктәп кырында зур гына тәҗрибә участогы барлыкка килгән. Укытучылар коллективы зур энтузиазм белән эшли башлаган. Үз белемнәрен күтәру максаты белән күбесе читтән торып укыган. Тиздән мәктәптә югары белемле укытучылар саны арткан. Укытучылар аерым фәннәр буенча укыта башлаганнар: Гыйльфанов Габделхай - математикадан, Көләчев Фоат - физикадан, Аюпова Гаян -тарихтан, Хөснетдинов Фәйзелхак - немец теленнән, Төхвәтуллин Әхәт - географиядән, Галимуллина Мәүлидә - биологиядән, Бәшаров

... 62 Рәшит һәм Әхмәтова Мансура - рус теленнән, Салихова Фирая - химиядән, Мөхәммәтдинова Мөсхудө - ана теленнән, Аликин Нурулла - рәсем, ж,ыр, физкультурадан һ.б. Сугыштан соңгы елларда Бәзәкә урта мәктәбе укытучылар коллективы бердәм, дәртле, көчле бер гаилә булып яшәгән. Ул балаларга белем-тәрбия биреп кенә чикләнмәгән, халык арасында агитация-пропаганда эшләре алып баруда, авыл халкына мәдәни хезмәт күрсәтүдә аеруча актив эшләгән.

Ләкин Бәзәкәдә әле укыту төрле урыннардагы биналарда алып барылган. 1944 елда мәктәптә яңадан ике 8- сыйныф ачылган. Мәктәп яңадан урта мәктәп булып киткән. Укучылар күп булганлыктан, укулар өч сменда алып барылган. Фәйзелхак Хөснетдинов истәлегеннән: «Минем бүгенгедәй хәтеремдә әле: кичләрен укулар керосин лампалары астында алып барыла иде. Лампалардан сөрем чыга иде. Тәнәфестә укытучылар укучылар борыннарына утырган сөремне чистарталар иде. Ә шулай да уку- укыту барды. 1956-нчы елда мәктәп директоры Гыймадиев Муллый булган вакытта мәктәпкә электродвижок кайтарылды. Шуннан башлап электродвижок лампочкасы астында укыта башладык. Шушы елны мәктәпкә беренче «Киев» маркалы киноаппарат кайтты. Электродвижокны көйләү, кино күрсәтү эшләрен Көләчев Фоат алып барды. 1959 елда без электр энергиясен көчле көчәнешле линиядән ала башладык».

1958 елда авылның тарихында кара көн булып кергән вакыйга булган. Июль аеның караңгы бер төнендә түбән очтагы коммунистлар тарафыннан йозак белән бикләнгән, халык сукмагы өзелгән мәчетнең манарасын кисеп аударганнар. Иртән йөзләренә кайгы сарган кешеләр ауган манара янына ж,ыелганнар. Болында печән чабучы ирләр атларга атланып авылга кайтканнар. Халык күңеле кителгән, күзләрдән яшь аккан, бәгырьләр өзгәләнгән. Манарадагы оялары тузган, балаларын җуйган күгәрченнәр атна буе мәчет өстендә очып йөргәннәр. Авыл женаза чыккан йорт кебек моңаеп,

мескенләнеп калган.

Әй манара, синең аең бик ерактан ялтырый,
Әй манара, син ауганда җирдә адәм калтырый.
Әй манара, сине инде фасик бәндәләр кисте,
Әй манара, бәхил бул дип, кыйбладан җилләр исте, - дип Бәзәкә халкы бу турыда бәет тә чыгарган.

1958-1959 елларда мәктәп директоры булып Галиев Муллаян эшләгән чорда коллектив алдына мәктәпкә Псәй, Турай авылларыннан укучылар килү сәбәпле укыту бүлмәләре җитмәү һәм интернат кирәклеге проблемалары килеп баскан. 1961 елда аның инициативасы белән яңа мәктәп төзелә башлаган. Аны колхоз 5 ел дәвамында төзегән. Галиев Муллаян киткәннән соң мәктәп директоры Гыйльмуллин Камиль бу эшне дәвам иткән. Гомумән, ул директор булган дәвердә күп кенә яңалыклар барлыкка килгән. Аның төп сыйфаты - мәктәп коллективын туплау. Мәктәптә көчле һәм кызыклы экспериментлар үткәрелгән, педагогика фәне яңалыкларын Бәзәкә укытучылары шәһәр укытучыларына караганда да тизрәк мәктәп тормышына керткәннәр, республика һәм район күләмендәүткәрелгән фәнни-практик конференцияләрдә актив катнашканнар. Мәктәп хуҗалыгы нык үскән. Мәктәп хуҗалык мөдире Мөхәмәтдинов Минәхмәт тә хуҗалыкны ныгытуда зур эшләр башкарган. Мәктәп янында 70 кешелек интернат барлыкка килгән.

1967 елның 13 октябрендә Татарстанның атказанган укытучысы Гыйльфанов Габделхәй директор булган чорда мәктәпнең хәзерге бинасы ачылган. Укыту-тәрбия эшләрен камилләштерү өчен яңа шартлар тудырылган. Тик шулай да башлангыч сыйныфлар түбән очтагы элеккеге мәчет бинасында калганнар. Яңа мәктәптә укыту ике сменада алып барылган. 1968 елда мәктәптә директор булып Татарстанның атказанган укытучысы Бәшаров Рәшит эшли башлаган. Ул Гыйльфанов Габделхәй үрнәгендә мәктәптә эстетик тәрбия бирүгә зур әһәмият биргән. Ул мәктәп бинасын зурайту өстендә югары органнар

алдында күп эшләр алып барган. Ниһаять 1969 елда мәктәпкә тагын элекке кадәр өстәмә бина төзергә рөхсәт ителгән. Ләкин 1971 елда мәктәпкә зур кайгы килгән - рус телен укытуны тәмам юлга салган, республиканың күренекле галим укытучысы, методисты, армас-талмас тынгысыз Рәшит Бәшаров вафат булган. Ләкин Бәзәкә мәктәбе укытучылар коллективы бу югалтудан каушап калмаска, үз эшен түбән төшермәскә карар кылган. Директор булып яңадан Гыйльфанов Габделхәй, аның урынбасарлары итеп Көләчев Фоат һәм Ибәтуллина Шәмсия билгеләнгәннәр. Ул вакытта мәктәп коллективы нык, эшчән, дус, бердәм булып формалашкан булган инде. Татарстанның атказанган укытучысы Мәхмүтова Нажия, кандидатлык диссертациясе өстендә эшләүче Әхмәтова Мансура, Аюпова Гаян, Бәдертдинова Әминә, Хөснетдинов Фәйзелхак һәм аның тормыш иптәше Галиева Зәйтүнә, Роза Кәлимуллина, Гыйльфанов Габделхәйнең тормыш иптәше Галимуллина Мәулидә.Салихова Фирая, Төхвәтуллин Әхәт һәм аның тормыш иптәше Мөхәмәтдинова Мәсхүдә, бертуган Көләчевлар: Көләчев Фоат һәм аның тормыш иптәше Таҗетдинова Мәүлидә, Көләчева Мәрьям, Көләчев Тәгъзим һәм Гатауллина Мәэлүфә, Таҗиев Мулланур, Аликин Нурулла, өлкән пионервожатые Әдия Ибраева һ.б. армый-талмый чын күңелдән эшкә бирелеп Бәзәкә балаларын укыткан-тәрбияләгән. Алар укытып чыгарган укучылар арасында галимнәр, укытучылар, колхоз председательләре, инженерлар, төрле өлкәләрдә эшләүче белгечләр үсеп чыктылар. Бәзәкә мәктәбен тәмамлаган авылдашларыбыз Мәскәү, Ленинград,
Казан, Уфа, Алабуга шәһәрләрендәге югары уку йортларына ел саен күп керәләр иде. Мәктәп республикада алдынгы тәҗрибә мәктәбе булып исәпләнде. Мәскәүдәнме, Казаннанмы нинди генә комиссия килмәсен, район җитәкчеләре тикшерүчеләрне иң беренче итеп Бәзәкә мәктәбенә алып киләләр иде. Ә район укытучылары өчен күпме ачык дәресләр, тәрбия чаралары, /методик киңәшмәләр үткәрелде! Район

мәктәпләре арасында оештырылган (Менделеевск шәһәре мәктәпләрен дә кертеп) үзешчән сәнгать смотрларында ел саен Бәзәкә укучылары беренче урынны алалар иде. Спорт ярышларында, төрле фәннәр буенча республика һәм район күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда бәзәкөлеләр призлы урыннарга ирешәләр иде. Әдия Ибраева гомере буе җитәкләгән пионер оешмасы район күләмендә Бөтенсоюз пионерлар Маршы, бишьеллыклары ярышында гел беренче урында булды. Мәктәпнең комсомол оешмасы шулай ук көчле оешмалардан исәпләнде, яшьләр белән гел рәттән Ибәтуллина Шәмсияне күрергә була иде.

Соңырак мәктәпкә Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлап көчле яшь укытучылар килде: Гыйльфанов Зиннур, Низаметдинова Мәрьям, Гөбәйдуллина Галия, Гыймазетдинова Рәмзия, Сабитова Роза, Мәхмутова Әнисә, Нөсифуллин Фәрит, Гимазов Дамир.Таҗиев Сәләхетдин, Сабитов Мөхәмәтнур һ.б. Күп еллар дәверендә мәктәп директоры булып Гыйльфанов Зиннур, Сабитов Мөхәмәтнур, Гимазов Дамир эшләделәр. Тәрбия эшләрен мәктәптә оста итеп оештыручы директор урынбасары Гимазова Шәмсия районда берүзе «СССРның мәгариф отличнигы» исеменә лаек булды. Бүгенге көндә мәктәпне Зиннәтуллин Наиль җитәкли. Мәктәп коллективы яшәрде дисәк тә була. Ләкин элеккеге матур традицияләр бүген дә укытучылар коллективында дәвам итә. Хәзерге көндә мәктәптә 120 бала белем ала.

Бу урында Бәзәкә урта мәктәбен алтын һәм көмеш медальләргә тәмамлаган укучыларны да атап үтәргә кирәк дип уйлыйм. Менә алар: Нәбиуллин Мансур Кәрим улы, Гимашев Мирзаһит Муллаян улы, Кәшбиева Рәмзия Әхмәтриза кызы, Аюпов Флюр Арслангәли улы, Нәҗметдинова Данфира Сәләхетдин кызы, Нәсифуллин Камиль Гәрәй улы, Көлимуллина Сәлимә Мөбәрак кызы, Гыйльфанов Рәфис Габделхәй улы, Мөхөмәтҗанов Зөфәр Гәрәй улы, Хүҗәхмәтова Гөлшат Фәрәхетдин кызы, Аюпова Рәвия Арслангәли кызы, Бәшаров Фәрит Рәшит улы, Кәлимуллин Рәшит Хаҗиәхмәт улы, Аюпова-Илсөяр Арслангәли кызы, Минехаҗиева Раушания

Габделхак кызы, Бикмөхәмәтова Илсөяр Саетҗан кызы, Гыйльфанова Резедә Зәки кызы, Хуҗина Әлфирә Мәхмүт кызы, Салихов Ильсур Галиәхмәт улы, Гыйльфанова Лилия Зәки кызы, Кәлимуллин Фәрит Мулләхмәт улы, Зиннәтуллина Ләйсән Җәүдәт кызы, Җамалетдинова Элмира Разит кызы, Сабитова Лилиана Рафаиз кызы һ.б.

Авылның мәдәни тормышында да зур үзгәрешләр булды. Авылда Мәдәният йорты җиткерелде. Аны җиткерүдә төзүчеләр җитәкчесе Габдрахман Габденуров күп көч куйды. Анда киң экранлы кинофильмнар күрсәтелә башлады. Күп еллар буе клуб мөдире булып Әхмәтҗанова Вәгыйдә, китапханә мөдире булып Шакирова Накия эшләделәр. Алар авылдашларыбызда әдәбияткә, үзешчән сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә, авылның мәдәни тормышын җанландыруда күп көч куйдылар. Авылның киномеханиклары Гыйльфанов Зәки һәм Бәхтигәрәев Вәгыйз дә авыл мәдәниятен үстерүдә күп өлеш кертте. 50-80 еллардагы авылның талантлы үзешчән артистларын әйтеп китик: Әхмәтжановлар Вәгыйдә һәм Нургәли, Нәсифуллиннар Тәскирә һәм Рәвил,
Мәхмүтова Әнисә, Шагина Әнисә, Сабирова Накия, Бәшаров Фәрит, Нәжметдинов Сәетнур, Бөхтегәрәевалар Әлфинә һәм Мөнирә, Мөхәмәтҗанова Гөлсинә, Шәймарданова Гөлфирә, Хәбибуллина Сабира, Гыйльфанов Кәүсәр, Таҗиев Сәләхетдин, Гыймазетдинова Рәмзия, Сабитов Мөхәмәтнур, Гимашевалар Мәүлия һәм Рәмзия, Әһлиева Гөлфәния, Шәймөхәмәтова ' Рәмзия, Хисаметдинов Хаҗиәхмәт, Гыйззәтуллиннар Ильяс һәм Ильгиз, Әһлиева Илсөяр, Садриевлар Рәмзия, Шәмсия, Рәвил һ.б.

## БӘЗӘКӨНЕҢ ЙӨЗЕК КАШЛАРЫ

!

Фәния Шакирова **Алар гузәл кешеләр**

Авылымның табигате Яшәр өчен көч биргән.

Изге сулы чишмәләре Күп
талантлар үстергән.
Һәрчак иртән гөрләп тора
Авылымның мәктәбе.
Тагын күпме талант бирер
Яшьләр бик күп бит әле.
Саный китсәң исең китәр Дәрәҗәле
исемнәр.
Уз һөнәренә лаёклы Алар гүзәл
кешеләр.

### Авылның асыл заты

Мансура җыйнак гәүдәле, күрер күзгә кырысрак, шул ук вакытта бик мөлаем ханым. Ул Алабуга районының Бехтерев исемендәге колхозның рәисе. Республикабызда хуҗалык рәисе булып эшләүче ун хатын-кыз арасында иң яше. Ул җитәкләгән хуҗалык районда алдынгылардан санала.

Хатын-кыз - кавемебезнең иң асыл заты, яшәешебезнең яме, бизәге, нәзакәте, дибез. Ул узенең табигате буенча гаилә учагының хуҗабикөсе, мәрхәмәтле ана булырга тиеш, дибез. Тик безнең заманда хатын-кыз еш кына узенең төп асылын югалта, эш аты, жөмгыять әгьзасына әверелә.

Мансура, бер яктан, гап-гади хатын-кыз заты. Икенче яктан, гаять узенчөлекле шәхес. Чисталык - пөхтәлек, тәртип, уңайлык, матурлыкны ярата. Ялагайлыкка, икейөзлелеккә нәфрәтләнә, гаделлеккә, камиллеккә омтыла. Иң мөһиме - уз кешеләренә, туган авылына гашыйк. Ул үзен һич тә эш аты итеп санамый, эшеннән зарланмый. Ул бердә уфтанмый, борчу-шатлыгын йөзенә чыгармый, беркемгә дә тавышын кутәрми. Аның кул астында эшләгән кешеләр йөзендә җитәкчегә карата ихтирам хисләре генә чагылганын күрергә була.

Мансураның әнисе Миңнеҗамал апа, чал чәчле, кызы кебек мөлаем йөзле ханым. Хәмәт абый белән дүрт кыз, бер егет үстерделәр алар. Бишесенө дә югары белем бирделәр. Мансур белән Миннур - табиблар, Мансура - уртанчы кыз - авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады, ә Гөлфирә белән Илсөярә - укытучылар. Татарстанда мондый гаиләләр бардыр, әмма Бәзәкәдә Сәлимуллиннар кебек гаилә бер генә. Курәсез, Миннеҗамал апаның горурланырлыгы бар. Хәер, аның узе турында да китап язарга мөмкин. Ул да уникe хатын-кыз белен бергә 1971 елда тракторчылар курсына укырга китә. Бу вакытта ул биш бала анасы була. 1975 елда алар арасыннан сигезе Мәскәүгә, алдыңгылар слетына бара. Бергә укыган хатыннар әкренләп бу авыр хезмәтне ташлый, Миңнеҗамал апа исә 63 яшенә кадәр, тракторчы булып эшли. «Мансурага елларның авыры, эшләрнең саллысы төште инде, - ди ана борчылгандай. - Балан, гөлҗимеш җыю дисеңме, бала карау, печән чабу дисеңме - барысы да эләкте. Шуңа нык булып ускәндер».

Түрдә Миңнеҗамал "присидөтел" кызына узе "присидател" булып утыра: «Чәчүеңне төгәлләдеңме? Култиләдеңме? Ашлама керттеңме? Печән өләштеңме? Уракка төштеңме?» «Нива»

машинасында Бәзәкәгә юнәлгәндә Мансура әнисенең бу сорауларына алдан әзерләнеп кайта, аның борчылып торганын белә ул. Ни дисәң дә, әнисе районның алдынгы механизаторы- булган кеше, атказанган колхозчы бит. Аны коры сүз белән гена ышандырып булмый.

Мансура Мәскәүдә авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең Бөтенрәсәй киңәшмәсендә катнашкан рәис. «Һәркем үзен борчыган проблемалар хакында сөйләде, - ди ул. - Аларның асылы авыл җире өчен уртак булып чыкты: безгә, ипи, ит җитештерүчегә булган караш. Авыл хуҗалыгына ташламалы кредитлар бирү, техника алу буенча файдалы килешүләр төзү мәсьәләләре хәл ителсә, авыл җирендә эшләргә, авылны яшәтергә һәм яшәртергә мөмкинлекләр артыр иде».

Мансура - замана җитәкчесе. Күп сыйфатларының нәкъ менә эшлекле хатын-кызларга хас икәнлеген күреп сокланырсың. Кеше хакында аның эше буенча нәтиҗә ясый, шул ук вакытта башкалар фикеренә дә колак сала белә. Узенә карата да таләпчән диләр аның турында. Кемдер өчен ул «ут хатын», «безнең Хәмәтовна» булса, кайбер олы яшьтәгеләр аның янына киңәшергә, серләшергә киләләр. «Рәислек һөнәр тугел, ул - җаваплылык», - ди үзе Мансура.

Мансура исеме гарәпчә «җиңүче хатын-кыз» дигән мәгънәне аңлата икән. Иншалла, безнең Мансурабыз да бу исемгә лаек зат булып яшәр.
(М.Сәлимуллина турында очерк Г.Сәрварова мәкаләсе нигезендә төзелде).

## Туган якның китмәс кошы

Бәзәкәнең үзәк урамында, авылның урта бер жиренде гади генә бер йорт бар. Албакчада үсеп утыручы миләш агачы үтеп баручыларны моңсу гына каршы ала, яфракларын шыбырдатып озатып кала. Бу йортта 1944 елның 11 декабрендә авылыбызның иң нечкә күңелле, хисләргә, моңга бай кешесе шагыйрь Марсель Гыймазетдинов туган. Әтисе Гыйльфан абый - колхоз рәисе, әнисе Газдә апа йорт хуҗабикәсе булган. Мәктәптә беренче сыйныфтан ук Марсель үзен тырыш, зиһенле, фәннәрне җиңел үзләштерүче, чаңгыда иң тиз

йөрүче итеп таныткан. Үзенең бик хәрәкәтчән, туры һәм үткен сүзле булуы белән иптәшләреннән аерылып торган. Өлкән сыйныфларда комсомол комитетында җаваплы эшләр башкарган. Бәзәкә мәктәбен тәмамлагач, Алабуга педагогия институтында татар филологиясе факультетында укыган. Армиядә хезмәт итеп кайткач, үз белгечлеге буенча Тойгуҗа авылы мәктәбендә укыткан. Аннан соң Ык Тамагында мәктәп директоры булып эшләгән. Шул елларда гаилә корып җибәргән. Тихоново авылында, Менделеевск шәһәренең махсус мәктәп - интернатында директор булып эшләгән. Укыту- тәрбия эшләре Марсельгә бик ошаса да, аның күңеле тагын да җанлырак һәм җитдирәк эшкә тартылган. «Тойма» совхозы партия оешмасы секретаре, 543 тәзү-монтаж поезды начальнигы урынбасары, «Батыр кул» колхозы партия оешмасы секретаре, Тукай исемендәге колхоз рәисе...

Марсель Гыймазетдинов республикабызда колхоз рәисе булып кына түгел, ә шагыйрь, берничә китап авторы булып та танылган шәхес. Беренче шигырьләрен ул 5 сыйныфта укыганда ук яза башлаган, район газетасында бастырган. Беренче китабы «Аккош канат кагына», икенчесе «Яшәү мәгънәсе» дип атала. 1992 елда аның «Язлардан алалмыйм күземне» исемле китабы, 1994 елда «Син мине белмисең» шигырьләр җыентыгы дөнья
күрәләр. Аның шигырьләре туган якка, туган авылга, авылдашларга, якташларга багышланган. Ул авыл кешесенә- игенчегә дан җырлый. Җырлый дигәннән, аның бик күп шигырьләренә төрле композиторлар тарафыннан матур-матур көйләр язылды. Луиза Батыр-Болгари, Зөфәр Хәйретдинов, Ильгиз Закиров һәм башка композиторлар Марсельнең. иҗади дуслары булалар. Аның җырларын , Зөһрә Шәрифуллина, Резиде Шәрәфиева, Габдельфәт Сафин, Салават Фәтхетдинов, Рамиль Миндияр, Зәйнәп Фәрхетдинова шикелле популяр җырчылар башкаралар. «Туган авылыбыз Бәзәкә» шигыренә композитор Владимир Мироваев җыр иҗат итте.

Татарстан радиосыннан ясаган бер чыгышында Марсель Гыймазетдинов үзенең иҗаты турында фикер

йөртеп болай дигән иде:
- Мин Менделеевск районында колхоз рәисе булып эшлим. Билгеле инде, ярты гомерем басу-кырларда үтте. Яз уянып кына килгән бер мәлдәме, яисә җәйге иртә-кичләрдәме, йә булмаса көзгә кергәчме - кырлар түренә карап уйланып торасың да, ирексездән күңелгә шатлык хисләре тула һәм үзең дә сизмәстән: »Матур бу дөнья!»- дип куясың. Мондый чакларда тормышның вак-төяк мәшәкатьләре онытылып китә, иркен сулыш белән яшисе килә башлый: Һәм мин уй-хисләремне, кодрәтемнән килгәнчә, кәгазьгә төшереп барырга тырышам».
...Гомерен басу-кырларга багышлаган шагыйрьнең җырларына әле башаклар шавы, тургайлар моңы килеп кушыла («чыксам әгәр иркен басуларга, тургай моңы чыңлый колакта»), анда «буразналар кояш назлавыннан кара икмәк кебек күперә»; кырларда аның «йөрәккәе бәйгедәге аттай җилкенә» башлый. Ул тормышның тәмен белеп яшәде, ул оптимист иде. Кыскасы, үз шигырьләрендә Марсель игенчегә, туган авылына, туган ягына мәдхия җырлады:

Саулармы сез, туган як кырлары!..
Кайтам сезгә, кайтам кайгысыз...
Изге җирсез - туган яктан башка Яши
ала, әйтче, кайсыгыз?!

Исәнмесез, яшел тугайларым,
Атлар көткән иркен болыннар?
Һаман сездә балачактагыдай,
Чабып йөри икән колыннар.

Ии хәлләрдә, авыл агайлары,
Исәнмесез, әби-апалар.
Туып-ускән җирен ташлаганнар
Саргаешып кире кайталар.

Саулармысез, туган-тумачалар!
Исәнмесез, курше-күләннәр.
Туган якларына ашкындылар Чит
җирләрдә яшәп үлгәннәр.

Ә мин кайтам, нык-нык басып кайтам,
Сине сагынып, яшьли торган җир.
Син гомергә яшә, анам кебек,

Иң кадерле, садә, туган җир...



Марсель Гыймазетдинов күренекле җәмәгать эшлеклесе дә булды. Аның җәмәгать эшләрен санап бетереп булмас: Менделеевск районының милли мәҗлесе рәисе, драма халык театры артисты, Бөтендөнья татар конгрессы делегаты, Менделеевск районында «Ядкарь» исемле әдәби-музыкаль берләшмәгә нигез салучы, җырчы Вафира Гыйззәтуллина белән бергә төрле кичәләр, бәйрәмнәр, уеннар оештыручы һәм башкалар ...

«Туган җирнең китмәс җырчы кошы» булып, җирдә яз ясап яшисе иде дә бит, тик рәхимсез улем Марсель Гыймазетдиновны 1993 елда арабыздан алып китте. Үзе үлсә дә, җырлары, шигырьләре яши аның:

Яшәсәгез җирдә озак еллар,
Яшәү дәрте өстәп халкыма,
Шигырьләрем, бар йөрәк җылысын
Бирәм сезгә халкым хакына.

(Марсель Гыймазетдинов турында очерк Наис Гамбәр, Рәмзия Мөхетдинова туплаган материаллардан файдаланып язылды)

## Гыйлембәшәрнекеләрнең берсе

Авыл тарихы турында бәян иткәндә без сезне Гыйлембөшәрнекелөрнең берничәсе белән таныштырдык инде. Ә хәзер Татарстанның атказанган укытучысы Рәшит Госман улы Бәшаров белән якыннан танышып үтик.

Рәшит абый кечкенәдән белемга омтылучан, яңалык белән кызыксынучан булып ускән. Туганнары арасында башлы, тапкыр, өлгер булуы белән аерылып торган. Мәктәптә укыганда ук ул актив эзләнүче, ялкынлы пропагандист булган.

Алабуга шәһәрендә педагогия училищесены тәмамлап, авылга кайтып рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлаган. Рус телен үзе яхшы белүче, аның проблемалары белән кызыксынучы Рәшит Госман улы әлбәттә укучыларда рус халык мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләүдә зур уңышларга ирешкән. Шуңа

күрә ул район методик берләшмәсенең иң актив, педагогик тәҗрибәне өйрәнеп таратучы булган. Мәктәптә рус телен укыту өлкәсендә экспериментал ь эшләр үткәргән.

Рәшит Бәшаров Татарстан һәм Рәсәй күләмендә үткәрелгән педагогик укуларда, фәнни-практик конференцияләрдә докладлар белән чыгыш ясаган. Аның татар мәктәпләрендә русча дөрес сөйләшү күнекмәләренә өйрәтү, дәресләрдә яңа методик алымнар куллану, диалог сөйләмнең белем бирүдә һәм балаларны тәрбияләүдә ролеише проблемалар буенча фәнни мәкаләләре китапларда, газеталарда бастырылган. Анын тарафыннан дәресләр өчен күп һәм төрле дидактик материаллар хәзерләнгән. Мәскәү галимнәре аның фәнни-теоретик һәм мето-
дик уңышларын күреп аспирантурага укырга керерга тәкъдим иткәннәр, Рәшит Госман улы читтән торып Алабуга педагогия институтының филология факультетын тәмамлаган. 1966 елда аңа «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелгән.

Рәшит абый күп еллар мәктәп директоры һәм аның урынбасары Вазыйфаларын үтәгән. Ул җитәкче булган вакыт - мәктәптә демократик үзгәртүләр, балаларны эстетик тәрбияләүдә борылыш ясаган чор. Ә үткәргән дәресләрен анын укучылары әле хәзер дә сагынып искә алалар. Һәр укучыны шәхес итеп карап, аның белән киңәшеп эш итә иде яраткан укытучыбыз. Миңа ул мәктәптә директор булган чорда укырга туры килде. Комсомол секретаре
вазифаларын үтәгәндә мин аның ярдәмен һәрвакыт тойдым. Ул комсомолецларга ышана, проблемаларны чишу юлларын үзебезгә сайлап алырга, үз мөмкинлекләребезгә ышанырга булыша иде.

Рәшит Госман улы - авылда пропаганда-агитация эшләрендә актив катнашкан укытучы. Колхоз радиосы буенча аның җитәкчелегендә тапшырулар хәзерләп үткәрелгән. Бәзәкә артистларын җыеп Казан радиосы

өчен тапшыру хәзерләгән. Ул колхоз тормышына багышланган «Вөждан бурычы» исемле 3 пәрдәдән торган пьеса авторы, клуб сәхнәләрендә күп рольләрне үзе оста итеп башкарган.

Бәшаровлар гаиләсе күпләргә үрнәк, тату, бердәм булып яшәде һәм яши. Фирая апа - алдынгы химия укытучысы, сабыр холыклы, гади һәм ачык күңелле хатын. Зур улы Фәрит югары белемле белгеч, дәүләт һәм җәмәгать оешмалары җитәкчесе, ул һәм энесе Халит тату гаилә башлыклары. Раушания да Бәшаровлар фамилиясенә тап төшерми яши.

Рәшит абыйның киләчәккә планнары зур иде, тик аларны башкарырга аңа язмады. Явыз чир аны арабыздан алып китте. Планнарын аның кул астында үсеп, педагог булып эшләүче укучылары дәвам итә...

### Бертуган Гыймадиевлар

Хәмәт абый Гыймадиев гомер буе сату эшендә эшләгән. Тормыш иптәше Гөлсем апа белән бер кыз, дүрт малай үстергән.Балаларына төпле -белем, хезмәт күнекмәләре бирергә, аларны кеше ^итәргә тырышкан.

Кызы Мансура әтисе янында сатучы эшенә өйрәнеп, башта сатучы, аннан соң сельпода җитәкче һәм күп еллар авыл советы рәисе булып эшләде.

Зур уллары Рәвил яшьтән үк хәрби кеше булу турында хыялланган. Мәктәптән соң Мәскәүдә хәрби училище бетергән, армия сафларында хезмәт иткән. Шуннан бирле ул Мәскәүдә яши. Бүгенге көндә без аны полковник дип беләбез.

Әнвәр Хәмәт улы югары белем алганнан соң Казан шәһәре электр челтәренең баш энергетигы булып эшләде, тик яман чир аны безнең арабыздан алып китте..

Миннезөфәр исә мәктәп бетергәч, Менделеевск райпосында башта грузчик булып, аннан соң шофер булып эшли башлаган. 1968 елда Васильевода автомобильләр техникумын тәмамлаган һәм күп еллар шушы өлкәдә җитәкче Вазыйфаларын үтәгән. Менә ничә ел инде Минезөфәр Хәмәт улы - Менделеевск шәһәренең АТП директоры. Аның кул астында 150-ләп

кеше эшли. АТП шәһәр буенча һәм шәһәрара маршрутлар буенча пассажирлар ташый. Айдан айга, елдан елга предприятие үз планын намус белән һәм вакытында үти. Монда җитәкченең зур өлеше бар. Ул үз кадрларына карата игътибарлык, әдәплелек, зирәклек күрсәтә, шуңа күрә дә аны коллектив нык ихтирам итә.

Миннезөфәр Гыймадиев буш вакытларында сәнгать белән кызыксына, шигырьләр яза, үзешчән шагыйрь- ләр һәм композиторлар белән дус. Берничә шигыренә көй дә язылды. Шулар арасында - Бәзәкәгә багышланган «Баллы чишмә» җыры. Гаиләдә игътибарлы ир һәм ата. Улы Айдар Карпов исемендәге химия заводында эшли. Кызы Алсу балалар тудыру йортында эшли һәм Алабуга педагогия институтының биология факультетында читтән торып укый.

Мөнәвир Хәмәт улы Яр Чаллыда күп еллар Алтынбаев белән рәттән виңе-мэр булып эшләде, хәзер ул шул ук шәһәрдә «Трестподряд» оешмасының генераль директоры.

Аның энесе Мансур берничә ел буенча Алабуга районында «Власть Советов» колхозы рәисе булып эшләде. Ул эшләгән дәвердә колхоз арттагылар рәтеннән алдынгылар рәтенә күчте. Аннан соң Менделеевск районының «Татарстан» колхозы рәисе булды.

Төпчек Рәшит Менделеевск шәһәрендә яши һәм ЖКОда бригадир булып эшли.

( Гимадиевлар турында язганда Фатыхов Нәҗипнең «Бондюжцы Татарстана» дигән китабыннан очерклар кулланылды).

### Мәңгелек яшь Әдия

Татарстанда аннан башка гомере буе пионерлар белән эшләгән кеше юктыр. Кызыл пионер галстугы бик килешә иде Әдия апага. Ул үзенең һәрвакыт бәхетле елмаюы, шат күңелле оптимист булуы, балалар күңелен күтәрә белүе белән районның өлкән вожатыйлары арасында аерылып торды. Ул җитәкләгән пионер дружинасы районда һәм республикада үзенең күркәм эшләре белән

билгеле иде. Республикада Бөтенсоюз пионер Маршы буенча үткәрелгән ярышларда, конкурсларда Бәзәкә пионерларының мактаулы исемнәргә, беренче урыннарга лаеклы булуы, ел саен үткәрелгән үзешчән сәнгать смотрларында Бәзәкә мәктәбе укучылар коллективының беренче урынны алуы - Әдия Сәлим кызының армый-талмый эшләү нәтиҗәсе. Балалар - фермада үз кешеләр, авыл колхозчылары алдында һәм күрше авылларда концерт куючылар, колхоз радиосы буенча махсус чыгарылыш ясаучылар, кечкенәләр өчен курчак театры күрсәтүчеләр. Авылның биючеләре барысы да беренче мәртәбә биергә Әдия апаларыннан өйрәнделәр. Ул бию-җыр остасы гына түгел, матур һәм кызыклы итеп хикәятләр, әкиятләр сөйләүче һәм сәхнәгә оста итеп музыкаль-әдәби композицияләр куючы да иде.

Тынгысыз Әдия кичә балалар белән туристик походта иде, бүген район семинарында үз тәҗрибәсе белән аралаша, ә иртәгә пионер строе смотры үткәрәчәк, берсекөнгә аны балалар агитбригадасы белән терлекчеләр көтә... Менә шулай көн саен тәҗрибәле педагог, балалар комиссары укучылар тормышын кызыклы һәм файдалы итеп оештырырга тырыша иде.

Гаиләдә дә Әдия Сәлимовна яратучы хатын һәм ана булды. Тормыш иптәше Гәрәй абый алдынгы нефтьче, уллары Мансур һәм Ралиф, кызлары Мансура һәм Гүзәлия Түбән Кама шәһәрендә бергәләп дус, чын туганнар булып яшиләр.

Берничә йөз пионер һәм үзенең 4 баласына чын кеше буларак гомере буе мәхәббәтен, йөрәк җылысын бүләк итеп яшәде Әдия Ибраева. Башкача булдыра алмас иде ул...

Аның тәэсире астында күп кенә авылдашларыбыз пионер эшенең активистлары булдылар. Сәләхетдин Таҗиев - пионер эше буенча кандидат диссертациясе яклады, үзе балалар оешмасы оештырды, җәй айларында пионер лагерларында эшләде, Мөхәммәтнур Сабитов - мәктәп директоры һәм район мәгариф бүлеге мөдире буларак Бәзәкә һәм Менделеевск районы пионерлары дусты булды,

Рәмзия Гыймазетдинова-Мөхетдинова Әдия апа лаеклы ялга чыккач мәктәпнең балалар оешмасын җитәкләде һәм җитәкли, Гөлсинә Мөхәмәтҗанова- Кәлимуллина китапханә хезмәткәре буларак һәрвакыт аеруча игътибарны балалар белән эшләүгә бирде, колхоз комсомол оешмасы секретаре булып эшләде, Сәетнур Нәҗметдинов - табиб булып эшләвенә карамастан балалар белән эшкә тартылды, Мөнирә Бәхтегәрәева-Нәҗметдинова - пионер- вожатые һәм Алабуга төзелеш трестында, училищеда комсомол оешмасы секретаре булып эшләде, Фәрит Бәшаров - Татарстанда иң зур булган Яр Чаллы шәһәр комсомол оешмасының беренче секретаре булды. Санап китсәң, аларның исемлеге йөзгә җитәргә мөмкин.

Әдия Ибраева - ВЛКСМ Үзәк Комитеты, Бөтенсоюз пионер оешмасының Үзәк Советы билгеләре һәм Почет Грамоталары белән бүләкләнде. Ул - халык мәгарифе отличнигы.

Әдия Сәлимовна 1999-нчы елда, кызганычка каршы вафат булды. Тик ул башлаган эшләр, традицияләр лаеклы кулларда. Аның эше дәвам итә. Әдия Ибраева безнең күңелләрдә яшь кызлардай чибәр, һәрвакыт шат йөзле, мөлаем, муенына кызыл галстук бәйләгән ханым булып мәңгелек сакланачак...

## Тату гаилә

Бәзәкә кешеләре турында язганда Фәйзелхак абый Хөснетдинов гаиләсе турында язмасаң зур гонаһ булыр иде. Авылдашларым беләләр: ул үзе дә, аның тормыш иптәше Зәйтүнә апа да, балалары Тәскирә, Кәүсәр, Зөһрә, Фәрит тә кешеләргә ихтирамлы, эчкерсез, гади, ярдәмчел булулары белән аерылып торалар.

Мин үзем, Кәүсәрнең якын дусты буларак, аларның гаиләсендә еш була идем, хәзер дә, авылга кайтсам, Фәйзелхак абый - ачык йөзе, камил җаны белән магнит сыман үзенә тарта торган олугь Кеше янына ашыгам. Ул беренчедән, минем немец телен укытучым. Институтка укырга кергәндә классташым Гөлсинә белән немец

теленнән керү имтиханы бирерга туры килде. Шундый яхшы итеп җавап биргәнбездер инде, имтихан алучы укытучылар безгә бишле билгесе куеп, «Сезне кем шулай яхшы итеп укытты? - дип кызыксындылар. - Сезнең сөйләмегез да чын немецларныкы кебек».

Икенчедән, Фәйзелхак абый тарих укытучысы да буларак, туган як, авыл тарихын өйрәнүче һәм язучы. Бәзәкә шәҗәрәсен саклаучы һәм гарәп теленнән татар теленә тәрҗемә итүче. Бу очеркларны язганда аның күп кенә кулъязма материаллары кулланылды.

Өченчедән, Зәйтүнә апа белән абый мине яратып «өченче улыбыз» дип йөрттеләр. Белгәнемчә, андый «уллары» аларның Бәзәкә кешеләре арасында байтак икән.

Фәйзелхак абыйны тыңлап утыру үзе бер рәхәт. Ул үзе белгән бөтен нәрсәне башкаларга бирергә тырыша, «тәмле» итеп сөйли, бөтен эшеңне оныттырып тыңлата белә. Ул чын халык укытучысы. Бәйрәм вакытларында аларга килгән хатлар һәм открыткалар мәктәпне тәмамлаучыларның үз укытучыларын яратуы, зур ихтирам итүе турында сөйли. Кемдә-кемдә, * ә Фәйзелхак абыйларда кунаклар еш була. Алар элеккеге укучылар гына түгел, шагыйрьләр дә, композиторлар да, галимнәр, администрация вәкилләре дә. Әйтергә кирәк, абый оста фотога төшерүче дә, шагыйрь дә әле. «Совет мәктәбе» журналында, республика һәм район газеталарында аның байтак кына шигырьләре басылып чыкты, берничәсенә көй дә язылды.

Тормыш иптәше Зәйтүнә апа сабыр, түзем холыклы, тиз аралашучан, кешеләргә һәрвакыт ачык хатын иде. Тәмле итеп бәлешләр пешерер иде, килеп керсәң бар булганын өстәлгә чыгарып, өстәл янына чакырыр, бер дә булмаса, чәй эчертеп булса да чыгарыр иде. Килеп кергән һәр кешегә: «И синең авызың бигрәк тә бәхетле инде, менә әле яңа мичтән бәлеш тартып чыгардым»,- дип утырмас җиреңнән өстәл артына утыртыр иде ул. Яшь чагында клуб сәхнәләрендә тормыш иптәше Фәйзелхак абый белән төрле спектакльләрдә, концертларда катнашыр иде. Ә инде мәктәп балаларына килсәң, алар үзләренең башлангыч сыйныф укытучысы

Зәйтүнә апалары янына каз бәбкәләре сыман сырылырлар иде. Әйе, Зәйтүнә апаның күңел җылысы күпләрне җылытты. Кызганыч, яман авыру аны арабыздан алып китте.

Фәйзелхак абыйга тормыш иптәшен югалткач, тагын бер зур кайгы килде - зур кызы фани дөньяны куйды. Тәскирә апа шулай ук үзенең туган җанлыклы, миһербанлы булуы, сабырлыгы, хезмәт яратуы, гадилеге белән хезмәттәшләре һәм авылдашлар арасында аерылып тора иде.

Дөрес, бу сыйфатлар Хөснетдиновлар балаларының барысына да хас сыйфатлар. Кәүсәр хәзерге көндә «Ижминводы» заводында эшли. Хезмәттәшләре аның ярдәмчел, ачык, тырыш булуын аеруча билгелиләр.Ә минем өчен ул дусларым арасында ин яраткан, чын күңелдән бирелгән якын дустым. Тормыш иптәше Сания белән алар башкалар өчен яшиләр дип әйтсәң дә ялгыш булмас. Аның гаиләсе дә нәкъ әтисенеке кебек дус, тату яши. Ике малае югары уку йорты студентлары, кызы мәктәптә яхшы билгеләренә генә укый. Зөһрә һәм Фәрит Менделевск һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә яшиләр, намуслы хезмәт башкаралар.

Фәйзелхак абый һәм Зәйтүнә апа белән Бәзәкә халкы горурлана. Аларның дәүләт биргән мактаулы исемнәре, билгеләре аз, ләкин авылдашлары һәм райондашлары аларга биргән бәяләр кыйммәтлерәк тә, дәрәҗәле дә.

**Нефтьчеләр җитәкчесе Вәлиәхмәт**

Ачык күңелле, гади характерлы кеше һәм хезмәт сөючән, акыллы җитәкче - шулай дип сөйлиләр Вәлиәхмәт Мөхәмәтдин улы Сираҗетдинов турында.

Вәлиәхмәт мәктәптә укыганда ук тырыш, эшчән, булдыклы, техника яратучы булып үскән. Тыңлаучан, мәрхәмәтле, игътибарлы, нечкә күңелле,' башлы егет, җәмәгать эшләрендә бик актив катнашучы иде, - дип искә алалар аны укытучылары. Үзешчән сәнгать смотрларында да Вәлиәхмәт гел катнашкан, район һәм авыл сәхнәләрендә оста җырчы булып танылган.

Мәктәпне уңышлы гына тәмамлаганнан соң, Вәлиәхмәт 1-нефть промыслена нефть табу буенча

оператор булып эшкә урнашкан. 1966 елның көзендә Совет Армиясе сафларына хезмәткә алынган. Армиядән соң яңадан нефтьчеләр сафына баскан, ләкин амплуасы башка инде - сусызландыру һәм тозсызландыру установкасы операторы булып эшли башлаган.Бу эш күп, тирән белемнәр сораганга күрә читтән торып Саратов политехникумын тәмамлаган.

Үзенә генә хас булган үзсүзлелек, тынгысызлык белән нинди эш кушсалар да, җиренә җиткереп башкарган Вәлиәхмәт. Ул тиз темплар белән һөнәр осталыгы баскычлары, буенча күтәрелгән. 1- ТХУны эш режимына кертүдә катнашкан, Алабуга товар паркын реконструкцияләүдә күп көч куйган, Кызыл Тауда УПСны эшләтә башлауны җитәкләгән.

8 ел нефть хәзерләү һәм суыртып куу установкасында (ППН) эшләгәннән соң Вәлиәхмәт механик, аннан соң өлкән инженер-технолог итеп билгеләнгән. 1978-1993 елларда цехның термохимик установкасының начальнигы булып эшләгән.

1993 елның 4 январенда идарә җитәкчелеге аны ППН начальнигы итеп билгеләгән һәм шул көннән бирле Вәлиәхмәт Сиражетдинов шушы зур вазыйфаны тырышып башкара. Ул җитәкләгән цех - НГДУда иң зур цех: эшчеләр саны буенча да,
объектлар саны буенча да, корылмалар һәм җиһазлар саны буенча да. ППН объектларында нәрсәләр генә юк: насос агрегатлары,
компрессорлар, газ белән эшли торган мичләр, тондыру җайланмалары, 200 километрдан артык труба уткәргечләре һ.б. Бу катлаулы хуҗалык җитәкчесе Вәлиәхмәт, 30 ел элек эшкә килгән егет сыйфатларын югалтмыйча, кешеләр белән идарә итә.

В.М.Сиражетдинов - хөкүмәт бүләкләре орденнар кавалеры, ВЛКСМ ҮК бүләкләре лауреаты, Җиңү байрагы янында фотога төшкән эшче, Бөтенсоюз һәм Бөтенрәсәй форумнары делегаты, Рәсәй Федерациясенең атказанган нефть промышленносте хезмәткәре.

Вәлиәхмәт Мөхәмәтдин улы - тату гаилә башлыгы. Тормыш иптәше Җәмилә Имай кызы, балалары Рунар

һәм Лилия әтиләре янында нефтьче булып эшлиләр. Барысы да югары белемле. Рунар инде өченче югары белем ала. Аларның инде үз гаиләләре дә бар. Алма агачтан ерак төшми, диләр. Чынлап та, Вәлиәхмәт абыйның да балалары, әти- әниләре кебек матур, тыныч, тату гаила тормышы белән яшиләр. Вәлиәхмәт абый, Җәмилә апа балаларын кечкенәдән тормыш сөючән, кешеләрне ихтирам итүче, хезмәт яратучы, туган җанлыклы итеп үстерделәр. Инде хәзер Сиражетдиновлар өч оныкларын тәрбияләүгә бөтен көчләрен куялар. Шул ук вакытта авылда яшәүче әниләрен, туганнарын да онытмыйча, аларга гел булышып торалар. Атна саен диярлек алар янында булалар.

Йомыш белән килгән кешене, кем гена булмасын, ашатмыйча-эчермичә, файдалы киңәшләр бирмичә, ярдәм кулын сузмыйча, чыгарып җибәрмиләр - чын кунак итеп җибәрәләр алар. Икесе . да яхшы, әчкерсез әңгәмәдәш, чын күңелдән хәл уртаклаша, сер саклый беләләр.

Вәлиәхмәт абый авылда тугангадыр инде, җиргә береккән кеше. Алабуганың матур җирендә коттедж җиткереп, Җәмилә апа белән бакчада төрле-төрле агачлар, яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәкләр үстерәләр, терлек карыйлар.

Вәлиәхмәт абый оста һәм матур итеп җырлаучы һәм биюче дә, моңга, шигъриятькә гашыйк кеше. Кулыннан нәрсә генә килми аның! Ул башкалар шикелле эштән кайткач, телевизор янында утырмый. Буш вакыты булдымы, нәрсәдер төзергә, җиткерергә, ясарга ябыша. «Хатын-кызның урыны өйдә, ир-атның урыны ишек алдында», - ди ул кайчагында.

Аның кул астында эшләүче бәзәкәлеләр Вәлиәхмәт Мөхәмәтдин улы белән горурланып бетә алмыйлар, аның турында «оста һәм игътибарлы җитәкче, сизгер һәм кеше хәлен тиз аңлаучан психолог, чын дус» дип сөйлиләр. Вәлиәхмәт авылны төзекләндерүгә дә өлеш керткән авылдашыбыз. Аның җитәкчелегендә авылның берничә чишмәсе һәм зират коймалары рәткә кертелде.

Әйе, Вәлиәхмәт Сиражетдинов - чын Бәзәкә баласы, аның тормышы һәм эшчәнлеге буенча авыл халкының нинди икәнлегенә характеристика биреп була. Авыл халкы синен белән горурлана, Вәлиәхмәт! (Сиражетдинов В.М. турындагы очеркта нефтьчеләргә багышланган китаплардагы аның турында язылган материаллар кулланылды).

### Атаклы хирург

Кеше ышанмаслык хәл: хирург бер операция вакытында хастаның, бик мөһим алты өгъзасын кисеп ала. Нәтиҗәдә ракның азган төре белән авырган сырхау исән кала. Алай гына да түгел, эшләү сәләтен дә югалтмый. А.га 49 яшь, Һөнәре буенча ул механизатор. Аны район хастаханәсенә ашказаныннан бик көчле кан килгән хәлдә китерәләр. Ашыгыч ярдәм курсәткәч, авыруны санитар самолет белән республика онкология үзәгенә алып киләләр.

Бер минут вакытны да сарыф итмичә, ул чагында әле Казан дәүләт медицина академиясенең хирургия һәм

онкология кафедрасы доценты Рифкәт Минһаҗ улы Таҗиев аңа операция ясарга керешә. Операция бик катлаулы була. Ашказаны, ашказаны асты бизенең шактый өлеше, талак, бавырның сул як өлеше, аркылы-кайма эчәк, бөер асты бизе кисеп алына. Бу көннән соң, инде 11 ел вакыт узган. А. җәй көннәрендә механизатор хезмәтен дәвам итә. Улемнән йолып калучысы янына да еш килә. РифкәтТаҗиев - бик тәвәккәл кешё. Башка хирурглар баш тарткан гаять катлаулы операцияләргә дә алына һәм уңышлы башкарып чыга. Мәсәлән, авыру К.ның операция вакытында упкәсенең бер өлешен кисеп ала Ьэм яңа уңәч ясап куя. Хирург Рифкәт Тажиев 32 ел эшләу дәверендә бик күп уникаль операцияләр ясый. Аларның бөтенесен санап китү дә мөмкин түгел.

Бәзәкә авылының ишле гаиләсендә дөньяга килә Рифкәт. 1943 елның 1 мае була бу. Бөтен илне сугыш афәте каплап алган чор. Рифкәтнең әтисе колхозда бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр төрле эшләр башкара. Төн уртасында гына өенә кайткан ата кеше, улы тууын белгәч, болай ди: «Көн бик кояшлы, җылы булды бүген. Малай, Алла боерса, зур кеше булыр».

Минһаҗ абый бик куп тапкырлар үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Тик моңа гражданнар сугышында алган җәрәхәт киртә була. Бөек Ватан сугышы тәмамланганда авылда ир заты бөтенләй диярлек сирәгәя һәм Минһаҗ абыйны колхоз рәисе итеп сайлыйлар.

Рифкәтнең әнисе Рөхима апа акыллы, нечкә күңелле, тырыш хатын була. Мохтаҗлык кичерсәләр дә, хуҗалыкны барлап, гаилә учагын сүндермичә саклый. Ул елларда ашау-эчү дә такы-токы була. Берәр касә сөт, бәрәңге боламыгы, кычыткан ашы эләгә. Көзен балалар кырда калган башак, кишер, борчак җыеп алып кайталар. Болары да ач карынга ярап куя. 1930 еллардагы һәм сугыш вакытындагы ачлык-ялангачлык Таҗиевларның 11 баласын аяктан ега һәм исән калган җидесенең дә өчесе сугыштан соң вафат була. Рәхимә апа сабыйларның'улемен бик авыр кичерә. 1968 елда 53 яшендә үзе'дә гүр иясе була. Минһаҗ абый авыр тормыш

юлы узып, 83 яшьтә үлә.

Рифкәт, урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт медицина институтына юл тота. Русча начар белгән авыл малае имтиханнарны татар телендә бирә. Институтта укыганда латин, рус телләрен, медицина фәннәрен яхшы узләштерә. Мединститутны тәмамлагач, аны Чувашстанның Яльчик районы узәк хастаханәсенә хирург итеп җибәрәләр.

«Ул көннәрне хәзер дә хәтерлим, - дип искә ала Рифкәт Минһаҗ улы. - Район хастаханәсендә эшли башлавымның өченче көнендә йөк машинасында бала тапкан бер хатынны китерделәр. Яңа туган нарасый фельдшер кулында, ә кендеге әле әнисеннән аерылмаган. Мин каушауданмы шунда, шоферны ачулана башладым: «Нишләп вакытында китереп җиткермәдең?» Ул да чая кеше булып чыкты, сүзсез калмады: «Сез нәрсә, мин бит педальгә бастым, аның корсагына !үгел». Бәхәсләшеп тору артык иде. Бөтен игътибарны ана белән балага юнәлттек. Тикшерә торгач, бәләкәчнең корсак өлешендә кимчелек ачыкланды: тире һәм мускул юклыгы беленде. Бавырын Ьэм эчәкләрне нечкә элпә генә каплап тора. Сабыйга катлаулы пластик операция ясадым. Өч елдан соң, Яльчиктан бөтенләй китәргә җыенып йөргән көннәрдә, кулына зур чәчәк бәйләме тоткан матур кызчык әнисе белән бергә миңа рәхмәт әйтергә килде».

Рифкәт Минһаҗ улы хастаханәдә эшли башлавының беренче көненнән үк медицина диагностикасын камилләштерергә һәм хирургиягә яңа алымнар кертергә омтыла. Озакламый хастаханәнең хирургия бүлеге мөдире эштән китеп бара һәм Рифкәт аның урынында кала. Ул көнне төнгә ялгап эшли: вакытында

йоклау, туклану

онытыла. Тәүлек буе хастаханәдән чыкмаган вакытлары да еш була. Операция өстенә операция: ясап кына өлгер. Яшь табибның абруе көннән-көн усә. Тагын бер елдан хастаханәнең баш табибы да эштән китә. Рифкәт Таҗиевка ике ел буена баш табиб һәм хирург вазифасын башкарырга туры килә. Районда эшләү срогы

тәмамланыр алдыннан ул ГИДУВта онкология һәм хирургия буенча белемен күтәрә. Шунда галим, танылган хирург, профессор Михаил Семенович Сигал белән очрашу аның киләчәк язмышын хәл итә дә куя.

Яльчикта өч ел эшләгәннән соң, Рифкәт Таҗиев профессор Сигал клиникасында ике ел ординатура утә һәм аны республика онкология диспансерының хирургия бүлеге мөдире итеп билгелилар. Монда да табибны яңа мәшәкатьләр көтеп тора: бүлектә ремонт эшләре бара. Стена-түшәмне акшарларга, идәнгә линолеум җәяргә, булмәләрне аппаратлар һәм җиһазлар белән тәзмин итәргә, кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Ул елларда биредә оста хирурглар Н.Поляков, Х.Кәримов, анестезиолог А.Подольский эшли. Яшь белгеч алардан корсак өлешендәге, аннары кукрәктәге яман шеш авыруларына ясалган операция алымнарын өйрәнә. Эшкә хирыслыгын күреп, аны 1980 елда клиника ассистенты итеп билгелиләр. Бу елларда ул бик мөһим темага диссертация яза һәм 1983 елда «Спленопанкреатогастэктомия в хирургии рака желудка» темасына кандидатлык диссертациясен яклый. 1985 елда Рифкәт Минһаҗ улы доцент итеп сайлана, ә 1990 елда профессор Сигалның вакытсыз

үлеменнән соң хирургия һәм онкология кафедрасы мөдире итеп билгеләнә.

1997 елда ул Мәскәүдә «Одномоментальные операции в хирургическом лечении рака пищевода и кардиоэзофагеальной области» темасына докторлык диссертациясен яклады. 1998 елда исә аңа Югары аттестация комиссиясе профессор дәрәҗәсен бирде.

Мөгаен, онкология өлкәсендә ул ясамаган операцияләр юктыр. Ә бит кешенең организмына карап һәр операция үзенчәлекле, бер-берсен кабатламый. Көтмәгәндә төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Мондый вакытта хирургның осталыгы, югалып калмавы сорала.

Катлаулы операцияләрдән соң, профессор аудиториягә лекция укырга ашыга. Аның дәресләренә яшь дәвалаучылар гына түгел, Казанның һәм Рәсәйнең төрле төбәкләреннән табиблар җыйнала. Монда инде ул онкология өлкәсен тирән белүче галим буларак ачыла.

Рифкәт Минһаҗ улы белән ни хакында гына әңгәмә корсаң да, аның үз эшенә булган мәхәббәте гәүдәләнә.

Күп гасырлардан бирле мондый гыйбарә йөри: «Кеше кешегә - бүре». Ләкин Санкт-Петербургның фән һәм сәнгать академиясе әгъза-корреспонденты, профессор, Татарстан Республикасының атказанган табибы, 70-тән артык фәнни эшләр авторы, Республиканың сәламәтлек саклау Министрлыгы каршындагы Клиника-онкология Үзәгенең дәвалау- диагностика бүлеге җитәкчесе Рифкать Минһаҗ улы Таҗиев турында сүз барганда, бу гыйбарәне бераз узгәртеп, болай диясе килә: «Кеше кешегә - кеше!»

Рифкәт Минһаҗ улы Таҗиев «Татар энциклопедия сүзлегенә» кертелде (Татарский энциклопедический словарь, Казань, 1999, с. 554).

(Медицина фәннәре докторы, профессор Михаил Розенгартенның «Ватаным Татарстан» газетасында 1999 елның 1 маенда бастырылган мәкаләсе файдаланылды).

## Бертуган Мәскәү галимнәре

Сүз Мансура һәм Мансур Әхмәтовлар турында бара. Алар икесе дә Габдулла абый һәм Рәхимә апа балалары.

Рәхимә апа тормыш иптәшен сугыш кырларында югалтып, авыр шартларда ике газиз баласын тәрбияләде, икесенә дә югары белем алырга шартлар тудырды. Игелекле, түзем, сабыр холыклы ана, чибәр ханым иде ул Рәхимә апа.

Мансура Әхмәтова Бәзәкә мәктәбен тәмамлаганнан соң, Алабуга укытучылар институтына укырга керә һәм анда рус теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеген алып чыга. Туп-туры Бәзәкә мәктәбенә эшкә кайта һәм берничә елдан методик яктан оста педагогка әйләнә. Ул күп вакытын педагогик әдәбият өйрәнүгә багышлый, укучыларда рус теленә мәхәббәт тәрбияләүдә күп игътибар бирә. Ул укыткан күп кенә бәзәкәлеләр институт бетереп, рус теле укытучысы белгечлеген алалар.

Мансура апа -минем рус теле укытучым һәм 6 ел буе сыйныф җитәкчем булды. Сыйныф коллективын туплауда һәм тәрбияләүдә төрле һәм яңа алымнар куллана иде ул. Дөресләрне ул кызыклы итеп үткәрә, дәресләрдә сәләтле укучыларны махсус институтка керүгә хәзерләүгә әһәмият бирә иде. Безнең сыйныфта анын җитәкчелендә бию ансамблебез оешты, ул безне эстетик яктан тәрбияләүгә зур игътибар бирде. Ул оештырган урман, күлләр буена сәяхәтләр, кичләрен учак буенда кызыклы әңгәмәләр, Казан, Алабуга шәһәрләренә экскурсиягә барулар, төрле кичәләр, бәйрәмнәр, очрашулар безнең күңелләрдә искиткеч тәэсирләр калдырды. Үзе укытучы һәм кеше буларак, бөтен яктан үрнәк булып яшәде. Озын чәч толымлы, төз буйлы, чибәр,
матур итеп биюче һәм җырлаучы Мансура апа өле хәзердә исемдә. Ул урамнан үтеп киткәндә авыл халкы аның буй-кыяфәтенә сокланып карап кала торган иде. Аның белән бәрәңге басуында эшләгәндә бәрәңгене тиз, балалар әйтмешли, «автомат» сыман җыюына безнең ис китәр иде. Эшчән, җитез, хәрәкәтчән иде безнең укытучы апабыз. /

Әйткәнемчә, Мансура апа педагогика, методика фәннәре белән нык кызыксына иде, шуңа күрә 1974 елда

ул Мәскәү каласына китеп анда милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институты каршындагы аспирантурага укырга керде. Аны уңышлы гына тәмамлап, татар мәктәпләрендә рус телен укыту проблемасына багышланган кандидатлык диссертациясе яклады. Аны институт хезмәткәрләре уку чорында бик яраттылар һәм аны үз яннарында эшкә алып калдылар. Мансура апа соңгы елларда шул институтта өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләде.

Аның энесе Мансур абый шулай ук Мәскәүдә техник фәннәр буенча югары белем алып, шунда ук аспирантура тәмамлады. Электроника буенча кандидатлык диссертациясе яклады. Яшьләр бик ярата торган төсле музыка аның катнашында барлыкка килде. Мансур* абый апасы кебек үк күп фәнни эшләр авторы. Кыаганычка каршы атом радиациясенә эләгеп, күп тә тормыйча һәлак булды.

Мансур абыйның дус һәм тату гаиләсендә миңа күп булырга туры килде. Иптәше Роза апа белән бик тату тордылар. Мансур абыйның көн саен тормыш иптәше янына чәчәк букеты белән кайтуы әле хәзердә күз алдымда. Аларның бер-берсен яратуы, ихтирам итүе хәзерге заман кешеләренә хас та түгел, алар икесе дә чибәр, күркәм, мөләем, бер- берсенә игътибарлы кешеләр Айдар исемле улларын зур кеше итүгә күп көч куйдылар. Роза апа балерина хезмәтен ташлап, улына вакытны кубрәк сарыф итәр өчен, икенче эшкә кучте. Айдар мәктәптән соң Мәскәү хореография училищесын тәмамлады. Хәзерге вакытта Мәскәү классик балетының күренекле солисты. Һәрвакыт репетицияләрдә, гастрольләрдә Айдар, аны өйдә туры китерү бик кыен. Айдар Казанда Муса Җәлил опера һәм балет театрында куелган зур гына балет спектакльләрендә катнашты.

Бәхетсезлек үзе генә йөрми диләр, Мансур абьй вафат булганнан соң, Мансура апа да бу дөньядан китеп барды. Иң авыры Рәхимә әбигә төште. Кадерләп үстергән ике кошчыгын үзенә җирләргә туры килде аңа. Шул хәсрәттән озак та тормады, үзе дә вафат булды.

Ходай әйбәт кешеләрне җирдә озак яшәтми, үз янына

ала, дип сөйлиләр. Чынлап та дөрестер бу сүзләр. Әхмәтовлар барысы да кешеләргә миһербанлы, шәфкатьле булдылар, авыр чорлар булуга да карамастан тыныч тормыш кичерделәр. Шуңа күрә аларны авыл халкы да олылап искә ала...

### Академик Мансур

Мансур Кәрим улы Нәбиуллин - Себердә яшәүче Бәзәкә егете, физика-математика фәннәре докторы, профессор, академик.

Мансур мәктәп елларын әле хәзер дә ачык хәтерли. Көчле укытучылар кулы астында укыган егет математика һәм физика дәресләрен бик ярата. Математика буенча үткәрелгән кичәләрдә, олимпиадаларда Мансур Бәзәкәдә генә түгел, район буенча да беренче урыннарга лаек булган укучы. Аның өстенә -комсомол комитеты активисты. Марсель Гыймазетдинов белән начар укучыларны, тәртип бозучыларны тиз «урыннарына» утыртырлар иде алар. Мансур Бәзәкә мәктәбен көмеш медаль белән тәмамлаучы беренче укучы.

Мәктәпне шулай уңышлы гына тәмамлаганнан сон, Мансур Нәбиуллин Казан авиация институтына укырга керә. Аны тәмамлагач, шунда ук теоретик механика кафедрасы каршында аспирантура бетереп кандидатлык диссертациясе яклый. Язмыш аны Новосибирскидагы Академиклар шәһәрчегенә эшкә китерә. Соңгы елларда Иркутск шәһәрендә яши.

1995 елда «Моделирование и исследование устойчивости стационарных движений орбитальных упругих систем» темасына докторлык диссертациясе яклады.Космик орбиталь системалар өлкәсендә модельләштерүнең яна ысулларын уйлап тапканы өчен академик М.В.Келдыш медале белән бүләкләнде.

Мансур Кәрим улы - 60-тан артык фәнни хезмәт авторы. Зур фәнни эше « Стационарные движения и устойчивость упругих спутников» (М.,Наука, 1990) дип атала. АКШта ике мәртәбә «51аһопагу тойопз апб з1аЫП1у оТ hexМе за1е11Кез» исеме астында бастырылды.

Набиуллин М.К. 1994 елдан Иркутск дәүләт университетының практик механика кафедрасы мөдире, Рәсәй Фәннәр Академиясе Себер бүлеге Системалар динамикасы һәм идарә итү институтының баш фәнни хезмәткәре. Соңгы вакытта Мансур Кәрим улы Спейс-Шатл ише космик орбиталь системалар динамикасы .проблемалары өстендә эшли. Күптән түгел Халыкара симпозиумда бу сораулар буенча зур чыгыш ясап кайтты...

**Мәхмүтовлар династиясе**

Бәзәкәдә Мәхмүт исемле бер фәкыйрь генә крестьян яшәгән. Хатыны Шәмсекамал белән 9 бала табып үстергәннәр. Шуларның 5 се генә исән калган..

Хаҗиәхмәт исемле малайлары Нуриәхмәт абыйсы белән Таҗетдин муллага сабак укырга йөргән.

Мәхмүт сатучылардан күн сатып алып Гыйльми тегүчедән сандалый, читек тектереп авылда сату оештырган. Шулай әкрен генә сату эшенә кереп киткән. Тик үпкә авыру сәбәпле Хаҗиәхмәткә 19 яшь тулганда Мәхмүт вафат булган. Шәмсекамал 4 бала белән калган, алар белән бергә эшләп үз тамакларын үзләре туйдырганнар. Гражданнар сугышында Мәхмүтовлар фронтка киткәннәр. Тән җәрәхәтләре алып авылга кайткач, күп тә үтмичә Нуриәхмәт белән Хаҗиәхмәт өйләнгәннәр. Аталары васыять итеп калдырган була: «Әниегезне карагыз!» дип. Төп йортта Хаҗиәхмәт калган. Беренче хатыны Гаффә белән 3 бала тапканнар. 1923 елда Сәетшәриф, 1924 елда Нажия, 1928 елда Рәмзия туганнар. 30-нчы елларда ул укытучы Оркыя Вәлиәхмәтовага өйләнгән.

Хаҗиәхмәт - колхозга керүчеләрнең берсе. Наҗия апа искә ала: «Әти бер йөк ашлык төяп, безне арба артына утыртып, колхозга төшеп китте. Атны, арбаны, сбруйны, ашлыкны калдырып җәяү өйгә кайттык. Кичен карасак, безнең атыбыз качып кире кайткан. Яңгырлы көн иде. Шуңа да карамастан әти атны кире төшереп бирде.

Сәетшәриф абыйны әти почтальон итеп урнаштырды. Ул елларны гәҗит алдыручылар күп иде. Абый арып-

талып, кайбер көннәрне таратып та өлгермәс иде. Без аңа булыша идек».



Икенче хатыны Оркыя Хаҗиәхмәткә тагын өч кыз бала тапкан: 1937 елда Альта, 1940 елда Алиса, 1949 елда Әнисә туган.

Сугыш башлану белән Хаҗиәхмәт фронтка киткән. Башта окоп казу, урман кисү лагерында хезмәт иткән, аннан соң сугыш кырына кергән. 1946 елның язында авыру хәлдә өйгә кайткан, байтак вакыт шифаханәдә дәваланган. Рәтләнгәч, авыл советы секретаре һәм соңрак райфо системасында налог җыю инспекторы булып эшләгән. 1980 елда вафат булган.

Улы Сәетшәриф Бәзәкәдә алты сыйныф тәмамлагач, рус телен яхшырак үзләштерү нияте белән күрше Бондюгка барып, квартирада торып татар мәктәбендә укыган. Аны бетергәч, Алабуга педагогия училищесында укыган. Студент елларында аны комсомол секретаре итеп сайлаганнар. Аны оста гармунчы булганы өчен дә яратканнар.

1941 елның 17 июнендә училищены тәмамлагач, ял итү нияте белән Березникига кунакка киткән. С'угыш башлангач, повестка килгән. Сәетшәриф кунакта булган җиреннән тиз генә кайтып фронтка киткән. Башта Әгерҗедә хәзерлек курсларында укыган. Аннан соң ул Сталинград юнәлешендә барган сугышларда командир булып катнашкан. Ул сугышларда лейтенант дәрәҗәсе алган. Аннан соң ул Ленинград юнәлешенә җибәрелгән. Сугышны Саетшәриф шунда тәмамлаган һәм хәрби частьнең штаб начальнигы булып хәрби хезмәттә калган. Хәзерге көндә ул подполковник дәрәҗәсендә. Ике улы да полковник.

Сеңлесе Наҗия 10 сыйныф белем алгач, авыл китапханәсендә эшләгән. Мәктәптә пионервожатые булган, шул ук вакытта рәсем, җыр дәресләре алып барган. Алга таба методикалар буенча имтихан тотып, башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләгән. Читтән торып Алабуга педагогия институтын тәмамлаган. Шуннан сон инде мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлаган. Наҗия апаның дәресләре башка укытучылар өчен үрнәк булып торган. Сыйныф җитәкчесе буларак та ул башка педагоглар өчен күп кенә методик күрсәтмәләр эшләгән, ачык чаралар үткәргән. 1965 елда Наҗия Мәхмутовага «РСФСРнын мәгариф отличнигы» дигән мактаулы исем бирелгән. 1969 елда ул «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән исемгә лаек булган.

Наҗия апа укыту эшләре белән генә чикләнмәгән, колхозның пропаганда-агитация эшләрендә актив катнашкан. Ул колхознын регуляр чыгып килгән стена газетасы редакторы, агитатор булып эшләгән.

Ике улы да югары белем алган. Камиль КХТИны

тәмамлап, Яшел Үзән шәһәрендә Серго заводында эшләде. Соңгы елларда Татарстанның сату һәм федераль органнар белән экономик хезмәттәшлек итү министрлыгының экспортны һәм федераль органнар белән хезмәттәшлек бүлегенең начальнигы булып эшләгән. Менә бер ел инде ул АЛАЗның тышкы элемтәләр Департаменты директоры урынбасары.

Кече улы Фәрит АДПИны тәмамлап, Бәзәкә урта мәктәбендә рус теле укытучысы, аннан соң Яр Чаллы шәһәрендә профсоюз җитәкчесе булып эшләде. Тик яшьли килеш без аны үз арабыздан югалттык.

Наҗия апаның сеңлесе Рәмзия Березники шәһәрендә сода заводында аппаратчы булып эшли. Алиса шулай ук Казан заводларының берсенда эшли. Алар икесе да югары белемле белгечләр.

Альта абыйсы үрнәгендә Бондюгта җиденче сыйныфны тәмамлагач, Алабуга педагогия училищесында укыган. Министрлык бүлүе буенча ул эшкә Казанга җибәрелгән. Анда башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләгән. Соңрак Казан дәүләт университетына укырга кергән. Шунда ук аспирантурада калган. «Татарлар арасында хатын- кызларның белемен күтәрү өчен көрәш (Х1Х гасырның 90-нчы еллары - 1917-нче ел)» дигән темага тарих фәннәре буенча кандидатлык диссертациясе яклаган. Хәзерге вакытта ул КДУ доценты, докторлык диссертациясе өстендә эшли.

Төпчек кыз Әнисә - белгечлеге буенча югары белемле рус теле укытучысы, Алабуганың бишенче урта мәктәбенең алдынгы укытучы-методисты, оста биюче һәм җырчы. Газизова Рәзилә, Таҗиев Сәләхетдин белән бергәләп Алабугада яшәүче авылдашларын туплап Бәзәкәдә, күрше шәһәрләрдә хәйрия концерты оештыручы.

Әйе, язсаң Мәхмүтовлар турында күп нәрсә язырга була. Аларның гаилә әгъзалары - кайда гына яшәмәсеннәр һәм эшләмәсеннәр, әтиләре үрнәгендә белемгә омтылучылар, башкаларны актив эшкә әйдәп йөрүчеләр, армыйча-талмыйча үз халкына хезмәт итүчеләр.
( Бу очеркны язганда Н.Х. Мәхмүтова истәлекләре кулланылды).

**Нәҗметдиновлар гаиләсе**

Алабуга үзәк район шифаханәсе буйлап төз һәм тиз атлап үтүче Сәетнурга карыйсың да, сокланып: «Каян килә икән бу кешегә энергия, көч, дәрт?» -дип уйлап куясың. Ул әле генә табиблар киңәшмәсен уздырган, ә хәзер инде авыручыларга консультация бирергә ашыга, ярты сәгатьтән аны Елаз медицина- санитария бүлегендә конференциядә көтәләр, сәгать ярымнан баш табиб янында булырга кирәк, баш шәфкать туташы белән медикаментлар турында сөйләшәсе бар, ә күпме документ тутырасы?! Кичен, арып-талып өйгә кайткач, уллары белән шөгыльләнәсе бар. Дөрес, балаларны тәрбияләүне үз өстенә тормыш иптәше Мөнирә алды, тик шулай да Сәетнур «егетләр» белән ирләрчә сөйләшеп алырга вакыт табарга тырыша.

Сәетнур Сәләхетдин улы Нәҗметдинов Бәзәкә мәктәбендә урта белем алды. Укыганда ук үзен тырыш, актив итеп күрсәтте, пионер һәм комсомол эшләренең инициаторы булды, соңгы уку елларында комсомол оешмасы секретаре Вазыйфаларын башкарды.

Мәктәпне уңышлы тәмамлап Казан медицина институтына укырга керде. Уку чорында алган мактау кәгазьләре аның тырыш, омтылучан студент булганы турында сөйлиләр. Табиб һөнәре күп белемнәр, күнекмәләр, сизгерлек, зур такт сорый. Шуңа курә

студент елларында ук Сәетнур үз өстендә эшләүне максат итеп куйды. Кайчан аның янына килеп кермә, китаплар, конспектлар белән өелгән өстәл артында утырыр иде ул!

Институт бетергәч, С.С.Нәҗметдинов Алабугага эшкә җибәрелде. 3 ел Алабуга медицина училищесында укытты, аннан соң район шифаханәсе поликлиникасында эшли башлады. Беренче эш көненнән үк үзен оста белгеч итеп (бигрәк тә терапия өлкәсендә) күрсәтте. Күп та тормыйча, Казанда ординатура бетерде. Ординатурадан соң поликлиникага кайтып экспертиза буенча баш табибның урынбасары, соңга таба поликлиника җитәкчесе булып эшләде. 1994 елда Елазда медицина-санитария бүлеге ачылгач, аны җитәкчелек баш врачның дәвалау эшләре буенча урынбасары итеп куйды. Шулай ук бу коллективта да Сәетнур тиз арада ихтирам казанды. Ул җәйге ялга яисә командировкага китсә, хезмәттәшләре «рәт бетте»,- дип әйтәләр иде. Чөнки ул бөтен сорауларны да чишә, төрле ситуацияләрдән чыгу юлларын оста таба, үз өстенә зур җаваплылык ала торган җитәкче һәм белгеч.

Менә бер ел инде Сәетнур Сәләхетдин улы Алабуга территориаль-медицина берләшмәсе баш врачының урынбасары булып эшли. Ул Татарстанның атказанган табибы.

Сәетнурның мондый уңышларга ирешүендә тормыш иптәше Мөнирә Әхмәтзәки кызының да зур өлеше бар дисәк ялгыш булмас. Сәетнурның әтисен кадерләп фани дөньядан озатты. Сәләхетдин абый тик кенә аңа «кызым» дип эндәшмәгәндер. Сәетнур Казанда укыганда яисә көннәр буе эштә югалган чакларында гаилә учагын саклаучы, балаларны башлы-кузле итәм дип тырышучы шулай ук Мөнирә. Тормыш иптәшенең апалары да Мөнирәне үз туганнары кебек яраталар.

Мөнирә сабыр, түзем булса да бик тәвәккәл, җитез хатын. Бер эшне башласа, ә дигәнче эшләп тә куя. Әнисе Нәгыймәгә охшаган ул. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Алабуга педагогия институтының чит телләр факультетына укырга керде. Аннан башка немец беле

буенча укыган бәзәкәлеләрне башка хәтерли да алмыйм. Мәктәптә укыганда даг студент елларында да Мөнирә сәхнәдән төшмәде, аерым хәм коллектив биюләрдә катнашты, фәнни түгәрәккә йөреп берничә мәртәбә студентларның фәнни конференцияләрендә чыгыш ясады, комсомол комитеты һәм пионер кафедрасы эшчәнлегендә актив катнашты. 1979 елда институтны тәмамлагач, Алабуга ВЛКСМ шәһәр комитеты аңа комсомол эше такъдим итте. Ул 7 номерлы төзү-монтаж трестының, аннан сон 69 номерлы профессиональ училищесының комсомол оешмасы секретаре булып эшләде. 1984 елдан Алабуга педагогия институтының педагогика кафедрасында эшли башлады. 1990 елда Казан дәүләт педагогия университетының аспирантурасына кереп, 1994 елда «Укытуны индивидуальләштерү һәм дифференцияләштерү шартларында укучыларның эшчәнлеге белән идарә итү» темасына кандидатлык диссертациясе яклады. Халык педагогикасы, булачак укытучыларны мәктәптә укыту-тәрбия процессына хәзерләү проблемаларына" багышланган мәкаләләре, студентлар өчен методик кулланмалары басылып чыкты.

М.З.Нәҗметдинова - 1996 елдан бирле чит телләр кафедрасы мөдире. 2000 елда доцент гыйльми исемен алды. Коллегалары һәм шәкертләре аны принципиальле, эше өчен җаваплы, һәрвакыт ярдәмчел, үз-үзенә таләпчән педагог дип атыйлар.

Нәҗметдиновларның ике уллары үсә. Зурысы Ильнар Чаллы педагогия институтының художество- графика факультетының 3 курсын тәмамлады.
Кечесе Ренат 1 Алабуга урта мәктәбенең 8 сыйныфында уку отличнигы.

Әйе, Сәетнур һәм Мөнирә кебек авылдашларыбыз булганда без бит бәзәкәлеләр дип горурланырга була. Ходаем исәнлек, саулык, тазалык, иминлек бирсен аларга!

### Шигърияткә, җырга гашыйк ул

Авылымда искиткеч гүзәл кешеләр яши. Шуларның

берсе шагыйрә Фәния Шакирова. Фәния апа Шакирова бөтен җиһан аклыкка күмелгән. мәлдә, февраль бураннары җир ананы карлы юрганнарга төргәндә дөньяга килгән. Сугыш башланганда кечкенә Фәниягә нибарысы ике яшь була. «Минем балачак булмады», - ди ул. Әтисен да фотографиядән гена карап белә. Шуңадырмы, әтисен сагыну хисе аны хәзер дә калдырмый. Бу хис аның шигырьләрендә ачык чагыла. Фәниянең әтисе сугыш кырларында ятып кала..

Сугыштан соңгы еллар исә бигрәк та авыр була. «Ул чорлар басуда үтте дисәм дә дөрес булыр», - дип искә төшерә Фәния апа. - «Алабута, өшегән бәрәңге җыю - берсе дә калмады. Әле дә ярый әнием шәл бәйли иде, ул һөнәрне мин дә үзләштердем. Шәл саткан акчага туй бирнәләрен җыйдым».

Тормыш иптәше Әхмәтгәрәйне ул хат ташучы булып эшләгәндә очрата. «Солдаттан бигрәк чибәр егет кайткан, кем бәхетенә булыр икән?»- дип уйлый. Ә егет исә шул кичтә үк Фәнияне озата кайта. Туйларын да алар җигүле атлар белән урам әйләнеп, бик күңелле итеп уздыралар. Тормышларын ямьләп өч балалары - Әлфия, Фәрит, ГӨлфия дөньяга килә.

Ә Фәния апаның күңеле нигәдер һаман шигъриятkә, моңга тартыла. Беренче шигырен ул кече кызы Гөлфия тугач иҗат итә. Туган авылы Бәзәкәгә багышланган әлеге шигыре дөнья күргәнгә дө инде 35 ел гомер үткән. Шул вакыт эчендә Фәния апа Шакирова зур югалтулар кичерде. Әнисе, тормыш иптәше Әхмәтгәрәй инде фани дөнья белән саубуллашканнар. Шагыйрәнең исә бу вакыт эчендә йөзләгән шигырләре иҗат ителгән, үзе дә инде бүлеп җиденче дистәне ваклаучы чәчләренә чал кергән мөлаем бер ханым.

Шулай булуга да карамастан, йөрәге яшь әле аның. Ул һаман шигырьләр иҗат итә, һаман эзләнүдә. «Очар кошым» җыентыгы - моның ачык дәлиле. Соңгы вакытта язган шигырьләре дә тагын бер китаплык булган. Әле алай гына да түгел, Фәния апа бик матур итеп җырлый да, пешеренергә дә бик ярата. Кайгыртучан ана, алты оныгына үрнәк әби дә ул.

Фөния апаның күңеле тулы шигърият һәм моң. Әнә шул шигъри күңеле аңа яшәргә коч бирә. Йөрәгендәге хисләре шигырьләренә көчә бара:

Гомер узды, картаелды, диләр,
Ә мин әле һаман ашыкмыйм.
Олыгайсам да күңелем яшь сыман,
Шигърияткә, моңга гашыйкмын.

(Фәния апа Шакирова турында очерк Р.Мирзаянова мәкаләсенә нигезләнеп язылды)

**Балаларның якын дусты**

«Балаларның якын дусты» - шулай дип атыйлар Алабуга шәһәрендә һәм якын-тирә шәһәр-районнарда Алабуга педагогия институты доценты, педагогия фәннәре кандидаты Сәләхетдин Таҗиевны.

Үзең фән кандидаты син,
Вузда яшьләр остазы.
Үзең наян, үзең шаян,
Үзең бию остасы.
Тормышта син һәр яктан да
Уңган кеше, кыскасы, - дип аңа шагыйрь

Мәхмүт Хөсәен шигырен багышлады.

Сәләхетдин Фәрдетдин агай гаиләсендә төпчек малай булып дөньяга килгән. Әтисе күп еллар колхозда рәис, агротехник, аннаң соң яшелчә бригадасы бригадиры булып эшләгән, авыл советы һөм җәмәгатьчелек эшләрендә актив катнашкан. Әнисе Газизәбану сабыр холыклы, киң һәм ачык күңелле, гадилеге, ә гаилә, гомумән, тәртиплелеге, тырышлыгы һәм хезмәт сөючәнлеге белән күрше- тирәдә аерылып торган. Күп вакытын балалары Галиябану, Рабига, Гәйфетдин һәм Сәләхетдинне тәрбияләүгә, аларны тормыш итәргә өйрәтүгә багышлаган. Галиябану Чиләбе өлкәсенең Копейск шәһәрендә шәфкать туташы булып эшләгән, хәзер лаеклы ялда. Рабига Белоус поселогында алдынгы урман эшчесе булган, шулай ук лаеклы ялда. Гәйфетдин Волгоград өлкәсендә яши һәм тракторчы булып эшли.

Героебыз кечкенәдән күрше-тирә малай-кызларны җыеп, төрле уеннар оештырып, курчак театрлары куеп, бергәләп җиләккә, балыкка, Пинәрә күленә су керергә йөреп үсте.

Мәктәптә укыган вакытларын сагынып сөйли Сәләхетдин: «Әле хәзер дә исемдә иң беренче мәктәпкә баруым - ул көнне мин нык дулкынланып искә алам. Гәйфетдин абыемны да укыткан беренче укытучым Гөлсем апа Гайнуллина вакытын, көчен җәлләмичә безне укырга, язарга өйрәтте. Беренче биергә өйрәтүче Әдия апа Ибраева иде. Октябрятка кабул итүче дә ул. Исемдә: үзебез каты кәгазьдән йолдызчык кисеп, аны кызыл материал белән әйләндереп, йолдызчык ясадык. Булавка белән пиджакка тагып йөри идек. Бу ике олугъ шәхес тормышымда, киләчәк һөнәремне сайлап алуда беренче тәэсир ясаган кешеләр булдылар. Аннан соң 5-нче сыйныфтан башлап безнең җитәкчебез Мансура апа Әхмәтова булды. Рус теленә, педагог профессиясенә мәхәббәт тәрбияләүче - әлбәттә, Мансура апа.»

Мәктәп елларында Сәләхетдин җәмәгать эшләрендә актив катнашкан укучыларның берсе. Сыйныф старостасы, отряд советы рәисе, дружина советы рәисе, мәктәп комсомол оешмасы секретаре, сәхнәдә сүз һәм бию остасы булган.

1969 елда мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан соң Алабуга педагогия институтының филология факультетына укырга кергән. Студент еллары - Сәләхетдин тормышында шулай ук зур активлык һәм тырышлык еллары. Институтның комсомол комитеты әгъзасы, биш ел буе группа старостасы, үзешчән сәнгать смотрларында, драма театры спектакльләрендә катнашучы, студентлар оештырган пионер кафедрасы мөдире урынбасары, ял көннәрендә атна саен туган авылына кайтып балалар өчен Ял көне Клубы оештыручы, авыл яшьләре ялын оештыруда актив катнашучы булган. 1 курстан ук фәнни эш белән кызыксынган, инде икенче курста ясаган фәнни докладлы 1 урынны алган. 3 курста Башкорт дәүләт педагогия институтында фәнни конференциядә катнашкан. 4 курста

укыганда Казан телевидениесе буенча чыгыш ясаган.

Институтны яхшы билгеләренә генә тәмамлап. Сәләхетдин 1974 елда туган мәктәбенә директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары булып эшкә кайткан. Ул эшләгән дәвердә мәктәптә туган якны өйрәнүчеләр клубы төзелгән, пионер һәм комсомол эшенең яңа эш формалары кулланыла башлаган. 40 укучы катнашында Фәрит Яруллин музыкасына «Шүрәле» хореографик сюитасы сәхнәгә куелган.

Тик ике елдан аңа Бәзәкә мәктәбеннән китәргә туры килгән: аны район яшьләре Алабуга ВЛКСМ шәһәр комитетының идеология эшләре буенча секретарь итеп сайлап куйганнар. Аннан соң педагогия институтының педагогика кафедрасында эшли башлаган. Мәктәпне ташламаган, Алабуга мәктәпләрендә, республика күләмендә балалар белән төрле чаралар үткәрүдә актив катнашкан. Республика пионер оешмасы Советы әгъзасы булып эшләгән, пионер оешмасы урынында Татарстан варислары оешмасы төзелгәч, ул оешмага аның рәисе В.Дергуновтан соң икенче булып Сәләхетдин кергән.

1980-1983 елларда Сәләхетдин Казан дәүләт педагогия институты аспирантурасында укып, 1983 елның декабрендә «Булачак укытучыларны авыл шартларында пионерлар белән идеологик эшкә хәзерләү» темасына кандидатлык диссертациясе яклаган. Казанда укыганда пионер эше буенча лекцияләр һәм семинарлар алып барган. Казанның Горький исемендәге ял паркында ул үткәргән инструктив-методик лагерьларны КДПИ укытучылары һәм студентлары әле хәзер дә сагынып искә алалар. Аспирантураны бетергәч, аңа Казанда калырга тәкъдим ясыйлар, ләкин ул туган якларына кайткан.

Хәзерге вакытта АДПИның педагогика кафедрасында доцент булып эшли. Утыздан артык фәнни эшләр авторы. Алар барысы да тәрбия проблемаларына багышланган. Фәнни эшләре арасында зур күләмле китаплар да бар. Сәләхетдин Таҗиев Татарстанда балалар оешмалары эшчәнлеген һәм балаларның җәйге ялын оештыру буенча зур гыйлем иясе булып санала. Ул

коллегалары әйтмешли башкалар алып бармастай зур курсларны алып бара: «Педагогик теорияләр, системалар , технологияләр», «Тәрбия эшләре технологиясе», «Социаль педагогның эшчәнлеге методикасы һәм технологиясе», «Интеграль педагогика», үзе уйлап тапкан махсус курслар. Алабуга шәһәрендә җәмәгатьчелек нигезендә 10 еллап үзе оештырган «Сәфәр» балалар оешмасы җитәкчесе булып эшләде. Җәй айларында КАМАЗның «Салават күпере» балаларны сәламәтләндерү комплексы директоры урынбасары булып эксперименталь эшләр үткәрде. Сәләхетдин - күп кенә күрше-тирә балалар оешмаларының һәм ял лагерьларының эш программалары авторы. Мәсәлән, ул «Өмет утравы» лагерын төзу идеясе һәм аның эшчәнлек программасы иясе. Бу лагерь 1999 елда Татарстан һәм Россия балаларның ял итү лагерьлары программалары конкурсында беренче урынга лаек булды.

Аны балалар һәм аларның әти-әниләре генә түгел, ә шәкертләре - АДПИ студентлары да яраталар. Алар:

«Сәләхетдин Фәрдиевичнең лекцияләре,

дәресләре кызыклы да, тирөнтен фәнни дә үтә, дәреснең үткәнен сизми дә каласың, дәрес беткәч, ял итеп чыккандай хис итәбез узебезне,» - дип өйлиләр. Кафедра мөдире сүзләренә караганда, ул тәрбия эшләре методикалары һәм технологияләре буенча институтта һәм якын-тирә район мәктәпләрендә төп белгеч булып исәпләнә. Педагог дәрес үткәрүнең яңа ысулларын киң куллана, яңа технологияләрен эшли. Алар турында Татарстан һәм Россия педагогик конференцияләрендә, Санкт- Петербургта узган Бөтендөнья Конгрессында чыгыш ясады. Ул Татарстан Республикасы Балалар һәм яшьләр белән эшләү Дәүләт Комитеты каршындагы фәнни-тикшеренү группасының җитәкчесе, Республика балалар оешмалары союзының Советы әгъзасы, Алабуга, Менделеевркс, Яр Чаллы, Мөслим, Аксубай, Сарман, Азнакай һәм башка шәһәр- авылларда укытучылар, укучылар тарафыннан көтеп алынган үз кеше, Алабуга шәһәрендә үткәрелгән күп кенә

бәйрәмнәр, конкурслар, кичәләрнең авторы һәм режиссеры. Хәзерге вакытта Сәләхетдин Таҗиев докторлык диссертациясе өстендә эшли. Чын күңелдән зур уңышлар телибез аңа!

(С.Ф.Таҗиев турында очеркны республика һәм район матбугатында бастырылган Ә.Баграмова, Ә.Ибраева, И.Уханов, Н.Максутова, Н.Әхмәтҗанов,

Т.Епифанова мәкаләләре нигезендә хезмәттәше Розалия Миңнулина төзеде).

## БЕЗ БИТ БӘЗӘКӘЛЕЛӘР

Адәм баласы үткәнне белми торып алга, киләчәккә таба дөрес юл таба алмый. Кешелекнең һәм кешенең тарихи аңы булырга тиеш. Кем синең нәселең? Кая йөз тотасың? Бу сорауларга җаваплар кешенең якты дөньяда яшәвенең асылын билгелиләр. Бу якты дөньяга килгән һәр кеше уй- фикерен, гамәлләрен шушы сорауларга җавап хәлендә кыла, башкара. Җир йөзендә һәр. нәрсәдә эз калдыра. Адам баласы калдырган эз - аның яшәвенә бәя бирә торган җирлек. Аны яшәү чорында нинди фикерләр борчыган, нинди гамәлләр башкарганыннан чыгып яхшы яиса начар дип бәяләргә була.

Һәр ана үз баласын бу фани дөньяга яхшы эз калдырсын дип таба һәм бага. Бу нәүбәттән чыгып фикер йөрткәндә, кем мин дигән сорауга җавап эзләүдән элек, кайдан мин, кем минем нәселем дигән сорауга җавап эзләргә кирәк. Кайдан мин дигән сорау фәлсәфи тирән мәгънәне үз эченә ала. Безнең бабайлар әйтмешли, «жиде буын бабаңны белү фарыз», ягъни сина дип салынган эз-сукмак нинди? Бабаңнар кем булган? Кайларда яшәгәннәр? Нинди гамәлләр кылганнар? Син алар белән горурланырлыкмы? Син алар эшен дәвам итәрга лаеклымы? һәм башка сораулар чылбыры туа. Бу күзлектән чыгып фикер йөрткәндә, тагын да яңа сораулар хасил булалар: Синең туган жирең кайда? Син кайсы милләт баласы? Тоткан кыйблаң кай тарафта? Туган авылың, төбәгең кайда? Аның тарихы нинди? Менә шушы сорауларга җавап тапкач кына, үзеңнең кем дигән сорауга җавап эзләп була. Син калдырган эз, тормышың, кавемең эзен лаеклы дәвам итәргә тиеш. Хәзер инде туган авыл тарихын белу адәм баласы өчен аның бабаларының җанлы тарихын белүгә тиң була. Менә ни өчен адәм баласы бу сорауларга җавап эзләп узенең авыл, төбәк тарихы белән яхшы таныш булырга тиешлек ачык

күренәдер.

Шушы хаҗәттән чыгып мин үз туган авылым Бәзәкә тарихын кулдан килгән, мөмкин булган кадәр бәян итәргә тырыштым. Ул беренче нәүбәттә үзем өчен, авылдашларым өчен, улым Дамир' өчен, оныкларым өчен - киләчәк буын өчен язылды. Билгеле ки, бәян ителгән авыл тарихы тулы түгел. Катлаулы, сикәлтәле тарих, бертуктаусыз кабатлана торган инкыйлаблар, иҗтимагый бәрелешләр, халәти тормышның астын-өскә китереп, гел болгатып торалар. Тарихны барлау, туплау, җыйнау катлаулы, четерекле, хәтта кайсыдыр нәүбәттә мөмкин да булмаган эштер. Шәһәрләр, фабрика-заводлар, эшчеләр турында күп китаплар, мәкаләләр, очерклар язылган, тик авыл, авыл хезмәтчәннәре бу өлкәдә читләтеп үтелгән. Авыл тарихы үзеннән соң бернинди язмача истәлекләр калдырмыйча юкка чыккан. Исән калган документлар да ярты-йорты, тулы булмаган мәгълүматлар бирәләр яисә бөтенләй юкка чыгарылганнар. Рәсәй шундый ил инде ул: гасырлар буйлап авыл хисабына яшәде, тик үзе авылга нәрсәдер бирерга ашыкмады.

Биш-алты гасыр яшәп кидүче туган авылым өчен аның тарихын бәян итәргә моңарчы теләүче табылмаганмы дип соравыгыз мөмкин. Бу сорауга мин болай дип җавап бирер идем: Бәзәкә тарихы белән кызыксынучы һәм аны буыннардан буыннарга сөйләп калдыручы кешеләр авылымда булган. Мәсәлән, Габделхак Хөснетдиновка 1932 елда Кәлимуллин Сәлимулла һәм Әхмәдиев Мөхәмәтҗан васыять итеп авыл тарихы буенча күп кенә материаллар васыять итеп калдырганнар. Муллалар ничә гасыр авылның шәҗәрәсен алып барганнар. Бәзәкә мәктәбе укытучылары авыл тарихы буенча

байтак материал җыйганнар. Картлар истәлекләре, кайбер документлар, фотолар белән бизәлгән альбомнар һәм стендлар тутырылган, авыл музее өчен тарихи әйберләр җыелган. Мәктәптә Рәмзия Мөхетдинова инициативасы белән һәм аның җитәкчелегендә Марсель Гыймазетдинов музее оештырылган. Бәзәкә урта мәктәбендә 1974-1976- нчы елларда автор җитәкчелегендә Туган якны өйрәнүчеләр клубы эшләде. Клуб эшләгән чорда авыл картлары һәм галимнәр белән очрашып байтак материал җыелды. 1976 елның мартында Мәдәният йортында авыл тарихына багышлап укучыларның фәнни конференциясе узды. Аннан соң бу эшне Рәмзия Мөхетдинова һәм аның хезмәттәшләре дәвам итте. Аның җитәкчелегендә әле хәзер дә «Мирас» исемле туган якны өйрәнүчеләр оешмасы эшли.

Әлбәттә, картлар сөйләве буенча гына бу очерклар язылса, бик дөрес үк булып бетмәс иде. Шуңа күрә авторга күп кенә дәүләт архивларында, музейларда, фәнни китапханәләрдә эшләргә туры килде. Мәскәүдәге Борынгы документларның Рәсәй дәүләт архивы, Рәсәй дәүләт фәнни китапханәсе, Татарстан Республикасы дәүләт архивы һәм дәүләт туган якны өйрәнү музее, Киров өлкәсе дәүләт архивы, Татарстанның Республика китапханәсе, Алабуга, Менделеевск, Бәзәкә урта мәктәбе музейлары материаллары, Татарстан галимнәренең туган як тарихына багышланган китаплары һәм фәнни эшләре киң кулланылды. Нәҗип Фатыховның «Бондюжцы Татарстана» дигән китабында тарихка инде кергән авылдашларыбыз: барлык гомерен колхоз төзүгә һәм аны үстерүгә багышлаган Габделхак Хөснетдинов, мәшһүр математик, Татарстанның атказанган укытучысы Габделхәй Гыйльфанов, мәктәп директоры һәм хәрби эш укытучысы Зәйнак Әһлиев, укытучы Гөлсем Садыйфова, алдынгы колхозчы- ветеран Нуриәхмәт Азин һәм башкалар турында җылы сүзләр язылган. Алар турында мәгълүматларны шул китаптан укырга мөмкин. Бәзәкәлеләр турында кыскача язмалар бирелгән.

Авылның килеп чыгышы, аның үсеш тарихын өйрәнүдә Фәйзелхак Гыйльфан улы Хөснетдинов күп көч куйды. Бу

китапта аның рөхсәте белән күп материаллары кулланылды. Фәйзелхак абыйга, аның абыйсы Габделхак Гыйльфан улына, шулай ук укытучы МөхетдиноваРәмзия Гәрәй кызына очерклар язганда булышканнары өчен зур рәхмәтемне белдерәм. Бу китап матди ярдәм күрсәтүчеләр булмаса, әле дөнья күрә алмас иде. Аларга зур рәхмәт.

Иң зур рәхмәтләрем мине бу дөньяга табып үстергән, туган ягыма һәм авылымамәхәббәт тәрбияләгән әтием Фәрдетдин Таҗетдин улы Таҗетдиновка, әнием Газизәбану Сәлимулла кызы Сәлимуллинага, миңа югары белем алу өчен шартлар тудырган якын туганнарым Гәйфетдин абыйга, Галиябану һәм Рабига апаларыма, бу китапны язар өчен авылдашларым образлары тудырган күршеләрем Наҗия апа Мәхмүтова һәм Гәрәй абый Нәсифуллинга, Фәйрүзә апа белән Сәләхетдин абый Габделнасыровларга, Фәйрүзә апа белән Рәхим абый Әхмөтҗановларга, миңа өс киемнәре тегеп биргән Нуриәсмә әбигә, бергәләп каз бәбкәләре саклаган Зарифә әбигә, көтүләр көткән Минәхмәт абыйга, җиңгәм ХәмденисәМинтаҗетдин кызы белән абыем Хәмәт Вәлиулла улы Нигъмәтуллиннарга, башлангыч сыйныф укытучым Гөлсем апа Гайнуллинага, иң яраткан өлкән вожатыем Әдия апа Ибраевага, сыйныф җитәкчем Мансура апа Әхмәтовага, барлык укытучыларыма, мәктәптә бергә эшләгән коллегаларыма, тау башында качышлы уйнап, әрәмәдә гөлҗимеш җыеп, төннәрен авыл буйлап җырлап йөреп бергә үскән Минегәли, Саетҗан, Мирзанур, Хөрмәтулла, Мансур, Кәүсәр, Сабира, Гөлфирә, Әкълимә, Мәүлидә һ.б. дусларыма.

Сабантуйларда актан киенеп йөгерешләрдә катнашкан Солтан бабай, Сабантуй батыры Сәетгәли абый, оста балыкчы Шункар бабай, кул остасы Минтаҗетдин бабай, тимерче Әхәт абый, янгынчы Минәхмәт Мөхәмәтдинов, ялкынлы сүз остасы һәм иҗат иясе, балалар остазы Рәмзия Мөхетдинова, Сабантуйлар хуҗасы, мәктәп

директоры һәм роно җитәкчесе булып эшләгән Мөхәмәтнур Сабитов, алдынгы колхозчы яшьләр, бу китапка кермәгән атамалар, кушаматлар турында язып тагын бер китап чыгарырга булыр иде. Бәзәкә шәҗәрәсен гарәпчәдән татар теленә кайтарырга кирәк дип уйлыйм...«Урыслашкан» бәзәкәлеләр өчен урыс телендә бу язмаларны нәшрият итү кирәктер.

Бәлки, бу китап чыкканнан соң, авылымның лаеклы бер асылы Бәзәкә тарихын тагын да тирәнрәк өйрәнергә алыныр, баетыр, тулыландырыр. Шушы өметләр белән бу китапны сезгә тәкъдим итәм, авылдашларым.

Кайда гына яшәмәсеннәр һәм нинди генә урыннарда эшләмәсеннәр, авылдашларыма теләгем шул: туган җир - изге җир, тудырып үстергән ата-ана - олугъ затлар. Аларның кадерен белегез! Сез суын эчкән чишмәләр, җиләк-җимешен ашап үскән әрәмәләр, үрмәләп менгән таулар, икмәк үстергән кырлар - барысы да сезнең үткәнегез, бүгенге көнегез һәм киләчәгегез. Нинди мәшһүр һәм хатирәләргә бай, нинди гүзәл, нинди сихерле көчле, нинди күңелгә якын ул Туган авыл!

Туганнарым, дусларым, авылдашларым! Бәзәкәлеләр! Яратыйк Бәзәкәне, онытмыйк Бәзәкәне, саклыйк Бәзәкәне! Матур эшләребез, рухи тормышыбыз, акыллы, саф күңелле, сәламәт балаларыбыз белән бизәклик Бәзәкәне!

Я, АиПЛАҺЫ ТӘГАЛӘМ, бу изге эшне башкарып чыгарга көч биргәнең өчен рәхмәт Сиңа!

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР


1. Абзянов М., Мухаметзянов А.,Фархутдинов А. Вышки над Камой. - Казань, 1978.
2. Анастасиев А. Вятские инородцы и ихъ школы. - М., 1902.
3. Арсланов Л.Ш. Угро-самодийские элементы в топонимии и археологии Восточного Прикамья.- Тезисы докладов 1 научно-краеведческой конференции, посвященной 25-летию города Менделеевска, Менделеевск, 1992, с.3-5.
4. Арсланов Л.Ш., Казаков Е.П., Корепанов К.И. Финны,

угры, самодийцы в Восточном Прикамье. - Елабуга, 1993.

5. Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье/ Под ред. А.Х.Халикова .- М., 1981.
6. Архивы и краеведческие материалы по истории г. Менделеевска и района.- Менделеевск, 1991.
7. Ахметгалиева С.Н. Обзор деятельности химического завода имени Л.Я.Карпова за 1868- 1900 гг. - Заводская трибуна, 1976, № 16.
8. Баграмова А., Ибраева А. Наш друг. - Новая Кама, 1973, 9 ноября.
9. Бәзәкә мәктәбе тарихы. Альбом. - Бәзәкә, 1972.
10. Бәзәкә пионер һәм комсомол оешмалары тарихы. Альбом.- Бәзәкә, 1974.
11. Валиев М. Слово о товарище,- За педагогические кадры, 1983, 19 декабря.
12. Гамбәр Н. Туган якның китмәс кошы.-Казан,1994.
13. Гарипова Ф. Авылларны сөям җаным-тәнем беләнн. - Казан, 1994.
14. Гыймазетдинов М. Син мине белмисең.- Казан, 1994.
15 Епифанова Т. Когда приехали студенты. - Новая Кама, 1973, 21 апреля.
16. Золото Прикамья.- Елабуга, 1998.
17. История Татарской АССР. - Казань, 1955.
18. «Кама» колхозы тарихы. Альбом.- Бәзәкә, 1976.
19. Кашапов Н.П. Занятия сельского населения Вятской губернии до 1917 г,- Менделеевские новости, 1989, № 64.
20. Кашин С.Г. Есть на Каме завод. - Казань, 1972.
21. Киров өлкәсе дөүлет архивы. 574-фонд, 1-тасвирлама, 3504-китап,127-бит.
22. Киров өлкәсе дәүләт архивы. 205-фонд, 3-тасвирлама, 2847-китап, 13-20-битләр.
23. Краткие сведения по истории Менделеевского района.- Менделеевск, 1993.
24. Максутова Н. Беренче карлыгач. - Яңа Кама, 1973, 21 апрель
25. Материалы по статистике Вятской губернии (данные

на 1887 г.).- Вятка, 1890, т. У1, ч. 2, п. 2.

26. Мирзаянова Р. Шигърияткә, моңга гашыйк ул. - Менделеевск яңалыклары, 1999, 6 февраль.
27. Мөхетдинова Р.Г. Бәзәкә авылының балалар бакчасы тарихы. Альбом. -Бәзәкә, 1988.
28. Мөхетдинова Р.Г. Манаралар ауды бәгырьгә. Кулъязма. -Бәзәкә, 1993.
29. Мөхетдинова Р.Г. Шагыйрь белән очрашу. Кулъязма. - Бәзәкә, 1994.
30. Нурутдинов Ф.Х. Родиноведение. -Казань, 1995.
31. Бондюге и бондюжцах. Сборник/ Сост. М.Глухов - Казань, 1994.
32. Бондюге и бондюжцах, Сборник/ Сост. М.Глухов. - Казань, 1994, с.399-403.
33. Розенгартен М. Кеше булган кешедә йөз кешенең эше бар. - Ватаным Татарстан, 1999 ел, 1 май
34. Сабитов М.Г. Бәзәкә авылының тарихи урыннары. Кулъязма. - Бәзәкә, 1993.

3б.Сабитов М.П. Сборник материалов по топонимике Республики Татарстан. - Набережные Челны, 1997.

36. Сборник тезисов по краеведению. - Набережные Челны, 1992.
37. Тазиев С. Всегда в дороге. - Комсомолец Татарии, 1974, 8 марта.
38. Тазиев С. Интересный вечер. - Новая Кама, 1974, 1974, 3 февраля

3Э.Тазиев С. Слово о друге. - Вожатый, 1973, № 2, с. 34.

40. Таҗиев С. Бүгенге көн сулышы. - Яңа Кама, 1973, 24 октябрь.
41. Таҗиев С. Туган якны өйрәнүнең тәрбияви мөмкинлеге. - Совет мәктәбе, 1976, № 6, 9-12 битләр.
42. Татарский энциклопедический словарь. - Казань, 1998.
43. Татарстан АССР тарихы. 1 том. - Казан, 1959.
44. Татар тарихы материалларда һәм документларда.- Казан, 1970.
45. Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре. -

Казан, 1995, 180-нче бит.

46. 35 лет НГДУ «Прикамнефть» Альбом.
47. Уханов И. Приедем, Фарида! - Учительская газета, 1971, 30 ноября.
48. Фатыхов Н. Слава бизякинцам! - Бондюжцы Татарстана, Санкт- Петербург, 1995, с. 399- 403.
49. Фәхретдинов Р.Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. 1-нче кисәк. -Казан, 1996.
50. Фотолар - Р.Г.Мөхетдйнова, Ф.Г.Хөснетдинов.
51. Халиков А.Х. Древняя история Среднего Поволжья.- М., 1969
52. Халиков А.Х. Татар халкының килеп чыгышы. - Казан, 1974.
53. Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. - Казань, 1989.
54. Хөснетдинов Ф. Байлык корбаны. - Октябрь байрагы, 1960, 8 июнь.
55. Хөснетдинов Ф. Бәзәкә тарихы турында уйланулар. Кулъязма.- Бәзәкә, 1997.
56. Хәтер-Память /гл. ред. Р.Р.Идиатуллин.- Казань, 1995.
57. Әхмәтҗанов Н. Уңыш телибез. - Яңа Кама, 1973, 13 март.

## **Илаһи заң**

Нәфисгөл Гәлиева

Бәзәкәдә җиткерелде
Мәчетнең иң ма!уры.
Артты авылымның яме,
Өстәлде нуры!
Нурлар сибә тирә-юньгә
Көләч айлы манара.
Шул нурларда җир өстенә
Ислам дине тарала.
Биек манарадан тиздән
Моңлы яңгырар азан.
Бу бит туган халкым моңы
Һәм дә илаһи

заң




бинасы

Соңгы елларда төзелгән мәчет



еге 4




Көчөндедә табылган болгар көбер ташы

19 гасыр мәчете
(И.Муллөхмәтов рәсеме)




Түбән оч мәчете (19 гасыр азагы -20 гасыр башы)



Югары оч мәчете (1941 елдан балалар бакчасы)



20 гасыр башы йорты




Пинәрә күлендә ял (70 еллар фотосүрәте)



Шәйхетдин кәберлеге (рәсем)


Хөснетдиновлар гаиләсе


«Бизәкле» Бәзәкәдә (койма артында мунча күренә)





Галим Мансура Әхмәтова

Атказанган укытучы Рәшит Бәшаров





Вожатый Әдия Ибраева

Шагыйрь һәм җитәкче Марсель Гыймазетдинов



**Авторның әтисе Фәрдетдин һәм әнисе Гөзизәбану**

АВТОРНЫҢ АЛЬБОМЫННАН




**М.Гыймазетдинов җырларын башкаручы җырчылар Г.Авзалов, Р.Шәрәфиева, Р.Гәлиев һәм биюче А.Вавилов авторда кунакта**

Эчтәлек

Туган авылыбыз Бәзәкә. С.Таҗиев........................... 3
Туган авылым - Бәзәкәм. М.Гыймазетдинов 3
Сагындырды мине. Ф.Хөснетдинов ...........................4
Туган җирем. Ф.Шакирова ......................................... 5
Баллы чишмә. М.Гыймадиев..................................... 5
Кайда да йөрәктә ....................................................... 6
Бәзәкә шәҗәрәсе ....................................................10
Бәзәкә исеме килеп чыгышына карашлар 12
Авылның килеп чыгышы һәм үсеше тарихы 16
Бәзәкәнең истәлекле урыннары .............................. 48
Авылда мәгариф һәм мәдәният тарихы ,.................52
Бәзәкәнең йөзек кашлары .......................................67
Алар гүзәл кешеләр. Ф.Шакирова............................ 67
Авылнын асыл заты ................................................. 67
Туган якның китмәс кошы ........................................ 69
Гыйлембәшәрнекеләрнең берсе............................. 73
Бертуган Гыймадиевлар......................................... 75
Мәңгелек яшь Әдия ................................................. 76
Тату гаилә................................................................. 78
Нефтьчеләр җитәкчесе Вәлиәхмәт ......................... 81
Атаклы хирург.......................................................... 83
Бертуган Мәскәү галимнәре.................................... 88
Академик Мансур ..................................................... 90
Мәхмүтовлар династиясе ........................................ 91
Нәҗметдиновлар гаиләсе........................................ 95
Шигърияткә, җырга гашыйк ул ................................ 98
Балаларның якын дусты .......................................... 99
Без бит Бәзәкәлеләр ............................................. 104
Кулланылган әдәбият һәм материаллар.............. 109
Илаһи заң. М.Гәлиева............................................ 112

Издательство ЕГПИ (г. Елабуга, ул. Казанская, 89)
Заказ Тираж 500 Объем 7,5 п.л.